ФГОС

Р. З. Хайдарова, Р. Л. Малафеева, Г. М. Ахметзянова

# ТАТАР ТЕЛЕ

8 класс




Татармультфильм
издательство
«Татармультфильм»


Жө
Предл
Баш кисәкләр
Главные члены предложения
Ия
Подлежащее
кем?
нәрсә?
Хәбәр
Сказуемое
нишли?
нишләде?
нишләгән?
нишләячәк?
нишләр?
нинди?
кем?
Аер
Опред
нинди
ничән
кайсы
кемне
нәрсән

**млә**
ожение

**Иярчен кисәкләр**
Второстепенные члены предложения

**гыч**
еление

?
че?
?
ң?
нең?

**Тәмамлык**
Дополнение

кемгә?
нәрсәгә?
кемне?
нәрсәне?
нәрсә белән?
кем белән?
нәрсә турында?
кем турында?
кемнән?
нәрсәдән?

**Хәл**
Обстоятельство

кайда?
кайчан?
ни өчен?
нинди максат
белән?
нишләсә?
ничек?
күпме?

Р. З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, Г. М. Әхмәтҗанова

# ТАТАР ТЕЛЕ

# 8

## СИГЕЗЕНЧЕ СЫЙНЫФ

ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ
ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК
(ТАТАР ТЕЛЕН БАШЛАП ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН)

ДӘРЕСЛЕК Е. И. ПАССОВНЫҢ
КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ
НИГЕЗЛӘНӘ

КАЗАН
«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ
2025

Р. З. Хайдарова, Р. Л. Малафеева, Г. М. Ахметзянова

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

# 8

## ВОСЬМОЙ КЛАСС

УЧЕБНИК ДЛЯ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ
ОСНОВНОГО ОБЩЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
(ДЛЯ ОБУЧАЮЩИХСЯ, НЕ ВЛАДЕЮЩИХ
ТАТАРСКИМ ЯЗЫКОМ)

НА ОСНОВЕ КОНЦЕПЦИИ КОММУНИКАТИВНОЙ
ТЕХНОЛОГИИ Е. И. ПАССОВА

КАЗАНЬ
ИЗДАТЕЛЬСТВО «ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ»
2025

УДК 811.512.145(075)
ББК 81.632.3я72
Х18

## Условные обозначения

Начало урока

Запомни!

Вспомни!

Произноси правильно!

Работа в парах

Работа в группах

Творческая работа

Инсценирование

Ситуативные упражнения

**Хайдарова, Р.З. и др.**

Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 8 класс: учебник для образовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р.З. Хайдарова, Р.Л. Малафеева, Г.М. Ахметзянова. — Казань: Татармультфильм, 2025. — 126 с.: ил.
ISBN 978-5-906508-04-1

**ISBN 978-5-906508-04-1**

**УДК 811.512.145(075)**
**ББК 81.632.3я72**

© Хайдарова Р.З., Малафеева Р.Л., Ахметзянова Г.М., 2025
© Издательство «Татармультфильм», 2025
Все права защищены

# Яңа уку елы котлы булсын!



**Кадерле укучылар!**

Менә яңа уку елы башланды. Сез татар теле өйрәнүне дәвам итәсез. Дәреслек сезгә бу хезмәтегездә зур ярдәмче булыр. Дәреслек эчтәлеге аша сез үзегезне борчыган проблемаларга җавап эзләрсез, яшьтәшләрегез белән фикерләшерсез, хис-тойгыларыгызны уртаклашырсыз. Сезне яңа хикәяләр, яңа геройлар, яңа образлар көтә.

Дәреслек татар теле грамматикасы буенча белемнәрегезне киңәйтергә ярдәм итәр. Татарстанда татар һәм рус телләре — дәүләт телләре. Ике дәүләт телен дә белү — сезнең өчен гаять әһәмиятле, кызыклы, кирәкле гамәл. Татар теле ярдәмендә сез туган илебезне яратырга, дус яшәргә, кешеләрне хөрмәт итәргә өйрәнерсез. Уңышлар сезгә!

# КҮП УКЫГАН КҮП БЕЛЕР



## 1–2 нче дәресләр

**1.** Укытучыларны, укучыларны, дусларыгызны Белем бәйрәме белән котлагыз.



**2.** Укучы өстәлендә нинди уку-язу әсбаплары бар?



**3.** Используя названия предметов на рисунке к упражнению 2,

— попросите себе эти учебные принадлежности;
— узнайте у друга, есть ли у него эти учебные принадлежности;
— спросите у него, нужны ли ему эти учебные принадлежности;
— узнайте у друга, купил ли он эти учебные принадлежности.

**4.** Диалогка төшеп калган репликаларны куегыз, сөйләшергә өйрәнегез.

— Лена, син искиткеч матур кофта кигәнсең!
— ... . ... ?
— Әйе, мин дә яңа костюм алдым. Ә син китаплар алдыңмы әле?
— ... .
— Бүген расписаниедә сезнең нинди дәресләр бар?
— ... .
— Ярый, мин сине көтәрмен.



**5.** Как скажете о том, что:

— вы соскучились по школе, друзьям;
— школа ждёт своих друзей;
— у вас новый классный руководитель;
— вы начали изучать новые предметы;
— вы получили новые учебники?

**6.** Спросите у друга:

— каким уроком будет английский язык;
— в каком кабинете будет урок татарского языка;
— сколько уроков будет завтра;
— будет ли сегодня урок литературы;
— раздали ли учебники.

**7.** **Исегезгә төшерегез!**

**Исемнәрнең тартым белән төрләнеше**

Имена существительные с аффиксами принадлежности

| Зат | Тартыкка беткән исемнәр | Сузыкка беткән исемнәр |
|---|---|---|
| I зат | карандаш-ым<br>дәфтәр-ем | хата-м<br>җилкә-м |
| II зат | карандаш-ың<br>дәфтәр-ең | хата-ң<br>җилкә-ң |
| III зат | карандаш-ы<br>дәфтәр-е | хата-сы<br>җилкә-се |

**8.** Шигырьне укыгыз, тартымлы исемнәрне билгеләгез, тәрҗемә итегез.

**Мәктәбем**

Елмая тәрәзәләре,
Түрләре — колач җәйгән.
Улларын көтә мәктәбем,
Уллары — кайта җәйдән...



И мәктәбем, мәктәбем,
Син — шатлыгым, син — ямем.
Синдә күрдем, синдә белдем
Туганлык, дуслык тәмен.

Синдә тәүге укытучым,
Тәүге куанычларым.
Сиңа минем, и мәктәбем,
Гомерлек бурычларым...

Р. Вәлиева

**түрләре** — здесь: внутренняя часть здания
**колач җәйгән** — здесь: встречает с распростёртыми руками
**ямь** — прелесть, красота
**тәүге** — первый
**куаныч** — радость, восторг
**гомерлек бурыч** — долг на всю жизнь

**9.** Шигырьдән түбәндәге фикерләргә туры килгән юлларны табып укыгыз.

1. Җәйге каникуллардан соң укучылар мәктәпкә баралар.
2. Мәктәптә укучыларга рәхәт.
3. Мәктәп укучыларга белем бирә.
4. Укучылар мәктәпкә бурычлы.

**10.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

1. Я знакомлюсь со школой. 2. Я знакомлюсь с классным руководителем. 3. Я знакомлюсь с новыми учебниками. 4. Я знакомлюсь с новыми одноклассниками.

**11.** Текстны укыгыз. Эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

Беренче сентябрь — мәктәптә иң күңелле көн. Укучылар да, ата-аналар да, укытучылар да бәйрәмчә киенгәннәр. Укучыларның кулларында матур чәчәк букетлары. Алар, әлбәттә, хөрмәтле кешеләргә — укытучыларга. Укучылар бер-берсен сагынганнар. Алар җәйге истәлекләре белән уртаклашалар.

**12.** Җөмләләрне дәвам итегез. Үзегез төзегән җөмләләргә сораулар куегыз, үзара сөйләшегез.

1. 1 нче сентябрьдә укулар башлана, шуңа күрә ... . 2. 1 нче сентябрьдә без мәктәпкә киләбез, чөнки ... . 3. 1 нче сентябрьдә күңелле, чөнки ... . 4. Мин мәктәпкә бурычлы, чөнки ... . 5. Мин укытучыга бурычлы, чөнки ... . 6. Без укытучыларга бурычлы, шуңа күрә ... .

# 3–4 нче дәресләр

**1.** Атна көннәрен тәртип буенча әйтегез.




**2.** Бер атнага дәресләр расписаниесе төзегез.

## Дәресләр расписаниесе
### 8 нче класс

| | Дүшәмбе |
|---|---|
| 1 | Татар теле |
| 2 | Физкультура |
| 3 | Алгебра |
| 4 | Геометрия |
| 5 | Тарих |
| 6 | |

| | Сишәмбе |
|---|---|
| 1 | |
| 2 | |
| 3 | |
| 4 | |
| 5 | |
| 6 | |

| | Чәршәмбе |
|---|---|
| 1 | |
| 2 | |
| 3 | |
| 4 | |
| 5 | |
| 6 | |

| | Пәнҗешәмбе |
|---|---|
| 1 | |
| 2 | |
| 3 | |
| 4 | |
| 5 | |
| 6 | |

| | Җомга |
|---|---|
| 1 | |
| 2 | |
| 3 | |
| 4 | |
| 5 | |
| 6 | |

| | Шимбә |
|---|---|
| 1 | |
| 2 | |
| 3 | |
| 4 | |
| 5 | |
| 6 | |

**3.** Узнайте у друга:

— какие уроки по расписанию в понедельник;
— сколько уроков в субботу;
— как зовут учительницу английского языка.

**4.** Текст эчтәлеге буенча үзара сөйләшегез.

Яңа уку елы төрле илләрдә төрлечә башлана. Япониядә яңа уку елы 1 нче апрельдә башлана. Италиядә ул — 1 нче октябрьдә, Швециядә — 15 нче августта, Австралиядә 1 нче февральдә башлана.

**5.** **Исегезгә төшерегез!**

## Хикәя фигыль

| Хәзерге заман | Үткән заман | | Киләчәк заман | |
|---|---|---|---|---|
| | билгеле | билгесез | билгеле | билгесез |
| **-а/-ә**<br>**-ый/-и** | **-ды**<br>**-де**<br>**-ты**<br>**-те** | **-ган**<br>**-гән**<br>**-кан**<br>**-кән** | **-ачак/-әчәк**<br>**-ячак/-ячәк** | **-ыр/-ер**<br>**-ар/-әр**<br>**-р** |
| кайт-**а**<br>кит-**ә**<br>җырл(а)-**ый**<br>сөйл(ә)-**и** | кайт-**ты**<br>кит-**те**<br>җырла-**ды**<br>сөйлә-**де** | кайт-**кан**<br>кит-**кән**<br>җырла-**ган**<br>сөйлә-**гән** | кайт-**ачак**<br>кит-**әчәк**<br>җырла-**ячак**<br>сөйлә-**ячәк** | кайт-**ыр**<br>бир-**ер**<br>яз-**ар**<br>кит-**әр**<br>җырла-**р**<br>сөйлә-**р** |

**6.** Бирелгән фигыльләрне үрнәк буенча үзгәртегез, тәрҗемә итегез.

Ү р н ә к: бар — бара — барды — барган — барачак — барыр.

Укы, бел, бул, ал, яса, сөйлә, соңга кал, бир, өйрән, тор.

**7.** Диалогны укыгыз. Дустыгыз белән сөйләшегез.

— Син ничәнче сыйныфта укыйсың?

— Сигезенче сыйныфта.

— Син ничәнче ел татар теле укыйсың?

— Сигезенче ел.

— Мин татарча матур сөйләшә, дөрес укый, чиста яза беләм. Ә син?

— Мин дә татарча матур сөйләшергә, дөрес укырга, чиста язарга өйрәндем.

— Син татарча шигырьләр сөйли беләсеңме?

— Әйе, татарча шигырьләр сөйли, җырлар җырлый беләм.

**8.** Как вы спросите:

— какую оценку получила одноклассница;

— как она отдохнула летом;

— с кем сидит Ляля;
— с кем будет сидеть Алсу;
— каким уроком будет алгебра?

**9.** Сезнең мәктәптә Белем бәйрәме ничек узды? Сөйләргә әзерләнегез.

## 5–6 нчы дәресләр

**1.** Шигырьне укыгыз. Малайлар җәйне ничек үткәргәннәр?

**Безнең йорт малайлары**

Өч сикереп, бер атлап,
Чыктык ишегалдына:
Сагынышкан Сашалар,
Азат, Фәрит бар монда.
Фәрит кайткан Кубадан,
Азат кайткан Алжирдан,
Әтиләре эшләгән
Дөньядагы бар җирдән!
Океан-диңгезләр кичкән
Гитара чирттерәләр,
Испанча да, французча да
Җырларны сиптерәләр!
Открыткалар — әкәмәт,
Карыйбыз өелешеп,
Сувенирлар — галәмәт,
Бүләбез сөенешеп.
Хосе, Әхмәтләр белән
Төшкән фотолар да күп,
Кочаклашып басканнар
Менә шулай, безнең күк.

Ш. Галиев



**сагынышкан** — соскучившиеся
**сиптерәләр** — здесь: поют, исполняют
**безнең күк (кебек)** — как мы
**өелешеп** — сгрудившись
**әкәмәт** — чудный
**сөенешеп** — обрадовавшись

**2.** Шигырьдәге җөмләләрне туры тәртиптә үзгәртеп укыгыз. Ничек уйлыйсыз, шигырьдә җөмләләр һәрвакытта туры тәртиптә генә була аламы?

Үрнәк: Өч сикереп, бер атлап, чыктык ишегалдына.
Ишегалдына өч сикереп, бер атлап чыктык.

**3.** Бу раслаулар дөресме? Җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

— Малайларның әти-әниләре чит илдә эшли.
— Азат Алжирдан кайткан.
— Саша Кубадан кайткан.
— Фәрит Испаниядән кайткан.
— Малайлар пианинода уйный.
— Малайлар гитарада уйный.
— Малайлар испанча, французча җырлыйлар.
— Малайлар фотога төшмәгәннәр.
— Малайлар сувенирлар алып кайтканнар.
— Малайлар чит ил кешеләре белән фотога төшмәгәннәр.

**4.** Сорауларга җавап бирегез. Шигырьнең эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

1. Малайларның әтиләре кайда эшли?
2. Малайлар нинди илләрдә булганнар?
3. Алар нинди телләрдә җырлый беләләр?
4. Алар нәрсәләр карыйлар?
5. Малайлар кемнәр белән фотога төшкәннәр?

**5.** Как скажете, что:

— ваш друг отдохнул на Кубе;
— отец вашего друга приехал из Алжира;
— вы смотрели все вместе летние фотографии друзей?

**6.** Шигырь эчтәлеге буенча диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.



# 7–8 нче дәресләр

1. **Исегезгә төшерегез!**

**Билгесез үткән заман**

Прошедшее неопределённое время

Прошедшее неопределённое время (билгесез үткән заман) глагола употребляется тогда, когда речь идёт о прошедших событиях, в которых говорящий сам не участвовал. Оно образуется присоединением к основе глагола аффиксов:

1) **-ган/-гән**, если основа глагола оканчивается на гласный или звонкий согласный звук:
уйла**-ган** — думал (оказывается),
күр**-гән** — видел (оказывается);

2) **-кан/-кән**, если основа глагола оканчивается на глухой согласный звук:
кайт**-кан** — вернулся (оказывается),
кит**-кән** — ушёл (оказывается).

**Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше**

| Зат Лицо | Берлек санда | Күплек санда |
|---|---|---|
| I | **-мын/-мен**<br>яз-ган-мын — я писал<br>кил-гән-мен — я пришёл | **-быз/-без**<br>яз-ган-быз — мы писали<br>кил-гән-без — мы приходили |
| II | **-сың/-сең**<br>яз-ган-сың — ты писал<br>кил-гән-сең — ты пришёл | **-сыз/-сез**<br>яз-ган-сыз — вы писали<br>кил-гән-сез — вы приходили |
| III | **—**<br>яз-ган — он писал<br>кил-гән — он пришёл | **-нар/-нәр**<br>яз-ган-нар — они писали<br>кил-гән-нәр — они приходили |

2. Түбәндәге фигыльләрне зат-сан белән төрләндерегез.

Оныткан, яткан, әзерләгән.

3. Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

1. Мин кичә бик тиз йоклап киткәнмен.
2. Хоккей уйнарга соңга калганмын.

3. Безгә Наил килгән, ә мин йоклаганмын.
4. Әби мин яраткан ашны пешереп куйган.
5. Син кичә миңа шалтыраткансың.

**4.** Диалогларны үзара сөйләшегез.

1. — Мин сиңа кичә шалтыраттым. Син телефоныңны алмадың.
— Мин кичә арыган идем. Мин йоклаганмын.

2. — Әбием, мин кайттым.
— Ярый, улым. Әйдә ашарга утыр.
— Ярый, әбием. Минем бик ашыйсым килә.
— Мин аш бүләм.
— И әбием, син мин яраткан ашны пешергәнсең, рәхмәт сиңа!
— Тәмле булсын, улым!

**5.** Җөмләләрне укыгыз, фигыльләрнең заманнарын билгеләгез. Җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

1. Мин мәктәптән кайттым һәм дәрес әзерләргә утырдым. 2. Кичке ашны ашагач, мин йоклап киткәнмен. 3. Мультфильмнан соң кино башланган. 4. Тиздән мәктәптә укулар башланачак. 5. Укытучы апа мәсьәләне Наилдән сорады. 6. Наил мәсьәләне чишәргә оныткан.

**6.** Түбәндәге фигыльләрне таблицага урнаштырыгыз. Алар белән җөмләләр төзегез.

| Хәзерге заман хикәя фигыль, I зат, берлек сан | Билгеле үткән заман хикәя фигыль, II зат, берлек сан | Билгесез үткән заман хикәя фигыль, III зат, берлек сан |
|---|---|---|
| утырам<br>... | утырды<br>... | утырган<br>... |

Калдырам, онытты, ятам, килгән, башлыйм, барган, карыйм, уйнаган, кайтты, өлгерәм, йоклаган, чакырды, алмады, чишмәде.

**7.** Фигыльләрне үрнәктәгечә үзгәртегез.

Ү р н ә к: Ул утыра. Ул утырды. Ул утырган.
Ята, өлгерә, чишә, күчерә, чакыра, аңлый.

**8.** Тәрҗемә итегез. Фигыльләрне билгесез үткән заманда кулланыгыз.

1. Бабушка сварила мой любимый суп. 2. Вчера он пришёл поздно вечером. 3. Я забыла тетрадь дома. 4. Он списал контрольную работу у Айдара. 5. Вчера у нас было всего три урока. 6. Я пришёл домой раньше.

**9.** Бу сүзләрнең антонимнарын табыгыз. Җөмләләр төзегез.

Көн, күп, ерак, зур, биек.

**10.** Сообщите другу о том, что вы, оказывается:

— опоздали на урок;
— опоздали на игру — хоккей;
— уснули после фильма;
— забыли приготовить уроки;
— забыли решить задачу.

## 9–10 нчы дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Билгеле киләчәк заман**
Будущее определённое время

Если вы говорите о таком действии, в совершении которого уверены, то употребляете будущее определённое время глагола (билгеле киләчәк заман), которое образуется путём присоединения к основе аффиксов:

1) **-ачак/-әчәк,** если основа оканчивается на согласный звук (тартык аваз):

яз-**ачак** — напишет, будет писать;
кит-**әчәк** — уйдёт, будет уходить;

2) **-ячак/-ячәк,** если основа оканчивается на гласный звук (сузык аваз):

укы-**ячак** — прочитает, будет читать;
эшлә-**ячәк** — сделает, будет делать.

**Билгесез киләчәк заман**
Будущее неопределённое время

Если вы говорите о таком действии, в совершении которого сомневаетесь, то употребляете будущее неопределённое время глагола (билгесез киләчәк заман), которое образуется путём присоединения к основе аффиксов:

1) **-р** — к основам, оканчивающимся на гласный звук:
эзлә-**р** — поищет;

2) **-ар/-әр**, **-ыр/-ер** — к основам, оканчивающимся на согласный звук:

яз-**ар** — напишет, кит-**әр** — уйдёт,
бар-**ыр** — пойдёт, кил-**ер** — придёт.

**2.** Таблицаны өйрәнегез.

**Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльләрнең - зат-сан белән төрләнеше**

| | Берлек санда | Күплек санда |
|---|---|---|
| I зат | **-мын/-мен**<br>яз-ар-мын<br>(я буду писать);<br>кил-ер-мен<br>(я буду приходить; приду) | **-быз/-без**<br>яз-ар-быз (мы будем писать; напишем);<br>кил-ер-без (мы будем приходить; придём) |
| II зат | **-сың/-сең**<br>яз-ар-сың (ты будешь писать; напишешь);<br>кил-ер-сең (ты будешь приходить; придёшь) | **-сыз/-сез**<br>яз-ар-сыз (вы будете писать; напишете);<br>кил-ер-сез (вы будете приходить; придёте) |
| III зат | —<br>яз-ар (он будет писать; напишет);<br>кил-ер (он будет приходить; придёт) | **-лар/-ләр**<br>яз-ар-лар (они будут писать; напишут);<br>кил-ер-ләр (они будут приходить; придут) |

**3.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

1. Олег бүген дәрес әзерләмәгән, иртәгә әзерләр инде.
2. Кичкә кадәр вакыт бар әле, дәрес әзерләргә өлгерермен.
3. Бүген иртәрәк ятармын да иртән иртәрәк торырмын.
4. Иртән иртәрәк уянырмын да дәрес әзерләрмен әле.
5. Мәсьәләне Наилдән күчерермен, ә мисалны үзем чишәрмен.
6. Син мисалны үзең эшләрсең, ә мәсьәләне чишәргә мин булышырмын.

**4.** 3 нче күнегүдәге җөмләләрдән билгесез киләчәк заман формасындагы фигыльләрне табыгыз, билгеле киләчәк заман формасына үзгәртегез. Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

**5.** Фигыльләрне үрнәктәгечә үзгәртеп языгыз, җөмләләр төзегез.

Ү р н ә к: кайта — кайтачак — кайтыр; кайтам — кайтачакмын — кайтырмын.

Әзерли, ашый, ята, башлый, уяна, күчерә, уйлый, сөйли, чишә.

**6.** Нокталар урынына билгесез киләчәк заман формасындагы фигыльләрне языгыз.

1. Дәрес әзерләргә кино карагач ... .
2. Дәрес әзерләргә бер чынаяк чәй эчкәч ... .

3. Мәсьәләне иртән мәктәпкә баргач ... .
4. Күнегүне хоккей уйнагач ... .
5. Өй эшләрен бераз йоклап алгач ... .

**7.** Как напишете о том, что, возможно, завтра:

— вы сходите в гости, в библиотеку, к друзьям;
— вы поедете в деревню, в спортивный лагерь;
— он приготовит завтрак, ужин, обед;
— вы напишете письмо бабушке?

**8.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәп языгыз. Диалогларны үзара сөйләшегез.

1. — ... ?
— Бара алмыйм. Миңа өй эшләрен эшләргә кирәк.
— ... ?
— Өй эшләрен эшләгәч, әнигә булышам.

2. — ... ?
— Математикадан мәсьәлә чишәргә, рус теленнән күнегү эшләргә кирәк.
— ... ?
— Өй эшләрен эшләгәч чыгам.
— ... ?
— Сәгать дүрттә.




3. — Син кич дәресләреңне әзерләдеңме?
— ... .
— Син бит кич дәресләрне әзерләячәкмен дип сүз биргән идең.
— Әйе, ләкин иртән әзерләрмен дип уйлаган идем.
— Ә иртән торачаксыңмы?
— ... .

**9.** 6 нчы күнегү эчтәлегеннән һәм таблицалардан файдаланып, диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

# 11–13 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Деепричастие** (хәл фигыль) имеет признаки глагола и наречия, обозначает добавочное действие, поясняющее как, когда, почему, с какой целью совершается основное действие.

**2.** Хәл фигыль кушымчаларын истә калдырыгыз.

| -ып<br>-еп<br>-п | -а/-ә<br>-ый/-и | -ганчы/-гәнче<br>-канчы/-кәнче | -гач/-гәч<br>-кач/-кәч |
|---|---|---|---|
| ал-**ып** (взяв)<br>кил-**еп** (придя)<br>аңла-**п** (понимая) | ал**а**-ал**а** (беря)<br>сикер**ә**-сикер**ә** (прыгая)<br>уйл**ый**-уйл**ый** (думая)<br>сөйл**и**-сөйл**и** (говоря) | кайт-**канчы** (пока не вернулся)<br>кит-**кәнче** (пока не ушёл)<br>кил-**гәнче** (пока не пришёл)<br>ал-**ганчы** (пока не взял) | күр-**гәч** (увидев, как только увидел)<br>кайт-**кач** (вернувшись, как только вернулся)<br>әйт-**кәч** (сказав, как только сказал) |

**3.** Җөмләләрдәге сорау урынына хәл фигыль өстәп языгыз.

1. Алёна бик (ничек?) укый, белгәнен бер дә онытмый.
2. Институтны (нишләгәч?), укытучы булып эшли башлый.
3. Мәктәпне (нишләгәч?), ул институтка укырга керәчәк.
4. Звонок (нишләгәнче?), без өлгерәбез.

**4.** Җөмләләрдә астына сызылган сүзләрне хәл фигыль белән алмаштырыгыз.

1. Ул бик нык тырышты, укыды. 2. Ул өйгә кайта, мин кибеткә китәм. 3. Ашыйм, аннан соң хоккей уйнарга китәм. 4. Кино карыйм, аннан соң дәрес әзерлим.

**5.** Как скажете о том, что:

— когда год прошёл, он вернулся;
— когда осень наступает, дни становятся короткими;
— пока не наступит вечер, я не пойду домой;
— когда закончится урок, я позвоню маме?

**6.** **Исегездә калдырыгыз.**

**Аналитик фигыльләр**
Аналитические глаголы

| Выражают начало действия | Выражают продолжающиеся действия | Выражают завершённость действия |
|---|---|---|
| укый башлады<br>җырлый башлады<br>карый башлады | укып утыра<br>басып тора<br>яшәп ята | укып бетерде<br>кайтып китте<br>барып җитте |

**7.** Җөмләләрне укыгыз һәм аналитик фигыльләрне билгеләгез.

1) Мин бу китапны укып бетердем. 2) Рамил кызыклы фильм карап утыра. 3) Ничек яшәп ятасыз? 4) Сәхнәдә кызлар җырлый башлады. 5) Алар тугызынчы катка менеп җиттеләр. 6) Барысы да берьюлы сөйли башлады.

**8.** Аналитик фигыльләр кулланып, татарчага тәрҗемә итегез.

1) Наконец я закончил читать этот роман. 2) Я приду из школы и начну убираться дома. 3) Посреди поля стоит большой столб. 4) В зале зазвучала красивая мелодия. 5) Когда уроки закончились, мы пошли домой.

**9.** Хикәяне укыгыз. Сез малайга нинди киңәшләр бирер идегез?

**Өлгерәм әле...**

«Бүген мәктәптән кайтам да дәресләремне әзерләргә утырам», — дигән идем. Булмады. Әни мин яраткан ашны пешереп куйган. Әби дә: «Ашау эшне калдырмый, улым», — диде. Дәрес әзерләргә кичкә кадәр вакыт бар әле. Ашны ашадым. Ә аннары, үзегез беләсез, әлбәттә, ял итәргә кирәк. Диванга барып яттым. Йокыга киткәнмен. Наил уятты. Хоккей уйнарга соңга калганмын бит. Тиз генә йөгердем. Ә дәрес? Һи-һи-и... кичкә кадәр биш тапкыр әзерләп була әле аны.



Яхшы уйнадык та соң. Өйгә караңгы төшкәч кенә кайттым. Хәзер мин бер чынаяк чәй эчеп алырмын да дәрес әзерли башлармын инде. Юк, мультфильм карагач башлармын. Мультфильмнан соң кино башланды. Зыян юк, кино карагач та өлгерәм әле. Вакыт бар бит. Тик менә фильм ахырында күзләр йомыла башлады. Юк, бүген иртәрәк ятам әле. Ә дәресләрне иртәгә иртән торып әзерләрмен. Өлгерәм ич әле.

В. Нуриевтан

**10.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

[қа°йта́м], [йа°ратқа́н а°ш], [а°ша́w], [қа°лды́рмы̆ й], [йŏқŏға́], [уйат̄ы́], [қа°раңғы́], [чы̆найа́қ], [ба°шла́рмы̆н], [wа°қы́т], [дулқы́н], [ба°ғана́], [уқтучы́], [қәлә́м], [ризы́қ].

**11.** Хикәядән аналитик фигыльле җөмләләрне табыгыз, тәрҗемә итегез.

**12.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Бүген мәктәптән кайтам да ... . 2. Әни мин яраткан ... . 3. Әби: «Ашау эшне ...», — диде. 4. Дәрес әзерләргә ... . 5. Аш ашагач ... . 6. Наил хоккей ... . 7. Дәрес әзерләргә вакыт ... .

**13.** Хикәянең икенче абзацыннан билгесез киләчәк заман фигыльле җөмләләрне табыгыз, тәрҗемә итегез.

**14.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз. Текстның эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

1. Әни мин яраткан ашны пешереп куйган. 2. Дәрес әзерләргә кичкә кадәр вакыт бар әле. 3. Диванда йокыга киткәнмен. 4. Әби: «Ашау эшне калдырмый, улым», — диде. 5. Бүген мәктәптән кайтам да дәресләремне әзерләргә утырам. 6. Ашагач, диванга барып яттым. 7. Мине Наил уятты. 8. Тиз генә хоккей уйнарга йөгердем. 9. Хоккей уйнарга соңга калганмын икән.

**15.** Хикәядәге билгесез үткән заман хикәя фигыльләр белән җөмләләр төзегез.

**16.** Малайның теләкләрен (желания) хикәя эчтәлеге тәртибе буенча урнаштырыгыз.

1. Дәрес әзерләргә мультфильм карагач тотынырмын.
2. Дәрес әзерләргә кино карагач өлгерермен.
3. Дәрес әзерләргә бер чынаяк чәй эчкәч тотынырмын.

**17.** Как изменятся предложения упражнения 16, если мальчик твёрдо решил делать уроки?

**18.** Диалогны иптәшегез белән сөйләшергә өйрәнегез.

— Алло, Дима, сәлам! Син футбол уйнарга барасыңмы?
— Барам, барам. Мин йоклап киткәнмен.
— Тор инде. Малайлар җыелдылар.
— 10 минуттан стадионда булам.



# 14–15 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Шарт фигыль**
Условное наклонение

**Условное наклонение** выражает действие, являющееся условием для осуществления другого действия. Образуется путём прибавления к основе глагола аффикса **-са/-сә**: укыса́ (если прочитает), укы́маса (если не прочитает); сөйләсә́ (если расскажет), сөйлә́мәсә (если не расскажет).

**2.** Шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнеш таблицасын өйрәнегез.

| Берлек сан | | Күплек сан | |
|---|---|---|---|
| барлык формасы | юклык формасы | барлык формасы | юклык формасы |
| Мин кил-**сә-м** бар-**са-м** | Мин кил-мә-**сә-м** бар-ма-**са-м** | Без кил-**сә-к** бар-**са-к** | Без кил-мә-**сә-к** бар-ма-**са-к** |
| Син кил-**сә-ң** бар-**са-ң** | Син кил-мә-**сә-ң** бар-ма-**са-ң** | Сез кил-**сә-гез** бар-**са-гыз** | Сез кил-мә-**сә-гез** бар-ма-**са-гыз** |
| Ул кил-**сә** бар-**са** | Ул кил-**мә-сә** бар-**ма-са** | Алар кил-**сә-ләр** бар-**са-лар** | Алар кил-мә-**сә-ләр** бар-ма-**са-лар** |

**3.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

а) 1. Бер чынаяк чәй эчеп алсам, дәрес әзерли башлыйм. 2. Илшат чакырса, хоккей уйнарга барам. 3. Караңгы төшсә, өйгә кайтам. 4. Укытучы апа беренче мәсьәләне Наилдән сораса, мин икенче мәсьәләне чишәм. 5. Бүген икеле алмасам, иртәгә дәрес әзерләячәкмен. 6. Бүген котылсам, иртәгә дәрескә әзерләнәм дә әзерләнәм инде.

б) 1. Если папа придёт с работы пораньше, то мы пойдём на хоккей. 2. Если буду смотреть мультфильм, на подготовку уроков времени останется мало. 3. Если хорошо отдохнёшь, то легче выполнишь домашнее задание. 4. Если захочешь кушать, то на столе есть сметана и булочка.

**4.** 3 нче күнегүдәге җөмләләрдән фигыльләрне табыгыз, заманнарын билгеләгез.

**5.** 3 нче күнегү эчтәлегеннән файдаланып, диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

**6.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Мәктәптән иртә кайтсам, ... . 2. Дәресләрне әзерләсәң, ... . 3. Күп укысаң, ... . 4. Караңгы төшсә, ... . 5. Дуслар килсә, ... .

**7.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез, үзара сөйләшегез.

1. — ... ?
— Әйе, икеле алсам, кәефем китә.
— ... ?
— Ә бишле алсам, миңа рәхәт, гел укыйсы килә, кәеф яхшы була.

2. — Дима, безгә киләсеңме?
— Әни рөхсәт итсә, бүген кич киләм.
— Ә көндез нәрсә эшлисең?
— ... .

**8.** Как скажете о том, что если вы:

— хорошо выучите урок, то получите пятёрку;
— будете долго смотреть телевизор, то испортите глаза;
— подготовитесь к урокам, то будете чувствовать себя спокойно;
— будете списывать у товарища, то никогда не научитесь решать задачи?

## 16–17 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен языгыз, дөреслеген сүзлекләр белән тикшерегез.

әлбәттә — ...
зыян — ...
иртәрәк — ...
өлгерәм — ...
уяндым — ...

мәзәк — ...
кучерә — ...
чакыра — ...
ризык — ...
аңлады — ...

**2.** Нокталар урынына 1 нче күнегүдәге сүзләрне куеп языгыз.

1. Мәктәптән кайткач, ... , бер-ике сәгать ял итәргә кирәк. 2. Азат ... сөйләргә ярата. 3. Бүген мин ... уяндым. 4. Мин күп эшләр эшләргә ... . 5. Алсу өй эшен Азаттан ... . 6. Мин бүген бик соң ... .

**3.** Логик рәткә туры килмәгән сүзләрне табыгыз.

Кайтам, әзерлим, пешерәм, йоклыйм, ял итәм, уянам, иртән, барам, мәктәп, күчерәм, сөйлим, мәзәк.

**4.** Сүзләрнең логик парларын табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| иртән | | чиште |
| караңгы | | сөйли |
| мәсьәлә | ? | уянды |
| мәзәк | | төште |
| икеле | | куйды |
| мисал | | эшләде |

**5. Исегезгә төшерегез!**

**Инфинитив** отвечает на вопросы что делать? что сделать? **(нишләргә?)**, что не делать? что не сделать? **(нишләмәскә?)**.

Положительная форма инфинитива образуется путём присоединения к основе глагола на гласный звук аффиксов **-рга/-ргә**, к основе на согласный звук — аффиксов **-ырга/-ергә, -арга/-әргә**.

Инфинитив часто употребляется со словами:
**кирәк** — надо; **кирәкми** — не надо;
**ярый** — ладно, можно; **ярамый** — нельзя, невозможно;
**мөмкин** — можно; **мөмкин түгел** — невозможно, нельзя;
**була** — можно; **булмый** — нельзя;
**тиеш** — должен; **тиеш түгел** — не должен.

**6.** Үрнәк буенча тәрҗемәне дәвам итегез.

1. Ещё надо готовить уроки. — Әле дәрес әзерләргә кирәк.
   Ещё надо поесть суп. — ... .
   Ещё надо поиграть в хоккей. — ... .
   Ещё надо выполнить домашнее задание. — ... .

2. Оказывается, он опоздал играть в хоккей. — Ул хоккей уйнарга соңга калган икән.
   Оказывается, он опоздал смотреть фильм. — ... .
   Оказывается, он опоздал сделать уроки. — ... .

3. Когда приду в школу, спишу у Марата. — Мәктәпкә баргач, Мараттан күчерермен.
   Когда приду с хоккея, сделаю домашнее задание. — ... .
   Когда посмотрю фильм, сделаю уроки. — ... .
   Когда попью чай, начну готовить уроки. — ... .

**7.** Как скажете о том, что:

— до вечера ещё много времени;
— вы, наверное, до вечера успеете приготовить уроки;
— вы, наверное, утром пораньше встанете;
— вы, наверное, утром будете готовить уроки;
— вы спишете задачу у Наиля?

**8.** Җөмләләрне үрнәктәгечә киңәйтеп языгыз.

Мин ятам.
Мин бүген ятам.
Мин бүген иртәрәк ятам.
Мин бүген өйдә иртәрәк ятам.

Җ ө м л ә л ә р: дәрес әзерлим, мәсьәлә чишәм.

**9.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез.

1. — Азат, син нигә соңга калдың?
   — ... .
   — Син кичә дә соңга калгансың бит.

2. — Син кичә телевизор карадыңмы?
   — ... .
   — Мин дә мультфильм карадым. Мультфильмнан соң кино башланды. Ә син аны карадыңмы?

— ... .
— Мин дә йокыга киткәнмен.

3. — ... ?
— Мин өй эшен күчермәдем, үзем эшләдем.
— ... ?
— Кич, кино карагач эшләдем.
— ... ?
— Бүген дә үзем эшлим.

**10.** Сообщите другу о том, что вы:

— уже успели подготовиться к урокам;
— начали готовить уроки;
— начнёте готовить уроки, когда посмотрите программу «Время»;
— сегодня не успели приготовить уроки;
— сами не решили задачу, а списали её у Айдара;
— получили пятёрку по татарскому языку.

## 18–20 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен исегезгә төшерегез.

**әле** — ещё
**кадәр** — до
**инде** — уже
**я** — или
**соң** — после
**бит** — ведь
**гына, генә** — только
**кебек** — словно

**2.** «Өлгерәм әле...» хикәясенең 2–3 нче абзацларын укыгыз. Икенче көнне хикәя герое белән нинди хәлләр була?



### Өлгерәм әле...
(дәвамы)

Шулай иттем. Иртән иртәрәк уяндым. Уяндым гына. Тормадым. «Өй эшен, мәктәпкә килгәч, Наилдән генә күчерермен», — дип уйладым. Вакыт бар бит әле.

Мәктәптә Наил барысына да мәзәк сөйләп көлдерә иде. Каян гына сүзен таба! Бүген дә үтерде генә инде. Әле тагын сөйләргә җыенган иде. Вакыт җитмәде. Дәрес башланды.

Укытучы апа беренче мәсьәләне Наилдән сорагач, тәнем буйлап җылы-йомшак дулкын йөгерде. Димәк, Наил сөйләгәндә, мин өйгә бирелгән икенче мәсьәләне чишәм, я арткы партадагы Дамирдан күчерәм. Вакыт бар бит. Тик мин мәсьәләне укып та өлгермәдем — Наил үзенекен чиште дә бетерде. Укытучы апа икенчесенә мине чакырды. Класс алдында багана кебек басып тордым. Укытучының каләменә карыйм. Бөтен теләгем: икеле генә куймасын. Бүген котылсам, өйгә кайткач, дәрес әзерләргә утырырмын. Аңламады Мөршидә апа — миңа икеле куйды. Ә кичә физика укытучысы Кәрим абый аңлады. «Иртәгә әзерләнеп киләм», — дип сүз бирдем. Шуңа күрә ул икеле куймады. Әгәр бүген дә куймаса, киләсе дәрескә әзерләнәм дә әзерләнәм инде. Бернинди ризык та капмам. Юк, тамак ялгарга кирәк булыр. «Ашау эшне калдырмый», — ди бит әбием.

В. Нуриевтан

**күчерермен** — спишу
**үтерде** — здесь: поразил
**куй** — здесь: поставь
**котылсам** — здесь: если пронесёт

**3.** Хикәядән шарт фигыль булган җөмләләрне табыгыз, зат-сан белән төрләнешен билгеләгез.

**4.** 2 нче күнегүдән файдаланып, таблицаны тутырыгыз.

| Инфинитив | Хәл фигыль | Шарт фигыль | Боерык фигыль |
|---|---|---|---|
| | | | |

**5.** План пунктларын хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

1. Наил такта янында мәсьәләне чишеп бетерде.
2. Өйгә караңгы төшкәч кенә кайттым.
3. Әни мин яраткан ашны пешергән.
4. Укытучы апа такта янына мине чакырды.

**6.** Әйтик, хикәя героеның исеме — Артур. Сез бу раслаулар белән килешәсезме?

1. Артур иртән иртәрәк уянды, ләкин тормады.
Артур иртән иртәрәк уянды һәм торды.

2. Артур иртән иртәрәк уянды һәм дәресләрен әзерләде.
Артур иртән иртәрәк уянды, ләкин дәресләрен әзерләмәде.

3. Артур: «Өй эшен, мәктәпкә баргач, үзем эшләрмен», — дип уйлады.
Артур: «Өй эшен, мәктәпкә килгәч, Наилдән күчерермен», — дип уйлады.

4. Артур мәктәптә өй эшен эшләде.
Артур мәктәптә Наилне тыңлады, ә ул мәзәк сөйли иде.

5. Наил мәсьәләне бик озак чиште.
Наил мәсьәләне бик тиз чиште.

6. Укытучы апа икенче мәсьәләне чишәргә Наилне чакырды.
Укытучы апа икенче мәсьәләне чишәргә Артурны чакырды.

7. Укытучы Мөршидә апа Артурга икеле куймады.
Укытучы Мөршидә апа Артурга икеле куйды.

8. Артур вакытында дәрес әзерләргә үз-үзенә сүз бирде, ләкин сүзендә тора алмады.
Артур вакытында дәрес әзерләргә үз-үзенә сүз бирде һәм сүзендә торды.

**7.** 5 нче күнегүдәге дөрес раслауларга сораулар куегыз, дәфтәрегезгә языгыз.

**8.** Бу диалоглар хикәянең кайсы абзацларына туры килә? Диалогларны иптәшегез белән сөйләргә өйрәнегез.

1. — Артур, тор, әйдә урамга чыгабыз.
— Урамда малайлар бармы?
— Әйе, алар хоккей уйныйлар. Әйдә тизрәк, соңга калабыз.
— Хәзер, мин бик тиз киенәм.

2. — Улым, син ашарга утыр.
— Рәхмәт, әбием, хәзер утырам.
— Аш тәмлеме?
— Әйе, бу минем яраткан ашым.

3. — Улым, дәресләреңне әзерләдеңме?
— Юк әле, менә бер чынаяк чәй эчәм дә аннан соң әзерлим.

4. — Сезнең сыйныфта балалар мәзәкләр беләме?
— Бездә иң оста сөйләүче — Наил. Ул бик күп мәзәкләр белә.

5. — Абый, бүген икеле куймагыз инде, иртәгә әзерләнеп килермен.
— Сүзеңдә торасыңмы?
— Әйе, сүз бирәм.

**9.** Хикәянең 2–3 нче абзацларын III зат исеменнән сөйләргә өйрәнегез.

**10.** Диалогларга тиешле репликаларны куеп укыгыз. Иптәшегез белән сөйләшергә өйрәнегез.

1. — Әйдә урамга чыгабыз.
— … .
— Өй эшләрең күпме?
— … .
— Кайчан эшләп бетерәсең?
— … .

2. — Катя, син өй эшләрен вакытында эшлисеңме?
— … . Ә син?
— … . …?
— Юк, күчермәдем, үзем чиштем.

**11.** Найдите в последнем абзаце текста предложения, подтверждающие слабохарактерность героя рассказа.

**12.** Таблицадан файдаланып, хикәя герое турында языгыз.

| Нинди укучы? | Өй эшен ничек әзерли? | Үз-үзен ничек тота? |
|---|---|---|
| Яхшы.<br>Начар.<br>Тырыш.<br>Ялкау.<br>Игътибарлы.<br>Игътибарсыз. | Өй эшен вакытында әзерли.<br>Өй эшен вакытында әзерләми.<br>Өй эшен оныта.<br>Көндәлеккә өй эшен яза.<br>Көндәлеккә өй эшен язмый. | Борчыла.<br>Борчылмый.<br>Үз-үзенә сүз бирә.<br>Үз сүзендә тора алмый.<br>Үз сүзендә тора. |

## 21–22 нче дәресләр

**1.** «Өлгерәм әле…» хикәясен искә төшерегез. Әйтик, хикәя герое — тырыш, үз сүзендә торучан укучы. Хикәя ничек үзгәрер? Яңа хикәя язып карагыз.

**2.** Шигырьне укыгыз. Барый белән «Өлгерәм әле...» хикәясе герое арасында нинди уртаклык бар?

### Барый телевизор карый

Укуына күңел салмый,
Китабын кулга да алмый,
«Бүген укымый да ярый,
Иртәгә укыйм», — дип, Барый
Көн дә телевизор карый.



Карый иртән торгач та,
Карый өйлә узгач та,
Карый карап аргач та,
Ике күзе талгач та.
Китаплары көтеп арый,
Дәфтәрләре көтеп арый,
Барый телевизор карый,
Көн дә: «Бүгенгә, — ди, — ярый».

Кояш бата, ай калка,
Барый йокларга ята,
Иртәгесен сумкасына
Икеле төяп кайта.
«Нәрсә карый бу Барый?» — дип,
Бөтен класс шакката.

Ә ул телевизор карый,
Карый-карый тәмам арый.
Шулай көн дә арый-арый,
«Бүгенгә, — дип, — ярый-ярый»,
Телевизор карый-карый,
Классында калды Барый...

Р. Вәлиева

**өйлә** — обед
**аргач** — устав
**күзе талгач** — когда устали глаза
**шакката** — удивляется
**күңел салмый** — делает без желания
**арый** — устаёт

3. Найдите строки стихотворения, которые характеризуют слабохарактерность героя.

4. 27 нче биттәге таблица аша шигырь герое Барыйга характеристика бирегез. Барый «Өлгерәм әле...» хикәясе герое белән ничек охшаш?

5. Ничек уйлыйсыз, көндәлек эшләрне ни өчен планлаштырырга кирәк? Төркемнәрдә фикерләшегез, сөйләргә өйрәнегез.

6. Скажите о том, чтобы хорошо учиться:

— надо планировать свои дела заранее;
— надо уметь вовремя выполнять запланированные дела;
— нельзя оставлять сегодняшние дела на завтра.

## 23–24 нче дәресләр

1. Язучы һәм галим Мөхәммәт Мәһдиев турында укыгыз һәм «Без — кырык беренче ел балалары» әсәреннән өзек (отрывок) белән танышыгыз.



Мөхәммәт Мәһдиев — язучы һәм галим. Ул 1930 нчы елның 1 нче декабрендә Арча районының Гөберчәк авылында туа. Ул Арча педагогика училищесын, Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлый. Озак еллар университетта студентларга лекцияләр укый. Яшьләр һәм өлкәннәр яратып укый торган повесть-романнар иҗат итә. Язучы 1995 елда вафат була. Ләкин әсәрләре белән ул һаман безнең арада (среди нас) — укытучылар, студентлар, укучылар арасында.

**Рус теле дәресендә**

*(Әсәрдәге вакыйга Бөек Ватан сугышы елларында бара. Авыл малайлары һәм кызлары педучилищега килеп белем алалар.)*

Бүген безнең класста яңалык: дүрт дәрестән соң педучилищедан Гыйззәтуллин качты. Барысы да юктан гына булды: рус теле укытучысы аннан:

— Что было задано на дом? — дип сорады. Бу бик гади сорау иде, ләкин Гыйззәтуллин коелып төште. Борынын тарта-тарта, ул бер җөмлә эчендә буталды да буталды.

— Надание на дом... Надание на дом... занадо за ном... — дип озак газапланды, тирләде.

Рус теле укытучысы аңа тактада бер җөмлә язарга кушты.

Гыйззәтуллин тактага: «Карим опоздал на урок», — дип язып куйды. Эш бик җиңел — иянең астына бер сызык, хәбәргә ике сызык сызарга да шуны русча сөйләргә кирәк иде.

Гыйззәтуллин, әлбәттә, боларны эшли ала иде. Ул ияне дә, хәбәрне дә тапты. Ләкин укыганда, «урок» сүзендәге басымны беренче иҗеккә күчереп харап булды.

Укытучы моңа бик зур игътибар бирде. Сүзне башта иҗекләп, аннан бөтене белән әйттерде. Әйбәт чыга. Ләкин шуны җөмләсе белән укыганда, басым яңадан беренче иҗеккә күчеп утыра. Менә бәла!

— Шушы сүзне дөрес укымыйча торып, алга таба бара алмыйбыз, — ди ул. Гыйззәтуллин инде үз-үзенә ышанмый, аның күзләре җансыз, пыяла...

— Син өметеңне җуйма, Гыйззәтуллин, — ди аңа укытучы. — Әгәр училищены тәмамлаганчы миндә укысаң, син барыбер русчаны бик әйбәт беләчәксең. Мин моңа ирешәчәкмен. Минем изге бурычым ул, аңладыңмы?

Кыңгырау, чылтырап, Гыйззәтуллинны бу хәленнән коткарды. Ләкин шул көнне аның училищедан качуына ачуыбыз килде. Ни өчен ачуыбыз килде?

Моны без ул вакытта аңламадык. Күп еллар үткәч кенә, бернәрсә аңлашылды: шул көннән башлап без Мәскәү татарын ярата башлаганбыз икән...

**юктан гына булды** — из ничего, из-за пустяка
**коелып төште** — растерялся
**бәла** — беда
**куллары калтырый** — руки дрожат
**бөтене белән** — в целом
**өметеңне җуйма** — не теряй надежды

М. Мәһдиев турында күбрәк бел

**2.** Текстны план буенча өлешләргә бүлеп укыгыз.

1. Безнең класста яңалык.
2. Өй эшен искә төшерү.
3. Гыйззәтуллин басымны дөрес күчермәде.
4. Безнең Гыйззәтуллинга ачуыбыз килде.

**3.** Нокталар урынына бирелгән сүзләрдән хәл фигыльләр ясап, җөмләләрне укыгыз.

1) Гыйззәтуллин училищены *(ташлый)* качты. 2) Сүзне башта *(бутый)* әйтте. 3) Гыйззәтуллин сүзне *(кычкыра)* әйтте. 4) *(Тырыша)* укысаң, рус телен әйбәт беләчәксең. 5) Күп еллар *(үтә)* кенә аңладым.

**4.** Бирелгән сүзләр һәм сүзтезмәләр кергән җөмләләрне тексттан табып укыгыз.

Коелып төште, борынын тарта-тарта, буталды да буталды, харап булды, игътибар бирде, үз-үзенә ышанмый.

**5.** Тәрҗемәне үрнәк буенча дәвам итегез.

Үрнәк: Ул: «Без соңга калдык», — дип язып куйды.— Он написал: «Мы опоздали».

1) Ул: «Өй эше нәрсә турында иде?» — дип сорады.
2) «Максатыңа һәрвакыт ирешергә тырыш», — ди әнием.
3) «Тырышлык — зурлык, ялкаулык — хурлык», — ди татар халкы.

**6.** Фикерләрне тексттагы җөмләләр белән дәлилләгез.

1) Гыйззәтуллин рус телен начар белә иде.
2) Гыйззәтуллин сүздә басымны дөрес куймады.
3) Укытучы рус теле өйрәтүгә җитди карый иде.
4) Гыйззәтуллин үз-үзенә ышанмый иде.
5) Мәскәү татарын ярата башлаганбыз икән.

**7.** Рус теле укытучысының «Мин моңа ирешәчәкмен. Минем изге бурычым ул» дигән сүзләрен сез ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә фикерләшегез.

**8.** Әсәрне сәнгатьле укырга өйрәнегез.

## 25–26 нчы дәресләр

**1.** Өзектән бирелгән җөмләләргә туры килгән өлешләрне табып укыгыз.

1) Гыйззәтуллин өй эшен әйтә алмады.
2) Гыйззәтуллин сүзгә басымны дөрес куймады.
3) Укытучы өйрәтергә тырышты.
4) Классташларының Гыйззәтуллинга карашы.
5) Укучыларның укытучыга карашы.

**2.** Ике раслауның кайсы дөрес?

1) Гыйззәтуллин рус теле дәресендә харап булды.
Гыйззәтуллин биология дәресендә харап булды.

2) Гыйззәтуллин: «Карим опоздал на урок», — дип дөрес әйтте.
Гыйззәтуллин: «Карим опоздал на урок», — дип дөрес әйтмәде.

3) Гыйззәтуллин «урок» сүзенә басымны дөрес куйды.
Гыйззәтуллин «урок» сүзенә басымны дөрес куймады.

4) «Урок» сүзендә басымны икенче иҗеккә куйды.
«Урок» сүзендә басымны беренче иҗеккә куйды.

5) Рус теле укытучысы бик җитди иде.
Рус теле укытучысы бик усал иде.

6) «Урок» сүзендә басым беренче иҗеккә төшә.
«Урок» сүзендә басым икенче иҗеккә төшә.

7) Гыйззәтуллин рус телен бөтенләй белми.
Гыйззәтуллин рус телен ярыйсы (удовлетворительно) гына белә.

8) «Училищены тәмамлаганчы, сине рус теленә өйрәтү — минем бурычым», — диде укытучы.
«Училищены тәмамлаганчы, сине рус теленә өйрәтә алмыйм», — диде укытучы.

**3.** Әсәрнең үзегезгә ошаган өлешен сәнгатьле укырга өйрәнегез.

**4.** Сез бу раслаулар белән килешәсезме?

1) Гыйззәтуллин бик ялкау, шуңа күрә рус телен белми.

2) Гыйззәтуллинга рус телен өйрәнү авыр, чөнки ул татар авылында үскән.

3) Рус теле укытучысы бик усал, укучыларны яратмый.

4) Рус теле укытучысы үз фәнен яхшы белә.

5) Классташлары Гыйззәтуллинны сагыначаклар.

6) Гыйззәтуллинның классташлары рус телен өйрәнәчәкләр.

**5.** Бу җөмләнең эчтәлеген ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә фикерләшегез.

«Күп еллар үткәч кенә, бернәрсә аңлашылды: шул көннән башлап без Мәскәү татарын ярата башлаганбыз».

6. Сорауларга җавап бирегез.

1) Укучылар кайда укыйлар?
2) Укучылар нинди милләттән?
3) Аларга рус телен өйрәнү җиңел булганмы?
4) М. Мәһдиев әсәреннән өзек сезгә ошадымы? Ни өчен?

7. Скажите, что:

— Марат вышел к доске;
— он нашёл в предложении подлежащее и сказуемое;
— он поставил ударение правильно;
— вы не поняли задание;
— вы подчеркнули подлежащее.

8. Как скажете о том, что ваша задача — знать в совершенстве три языка: русский, татарский, английский?

9. Узнайте у друга:

— кто их классный руководитель;
— сколько ударников в их классе;
— какой иностранный язык он изучает.

10. Күп телләр белү кешегә нәрсә бирә? Төркемнәрдә сөйләшегез.

11. При составлении текста на татарском языке, ученик допустил ошибки в порядке слов в предложении. Исправьте ошибки и запишите текст в тетрадь.

Безнең булды дәрес татар теле. Дәрестә без укыдык әсәре М. Мәһдиевнең «Без — 41 нче ел балалары». Миңа бик ошады геройлар әсәрнең. Мин яратам укырга татарча китаплар.

12. Елмаеп алыйк әле!



Укытучы:
— Балалар, «Кыз бала ял итә» дигән җөмлә языгыз, фигыльне табыгыз.
— Монда фигыль юк бит, апа, — ди бер укучы.
— Фигыль «нишли?» дигән сорауга җавап бирә, ә кыз бала бернәрсә дә эшләми, ял итә.

# 27–28 нче дәресләр

**1.** Бу сүзләрнең тәрҗемәсен табыгыз, дөрес укырга өйрәнегез. Алар сезгә халык шагыйре Фәнис Яруллинның тормыш юлы турындагы язманы аңларга ярдәм итәр.

[хәбә́р], [тормо̆́ш], [оно̆тмы̆́й], [тәмамлы̆́й], [шөғө̆л̄әнә́], [йаᵒзмышы̆́], [хы̆йал̄а́р], [йы̆гы̆лы̆́п төшә́], [шиғә̆́р]

**2.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз.

| | ? | |
|---|---|---|
| туа | | башлый |
| тәмамлый | | зур |
| кечкенә | | авыр |
| җиңел | | шатлык |
| кайгы | | аз |
| күп | | үлә |

**3.** Саннарны үрнәк буенча языгыз.

Үрнәк: Биш — бишенче.
2, 9, 14, 25, 36, 103, 1938, 1957.

**4.** Татарстан Республикасының халык шагыйре Фәнис Яруллин турында укыгыз. Ни өчен без аны «татар Корчагины» дип атыйбыз? Аның батырлыгын ничек аңлыйсыз?

### Татар Корчагины



Фәнис Яруллин 1938 нче елның 9 нчы февралендә Татарстанның Баулы районында туа. Фәнискә 4 яшь вакытта аның әтисе фронтка китә, һәм тиздән аның үлеме турында хәбәр килә.

Гаиләдә бишенче бала булып үскән Фәнискә тормыш җиңел булмый. Җәй буе колхозда эшли. Ләкин ул укуны да онытмый, белемле булырга омтыла. Егет Баулыда урта мәктәпне тәмамлый.

1957 нче елда Фәнис армиягә китә. Армиядә ул спорт белән шөгыльләнә, киләчәк турында хыяллана.

Ләкин бәхетсезлек язмышны икенче якка бора да куя...

Турникта әйләнгәндә, егылып төшеп, Фәнис умыртка сөяген имгәтә, йөри алмас хәлгә килә. Ләкин ул югалып калмый, яшәргә омтыла. Фәнис Яруллин читтән торып Казан дәүләт университетын тәмамлый, хикәяләр, шигырьләр иҗат итә башлый.

Фәнис Яруллин — өч дистәдән артык китап авторы.

Аның шигырьләрен, проза әсәрләрен өлкәннәр дә, кечкенәләр дә яратып укый. Ул — Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының халык шагыйре.

Фәнис Яруллин шигырьләре

**хыял** — мечта
**дистә** — десяток
**умыртка сөяге** — позвоночник
**мәртәбәле** — авторитетный
**имгәтә** — калечит
**йөри алмас хәлгә килә** — потерял способность самостоятельно передвигаться

**5.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1) Фәнис Яруллин 1938 нче елның ... . 2) Фәнискә 4 яшь вакытта ... . 3) Фәнис җәй буе ... . 4) Егет Баулыда ... . 5) Ул укуны да онытмый, ... . 6) Армиядә Фәнис умыртка сөяген ... . 7) Фәнис Яруллин читтән торып ... .

**6.** Диалогка төшеп калган репликаларны өстәгез, сөйләргә өйрәнегез.

— ... ?
— Әйе, минем Фәнис Яруллин турында ишеткәнем бар.
— Ул кайда һәм кайчан туган?
— ... .
— Фәнис Яруллинның тормышы турында сөйлә әле.
— ... .
— Ни өчен без аны «татар Корчагины» дип атыйбыз?
— ... .
— Синең Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» дигән повестен укыганың бармы?
— ... .

**7.** Узнайте у друга, что он знает о Фанисе Яруллине, что с ним случилось во время службы в армии.

**8.** Посоветуйте другу:

— познакомиться с биографией Ф. Яруллина;
— прочитать книгу Ф. Яруллина «Упругие паруса» («Җилкәннәр җилдә сынала»).

**9.** Шигырьне укыгыз.

### Ялкау ялы

Әти әйтә: «Әй, улым,
Бигрәк әллә нинди син.
Эш турында әйтмим дә,
Ял итә дә белмисең».
Ял итәргә аңарга
Нинди белү кирәктер?!
Минем кебек ял иткән
Болай да бик сирәктер.
Көннәр буе өйдә мин,
Ятамын гел диванда.
Телевизор карыймын
Мультфильмнар булганда.
Йөгермимен, чапмыймын,
Сазга батып кайтмыймын.
Чапсын әйдә юләрләр,
Мин аякны саклыймын.
Киерелеп, сузылып
Ял итәм дә ял итәм.
Әнә шулай ял итеп,
Кай көнне арып бетәм.
Бәйләнәләр гел юкка,
Кызык та бу өлкәннәр.
Әйтерсең лә үзләре
Миннән шәп ял иткәннәр.

Ф. Яруллин

**10.** Сорауларга җавап бирегез.

1) Малай ничек ял итә? Аның «Барый телевизор карый» шигыре герое белән нинди уртак яклары бар?

2) «Киерелеп, сузылып
Ял итәм дә ял итәм.
Әнә шулай ял итеп,
Кай көнне арып бетәм» дигән юлларга шагыйрь нинди мәгънә салган?

**11.** Шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнегез.

# 29–30 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Исем фигыль**
Имя действия

**Имя действия** — это часть речи, которая одновременно обладает признаками и глагола (обозначает процесс или действие, имеет отрицательную форму), и имени существительного (склоняется по числам, падежам и принадлежности). Отвечает на вопрос «нишләү?» и образуется путём добавления к основе глагола аффикса **-у/-ү**: кайт**у** (возвращение), кит**ү** (уход). Например: Һөнәр сайлау — җаваплы эш. Дөрес тукланмау организмга зыян китерә.

В речи часто встречается конструкция **исем фигыль + өчен**: Яхшы **уку өчен** тырышырга кирәк. Белемле **булу өчен** күп укырга кирәк.

2. Җөмләләрне дәвам итегез.

1) Яхшы уку минем үзем өчен ... . 2) Яхшы уку өчен тырышу ... . 3) Дәресләр материалны начар белүгә ... . 4) Дәрескә соңга калу — начар ... . 5) Өй эшләрен иптәшеңнән күчерү — ... .

3. Яхшы уку өчен, сез дустыгызга нинди киңәшләр бирер идегез? Җавапларны, исем фигыльләр кулланып, дәфтәрегезгә языгыз.

Ү р н ә к: Яхшы уку өчен бик тырышу кирәк.

4. Спросите у друга:

— когда он встаёт утром;
— делает ли он зарядку;
— во сколько часов начинаются уроки в школе;
— во сколько часов кончаются уроки в школе;
— во сколько часов он ложится спать.

5. Узнайте у друга:

— есть ли у него дома рабочее место;
— что у него есть на рабочем месте;
— в какое время он начинает готовить домашние задания;
— какие предметы он готовит сначала, какие — потом;
— какие уроки ему нравятся.

6. Подумайте и заполните таблицу.

| | Когда происходят действия? | Аффиксы к глаголам | Время глаголов |
|---|---|---|---|
| 1 | Действия происходят сейчас | ... | ... |
| 2 | Действия уже произошли | ... | ... |
| 3 | Действия произошли, но вы не видели | ... | ... |
| 4 | Действия обязательно произойдут | ... | ... |
| 5 | Возможно, действия произойдут | ... | ... |

7. «Уку — энә белән кое казу», «Тырышлык — зурлык, ялкаулык — хурлык» дигән мәкальләрне ничек аңлыйсыз? Бу мәкальләрнең сез укыган әсәрләр белән уртаклыгы нәрсәдә? Төркемнәрдә киңәшегез. Фикерләрегезне дәфтәргә языгыз.



# ЯШЬТӘШЛӘР БЕЛӘН АРАЛАШУ

## 31–32 нче дәресләр

**1.** Сүзләр һәм сүзтезмәләрне тәрҗемә итегез.

Общение, общаться, спорить, разговаривать, обмениваться мыслями, правила общения, из поколения в поколение, спокойным голосом, интересный разговор, унижать строго запрещается.

**2.** Текстны укыгыз. Аңа нинди исем бирер идегез?

Тормышта кешеләр гел аралашып яшиләр: көнкүрештә, гаиләдә, эш урыннарында туганнар, дуслар, хезмәттәшләр белән сөйләшәләр, фикер алышалар, бәхәсләшәләр.

Аралашуның билгеле бер кагыйдәләре була. Бу кагыйдәләр кешеләрнең төрле урыннарда үз-үзләрен тоту үрнәкләрен билгели, буыннан буынга тапшырылып килә.

— Аралашканда, тыныч тавыш белән сөйләшергә кирәк.

— Аралашканда, урынсыз бәхәскә, конфликтка керергә, усаллыкка барырга һич ярамый.

— Үзеңне иркен тотып, кызыклы итеп сөйләшү дә әһәмиятле.

— Әңгәмәдәшеңне бүлдерми тыңлау, үзеңне аның белән бер дәрәҗәгә куеп сөйләшү дә бик мөһим.

— Әңгәмәдәшеңне түбәнсетү, сөйләмдә мәгънәсез сүзләр куллану катгый тыела.

— Негатив сөйләшүдән качарга, зарланмаска кирәк.

— Үз проблемаларында башка кешене гаепләп сөйләргә ярамый.

**3.** Фигыльнең инфинитив формасын искә төшерегез. Тексттагы инфинитив формасындагы фигыль кушымчаларының ялгану тәртибен аңлатыгыз.

**4.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1) Тормышта кешеләр гел ... .
2) Кешеләр гаиләдә аралашалар, эш урыннарында ... .
3) Аралашуның билгеле ... .
4) Аралашканда, ... .
5) Аралашуда мөһим кагыйдәләр: ... .
6) Үзеңне иркен тотып, кызыклы итеп ... .
7) Бу кагыйдәләр ... .

**5.** Җөмләләрне укыгыз, тәрҗемә итегез. Һәр парның икенче җөмләсенә нәрсә өстәлгән, шуларны билгеләгез.

1) Тормышта кешеләр аралашып яшиләр.
Тормышта кешеләр гел аралашып яшиләр.

2) Аралашуның кагыйдәләре була.
Аралашуның билгеле бер кагыйдәләре була.

3) Аралашканда, урынсыз бәхәскә, конфликтка керергә һич ярамый.
Аралашканда, урынсыз бәхәскә, конфликтка керергә, усаллыкка барырга һич ярамый.

4) Үзеңне иркен тотып сөйләшү дә әһәмиятле.
Үзеңне иркен тотып, кызыклы итеп сөйләшү дә әһәмиятле.

5) Әңгәмәдәшеңне бүлдерми тыңлау да бик мөһим.
Әгәр фикерең булса, әңгәмәдәшеңне бүлдерергә дә мөмкин.

**6.** 2 нче күнегүдәге текстка сораулар әзерләп, партадашыгыз белән сөйләшегез.

**7.** 2 нче күнегүдә күрсәтелгән аралашу кагыйдәләрен ни өчен үтәргә кирәклеге турында төркемнәрдә фикер алышыгыз. Фикерләрегезне тормыштан мисаллар белән дәлилләгез (аргументируйте).

**8.** Текстны укыгыз. Уйлагыз, гаеп кемдә?

### Гаеп кемдә?

— Бездә бөтен малайлар да тәртипсез, — дип, Клара үз сыйныфындагы малайлардан зарлана. — Шундый тупаслар инде, мине «кире Клара» дип кенә йөртәләр.

— Ә син үзең аларга ничек дип эндәшәсең? — диде әнисе.

— Минем аларга эндәшкәнем юк.

Гаеп кемдә?

**9.** Яшьтәшләре белән аралашу өчен, Кларага нинди киңәшләр бирерсез? Дәфтәрегезгә языгыз.

# 33–36 нчы дәресләр

**1.** Алсу «Ялкын» журналына менә нинди хат язып җибәргән. Сез аның сорауларына ничек җавап бирер идегез?

**Аралашу серләре**



Кызык... Ни өчен берәүләрне яраталар, берәүләрне юк? Кайбер малайлар, кызлар белән күпләр дус була ала, ә кайберәүләр белән озак дуслашып булмый.

Мәктәптәге дус кызларым малайларның әдәпсез, тупас кыланышларына рәнҗиләр. Ә үзләре оялчан, кызара белә торган яисә артык ябык, я артык таза егетләрдән көләләр.

Кайбер малайларыбыз әдәпле булырга оялалар. Әдәпле булу модада түгел, дип уйлыйлар.

Минем фикеремчә, әдәпле кешеләр түгел, ә тупас, тәрбиясез кешеләр оялырга тиеш.

Ә кайбер кызлар һәм малайлар белән, киресенчә, модалы киенмәсәләр дә, аралашу рәхәт. Чөнки алар сине тыңлый беләләр, синнән көлмиләр, кимчелекләреңне гафу итә алалар. Бәлки, мин искечә фикер йөртәмдер...

**берәүләр** — одни
**кайберәүләр** — некоторые
**кыланыш** — поступок, выходка
**рәнҗиләр** — обижаются
**киресенчә** — наоборот
**кимчелек** — недостаток

**2.** Тәрҗемәгә туры килгән җөмләләрне тексттан табып укыгыз.

1. Почему-то одних любят, других нет. 2. В школе некоторых моих подруг обижают выходки грубых, невоспитанных мальчиков. 3. Некоторые мальчики и девочки стесняются быть вежливыми. 4. Помоему, должны стесняться не воспитанные люди, а, наоборот, грубые, невоспитанные. 5. Потому что они тебя умеют слушать, умеют прощать твои недостатки.

**3.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Кайбер кызлар һәм малайлар белән күпләр дус була ала, ә ... . 2. Кайбер дус кызларым малайларның ... . 3. Ә үзләре оялчан ... .

4. Минем фикеремчә, әдәпле кешеләр түгел, киресенчә, ... . 5. Кайбер малайларга кызлар белән аралашу рәхәт, чөнки ... .

**4.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Кызлар малайларның нинди кыланышларына рәнҗиләр?
2. Шулай да кызлар нинди малайлардан көләләр?
3. Кайберәүләр үзләренең нинди сыйфатларыннан оялалар?
4. Нинди кешеләр белән аралашу җиңел?
5. Алсу искечә фикер йөртмиме?

**5.** Алсуның төп фикерләрен дәфтәрегезгә языгыз. Сез аның белән килешәсезме? Төркемнәрдә үзара фикерләшегез.

**6.** «Кайбер малайлар әдәпле булырга оялалар» дигән фикерне ничек аңлыйсыз? Үзара аралашудан нинди мисаллар китерә аласыз?

**7.** Сезнең фикерегез нинди? Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Минемчә, оялчан, кызара белә торган егетләр ... . 2. Минем уйлавымча, әдәпле булу модада түгел, дип уйлау ... . 3. Әлбәттә, модалы киемнәр белән аерылып тору ... . 4. Минем фикеремчә, кешене тыңлый, кимчелекләрен гафу итә белү ... .

**8.** Как скажете о том, что:

— скромность украшает человека;
— грубость, невоспитанность не украшают людей;
— застенчивость не всегда положительная черта характера;
— грубые выходки обижают окружающих;
— твои друзья все воспитанные;
— нельзя обижать девочек;
— нельзя смеяться над недостатками людей;
— нельзя постоянно критиковать других?

**9.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

1. Он часто обижается, по-моему, это плохая привычка.
2. Мы с друзьями встречаемся часто и весело проводим время.
3. С воспитанными людьми легко общаться, потому что они умеют внимательно слушать.
4. Умение интересно рассказывать — это тоже талант.

**10.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Кеше тәрбияле булса, аның белән ... .
2. Кеше кичерә белсә, аның белән ... .
3. Кеше тупас булса, аның белән ... .
4. Кеше оялчан булса, аның белән ... .

## 37–39 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

Үз фикереңне ничек белдерергә?

1) **риза** — согласен
2) **әйе, мин риза** — да, я согласен
3) **риза түгел** — не согласен
4) **юк, мин риза түгел** — нет, я не согласен
5) **юк, минем уйлавымча, алай түгел** — нет, по-моему, не так
6) **әйе, минемчә, бу дөрес** — да, по-моему, это правильно
7) **әйе, мин дә шулай уйлыйм** — да, я тоже так думаю

**2.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме? Төркемнәрдә фикерләшегез. Фикерләрегезне тормыштан мисаллар белән дәлилләгез (аргументируйте).

— Әдәп кагыйдәләрен һәрвакыт үтәргә кирәк.
— Әдәп кагыйдәләрен өйдә үтәмәсәң дә ярый.
— Әдәп кагыйдәләрен үтәмәсәң, кешеләр сине яратмый.
— Әдәп кагыйдәләрен үтәмәсәң дә, дуслар сине яратырга тиеш.
— Әдәп кагыйдәләрен өлкәннәр янында үтәсәң дә җитә.

**3.** Татарчага тәрҗемә итегез. Эчтәлек буенча үзара сөйләшегез.

а) Умеем ли мы слушать друг друга и слышим ли друг друга? Во-первых, в разговоре не надо перебивать друг друга: выслушай до конца, потом скажи сам. Во-вторых, поменьше говори о себе, не привлекай внимания громким голосом, смехом, жестами.

б) Если у товарища плохое настроение, то постарайся его развеселить. Но если горе или беда, то не шути. Твоя шутка может обидеть человека.

в) Как быть, если тебя оскорбили грубым словом? Не следует отвечать тем же и опускаться до уровня первобытного человека.

4. Кешеләр белән аралашу өчен, сез нинди кагыйдәләр үтәргә тиеш? Үзегезнең фикерләрегезне дәфтәрегезгә языгыз. Язган фикерләрегезне партадашыгызга сөйләгез.

5. Бу мәкальләрне ничек аңлыйсыз?

Әдәп төбе — матур гадәт.
Сөйдергән дә тел, биздергән (вызывающий отвращение) дә тел.

6. Әдәплелек турында русча нинди мәкальләр беләсез?

7. Үзегезгә ошаган мәкаль эчтәлеге буенча кечкенә хикәя языгыз.

8. У «спасибо» есть великая сила. Придумайте ситуации общения, когда мы говорим ровесникам, взрослым волшебное слово «спасибо». Составьте диалоги, поговорите друг с другом.

9. **Исегездә калдырыгыз!**

**Неопределённые местоимения** указывают на неопределённость лица или предмета, признака, количества, образа действия и некоторых процессов. Они образуются от вопросительных местоимений двумя способами:

1) присоединением к местоимениям частицы **-дыр/-дер (-тыр/-тер)**: **кемдер** (кто-то), **нәрсәдер** (что-то), **кайдадыр** (где-то), **ниндидер** (какой-то), **ничектер** (как-то), **ничәдер** (сколько-то), **нигәдер** (почему-то).

2) употреблением частицы **әллә** перед вопросительными местоимениями: **әллә кем** (кто-то), **әллә нәрсә** (что-то), **әллә кайда** (где-то), **әллә нинди** (какой-то), **әллә ничек** (как-то), **әллә ничә** (сколько-то), **әллә нигә** (почему-то) и др.

Мин сезне **кайдадыр** күрдем. — Я вас где-то видел(а).

Бу ял көннәре **әллә ничек** узды. — Эти выходные прошли как-то не так.

10. Җөмләләрне укыгыз, билгесезлек алмашлыкларын билгеләгез.

1) Бу кешене минем кайдадыр күргәнем бар. 2) Бәйрәмдә шундый күңелле: кемдер матур итеп җырлый, кемнәрдер бии. 3) Бу кабинетта һәрвакыт кемдер нәрсәдер сөйли. 4) Әллә нигә бүген кәефем юк.

5) Ерактан әллә кем бик тупас итеп кычкырды. 6) Мин кайчандыр журналист булырга хыяллана идем.

**11.** Посоветуйте другу:

— при разговоре держать себя свободно;
— при беседе не перебивать друг друга;
— внимательно слушать собеседника.

**12.** Сез үзегез өчен нинди әхлак кодексы (кодекс морали) төзи аласыз? Төркемнәрдә фикерләшегез.

**13.** Сорауларга җавап бирегез.

1) Әйтик, әниегез авыр сумка күтәреп кибеттән кайта, ә сез дусларыгыз белән өй янында сөйләшеп торасыз. Бу очракта нишләрсез?

2) Исәнләшкәндә, башта кем кул бирергә тиеш — зурлармы, кечкенәләрме, ир кешеме, хатын-кызмы?

3) Әгәр бик тупас (грубо) итеп эндәшсәләр, сез бу ситуациядә нишләрсез?

4) «Егылганны таптамыйлар» дигән мәкальнең русча эквиваленты нинди? Сез бу мәкальне ничек аңлыйсыз?

## 40–41 нче дәресләр

**1.** Түбәндәге сүзләрне һәм сүзтезмәләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, тәрҗемәсен табыгыз.

Һәвәскәрләр, кайберләре, читтәрәк, таза гәүдә, шахмат тактасы, таныш, иярләшкән, көн нуры, катлаулана, күңел төшү, җиңелү.

**2.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

**үзе сизмәстән**
1) незаметно для тебя
2) незаметно для себя
3) незаметно для нас

**үрелде**
1) подвинул
2) потащил
3) потянулся

**һичшиксез**
1) без сомнения
2) с сомнениями
3) сомневаясь

**оялу**
1) стеснение, стыд
2) совестливый, совесть
3) очищение, чистота

**күңеле тулды**

1) расстроился
2) расчувствовался
3) разволновался

**3.** Сүзләрнең логик парларын табыгыз, җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| сукыр | ? | күп телләр белә торган кеше |
| һәвәскәр | | күзләре күрми торган кеше |
| полиглот | | берәр нәрсәне үзлегеннән өйрәнгән кеше |

**4.** Сүзләргә тиешле кушымчаларны ялгап, яңа сүзләр ясагыз, тәрҗемә итегез. Бу сүзләр белән җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| комач | ? | -чы |
| гәүдә | | -таш |
| сыйныф | | -лык |
| буш | | -ле |
| хәрәкәт | | -сез |
| шахмат | | -тай |

**5.** Сүзләрнең синоним парларын табыгыз, җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| таза | ? | кызару |
| бәләкәй | | билгеле |
| таныш | | елыйсы килү |
| комачтай булу | | кечкенә |
| күңел тулу | | симез |

**6.** Скажите, что:

— вы научились играть в шахматы;
— вы играете лучше в шахматы, чем в шашки;
— вы ходите в шахматный кружок;
— вы хотите победить в шахматах;
— ваш одноклассник хорошо играет в шахматы;
— вы постеснялись сказать правду;
— вам было стыдно.

**7.** Убедите друга записаться в шахматный кружок.

**8.** 1 нче күнегүдәге сүзләр һәм сүзтезмәләр белән җөмләләр төзегез.

**9.** **Исегезгә төшерегез!**

**Причастие** (сыйфат фигыль) — это неспрягаемая форма глагола, которая имеет признаки глагола и имени прилагательного. В татарском языке есть три временные формы: причастие настоящего, прошедшего и будущего времени.

| Хәзерге заман сыйфат фигыль | Үткән заман сыйфат фигыль | Киләчәк заман сыйфат фигыль |
|---|---|---|
| а) **-учы/-үче**<br>сөйлә-үче кеше<br>(рассказывающий человек)<br>җырла-учы кыз<br>(поющая девочка)<br><br>ә) **-а/-ә+торган, -ый/-и+торган**<br>би-и торган малай<br>(танцующий мальчик) | **-ган/-гән, -кан/-кән**<br>җырла-ган җыр<br>(спетая песня)<br>сөйлә-гән сүз<br>(сказанное слово)<br>ярат-кан эш<br>(любимая работа)<br>кит-кән кеше<br>(ушедший человек) | а) **-ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк**<br>бар-ачак юл<br>(предстоящая дорога)<br>кил-әчәк кеше<br>(человек, который должен прийти)<br><br>ә) **-ыр,-ер,-ар,-әр,-р**<br>бар-ыр юл<br>б) **-асы/-әсе, -ыйсы/-исе**<br>бар-асы юл |

**10.** Җөмләләрдән сыйфат фигыльләрне табыгыз, сораулар куегыз.

1. Әни мин яраткан ашны пешергән. 2. Шахмат уйнаучы малай минем дустым иде. 3. Зәңгәр балконлы фатирда яшәүче әбинең улы кайтты. 4. «Эшлисе эшләрем бик күп әле», — диде Маһруй әби. 5. Сабантуйга кайткан кунаклар клубка җыелдылар. 6. «Эшкә китәр вакытың җитте, тиз бул», — диде әни.

**11.** Җөмләләрдә хикәя фигыльләрне табыгыз, сыйфат фигыльләргә әйләндереп, яңа җөмләләр төзегез.

Ү р н ә к: Һәвәскәрләр шахмат уйныйлар. — Шахмат уйнаучы һәвәскәрләр клубка килделәр.

1. Абыйның күзләре күрми.
2. Малай ладьяны яшерде.
3. Малайның җиңәсе килде.

**12.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

1. Күрмичә уйный торган бу кешегә Илгизнең җиңеләсе килмәде. 2. Тыныч кына басып торган бу абый аңа ошады. 3. Комачтай кызарган Илгизнең күз яшьләре тамды.

**13.** Как скажете о том, что:

— идёт поющий человек;
— к вам пришёл многознающий друг;
— незрячий человек тоже может хорошо играть в шахматы;
— в вашем дворе шахматисты часто играют в шахматы;
— вы не хотите проиграть в шахматы;
— вы непременно выиграете?

**14.** 13 нче күнегүне язмача эшләгез.

## 42–44 нче дәресләр

**1.** Биографик материалны укыгыз.

Язучы һәм шагыйрь Марсель Галиев 1946 нчы елда Татарстанның Азнакай районы Балтач авылында туа. Азнакай урта мәктәбен тәмамлагач, 1965–1968 нче елларда армия сафларында хезмәт итә. Ул Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый. «Казан утлары» журналы редакциясендә эшли.

Марсель Галиев — профессиональ язучы, шигърият һәм проза жанрларында иҗат итә. Аның аерым әсәрләре рус, поляк, украин, үзбәк, каракалпак, осетин, чуваш телләренә тәрҗемә ителгән.

**2.** Бу сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез һәм тәрҗемәсен табыгыз. Алар сезгә хикәяне аңларга ярдәм итәрләр.

[қа́°йбә̆рләрә̆н], [та°қтасы̆́], [та°пқа́н], [та°ны̆́ш ту́гә̆л], [йа°ғы̆млы̆́], [сы̆йны̆фташлары̆ма́], [җиңә̆ләсә́ ки́лмәдә̆], [тә̆трәнә́п кит̄ә́], [бушлы́қ], [күңә̆лә́ тулды̆́, [о̆йалуда́н қо̆мачта́й булды̆́].

М. Галиев турында күбрәк бел

3. Хикәяне укыгыз.

### Җиңәсем килде

Беседкалар янына кешеләр җыелган. Анда һәвәскәрләр шахмат уйныйлар. Илгиз кайберләрен танып та белә. Бер читтәрәк кулына шахмат тактасы тоткан таза гәүдәле абый тора. Малай аңа таба китте:

— Абый, әйдәгез, икәү уйныйбызмы? Минем хрусталь шахматларым бар. Бүген генә бүләк итеп бирделәр.

Таныш түгел абый аңа таба кулын сузды:

— Син бик бәләкәй түгелме соң?

— Булса ни, мин сыйныфташларыма мат куям.

— Мин үземнең шахматларга ияләшкән, әйдә, бу да ярар, — диде таныш түгел абый. Шулчак Илгиз аның күзләренә карап тетрәнеп китте. Абыйның күзләре кибеп баручы күлгә охшаган иде. Илгиз аларда көн нурын күрмәде.

Сукыр абый ягымлы итеп елмайды. Әйтерсең күзендәге бөтен нуры аның йөзенә күчкән иде.

Күрмичә уйный торган бу кешегә Илгизнең бер дә җиңеләсе килмәде. Ләкин уен һаман катлаулана бара. Абый бик төгәл уйный, әйтерсең бармаклары белән күрә. Илгиз иреннәрен кысты: «Мин җиңәргә тиеш. Җиңәргә!»



Һәм ул, үзе дә сизмәстән, сукыр шахматчының почмакта торган ладьясын учына яшерде. Абый бераздан нәкъ шул ладья торган урынга үрелде. Ләкин аның кулы бушлыкта калды. Кул, бераз хәрәкәтсез торганнан соң, икенче фигурага күчте. Ладья Илгизнең учын пешерә башлады. Фигураны кире урынына утырту соң иде инде.

— Я, я, күңеленңне төшермә, бүген җиңелсәң дә, иртәгә, һичшиксез, җиңәчәксең, — дип, абый кеше аның җилкәсенә кулын салды.

Шулчак кырыйга килеп баскан Зөлфия:

— Ә сез элек күрә идегезме? — дип сорап куйды.

— Әйе, кызым. Танк эчендә яндым. Күзләрем дә...

Илгизнең күңеле тулды, күзләреннән яшь тамды. Оялудан ул комачтай кызарган иде:

— Абый, сез мине гафу... гафу итегез инде... Минем бик тә җиңәсем... җиңәсем килгән иде...

М. Галиевтан

**һәвәскәрләр** — любители
**танып белә** — узнавал
**кибеп баручы** — засыхающие
**нур** — луч
**ияләшкән** — привык
**хәрәкәтсез** — неподвижно
**бушлык** — пустота
**йөреш** — ход

**4.** Исегездә калдырыгыз!

**тетрәнеп китү** — пережить потрясение
**комачтай (комач кебек) кызару** — здесь: краснеть до корней волос
**күңел тулу** — расчувствоваться, доходить до слёз
**күңел төшү** — падать духом, отчаиваться

**5.** Хикәядән түбәндәге җөмләләрне табып укыгыз.

1. Таныш түгел абыйга шахмат уйнарга тәкъдим итү турында.
2. Илгиз абыйның сукыр булуын күрүе турында.
3. Илгизнең начар эше турында.
4. Абыйның төгәл уйнавы турында.
5. Зөлфия белән абыйның сөйләшүе турында.
6. Илгизнең оялуы турында.

**6.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

1. Янга Зөлфия килеп басты. 2. Илгизнең җиңеләсе килмәде. 3. Беседка янында һәвәскәрләр шахмат уйнадылар. 4. Илгиз гафу үтенде. 5. Илгиз абыйның күзләрендә көн нурын күрмәде. 6. Илгизнең таныш түгел абыйга тәкъдиме. 7. Илгиз сукыр шахматчының ладьясын учына яшерде.

**7.** Җөмләләрне киңәйтеп языгыз.

1. Абый тора. 2. Минияләшкән. 3. Илгизнең җиңеләсе килмәде. 4. Ул учына яшерде. 5. Ладья пешерә башлады.

**8.** Нокталар урынына төшеп калган сүзләрне өстәп укыгыз.

1. Беседкалар ... шахматчылар җыелган. 2. Кулына шахмат ... абый тора. 3. Илгиз аңа ... китте. 4. Мин ... мат куям.

**9.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Һәвәскәрләр шахмат ... . 2. Мин сыйныфташларыма ... . 3. Сукыр абый ягымлы ... . 4. Илгизнең җиңеләсе ... . 5. Мин җиңәргә ... . 6. Илгиз сукыр абыйның ладьясын ... .

**10.** Диалогларны хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз, сәхнәләштерегез.

1. — Син бәләкәй түгелме соң, энем.
— Юк, абый, мин сыйныфташларыма мат куям.

2. — Ә элек сез күрә идегезме?
— Әйе, күрә идем. Танк эчендә яндым.

3. — Мин җиңеләм бугай.
— Күңелеңне төшермә, бүген җиңелсәң, иртәгә җиңәрсең.

4. — Абый, әйдәгез икәү уйныйбыз, минем хрусталь шахматларым бар.
— Әйдә, энем.

5. — Абый, мине гафу итегез инде. Минем бик җиңәсем килгән иде.
— Хатаңны танygач, гафу итәм, энем.

**11.** Хикәяне рольләргә бүлеп укыгыз. Диалогларны сөйләшергә өйрәнегез.

**12.** Бу җөмләләр аша шахматчы абыйга нинди бәя бирерсез? Төркемнәрдә фикерләшегез.

— Мин үземнең шахматыма ияләшкән инде, әйдә бу да ярар.
— Сукыр абый ягымлы итеп елмайды.
— Я, күңелеңне төшермә, бүген җиңелсәң, иртәгә җиңәрсең.

**13.** Бу җөмләләргә карап, Илгизгә нинди бәя бирерсез? Төркемнәрдә фикерләшегез.

— Минем хрусталь шахматларым бар. Бүген генә бүләк итеп бирделәр.
— Мин сыйныфташларыма мат куям.
— Илгиз иреннәрен кысты: «Мин җиңәргә тиеш. Җиңәргә!»

**14.** Исегезгә төшерегез, бу фразалар сезгә үз фикерегезне белдерергә ярдәм итәр.

1. Минем уйлавымча, бу дөрес фикер.
2. Мин болай уйлыйм.
3. Минем фикеремчә.
4. Әйе, бу, минемчә, бик дөрес.
5. Мин дә шулай уйлыйм.

**15.** Что вы скажете в этих ситуациях по-татарски?

1. Предложите другу поиграть в шашки (домино, шахматы).
2. Спросите у друга, играет ли он в шахматы.

3. Допустим, вы не играете в домино, а играете в шахматы. Как вы об этом скажете?
4. Переспросите собеседника, хорошо ли играет в шахматы его отец.
5. Спросите, есть ли у друга дома шахматы.

**16.** Түбәндәге сорауларга җавап бирегез. Үз фикерегезне әйтер өчен, кереш җөмләләр кулланыгыз.

1. Илгизнең: «Мин җиңәргә тиеш. Җиңәргә!» — дип, максат куеп уйнавы уңай күренешме?
2. «Җиңү өчен бөтенесен дә эшләргә кирәк!» Сез бу фикерне ничек аңлыйсыз?
3. Күрмичә уйный торган бу кешегә Илгизнең җиңеләсе килмәве, аның нинди характер сыйфатын ачыклый?
4. Ничек уйлыйсыз, Зөлфия Илгизнең ладьяны яшергәнен күрдеме?
5. Илгиз киләчәктә алдашу юлына басармы?

**17.** «Җиңәсем килде» хикәясен сөйләргә өйрәнегез.

## 45–47 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемәсен исегездә калдырыгыз. Алар сезгә алдагы текстны аңларга ярдәм итәр.

Тырыш, уңган, тыйнак, саф күңелле, чибәр, ямьле, җир йөзе, сөйкемле, тормыш, ризык, оекбашлар, ямьләнә, яктыра, йолдызлар, сөйкемле.

**2.** Хатлар укуны дәвам итәбез. Бу хатны Разил исемле егет кызларга яза. Егетләр, сез аның белән килешәсезме? Кызлар, ә сез Разилнең хатын күңелегезгә салып куегыз.

### Ал кирәк, гөл кирәк, безгә нинди кыз кирәк?



Кызлар... Алар — җир йөзендәге иң саф, иң сөйкемле затлар. Менә без тормышны алардан башка күз алдына китереп карыйк әле. Әйе... Нинди күңелсез, караңгы кебек тоелыр иде ул. Алар булмаса, безгә кемнәр тәмле-тәмле ризыклар пешерер, кемнәр матур гөлләр үстерер, кемнәр соң безгә җылы шарфлар бәйләр иде.

Алар нинди сыйфатларга ия булырга тиеш соң? Минемчә, кызлар, иң беренче чиратта, тырыш, уңган, чибәр, сөйкемле, тыйнак булырга, олыларны хөрмәт итә белергә тиешләр.





Алар тәмле телле дә булсалар... Минем уйлавымча, егетләр тәмле телле кызларны ярата.

Минем фикеремчә, шундый кызлар булганда гына, тормыш тагын да ямьләнер, яктырыр.

Кызлар бит ул — йолдызлар,
Кызлар — тормышның яме.
Кызлар булганда гына,
Яшәве дә бик ямьле.

Вакытлы матбугаттан



**зат** — здесь: человек, личность
**караңгы** — темно
**җир йөзе** — здесь: на земле
**алардан башка** — без них
**иң беренче чиратта** — в первую очередь

**3.** Кызлар нинди булырга тиеш? Җөмләләрне дәвам итегез.

Минем уйлавымча, ... . Минем фикеремчә, ... .

**4.** Тексттан бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне табыгыз.

1. Җир йөзен кызларсыз күз алдына китереп булмый.
2. Кызлар эшчән булырга тиеш.
3. Кызларның характер сыйфатлары.
4. Кызлар тәмле телле булсын.
5. Тәмле телле кызлар булганда, тормыш тагын да ямьләнер.

**!** **5. Исегездә калдырыгыз!**

В татарском языке есть производные **(ясалма)** и составные **(тезмә)** прилагательные.

Производные прилагательные **(ясалма сыйфатлар)** образуются путём добавления к именам существительным аффиксов **-лы/-ле; -сыз/-сез**: акыллы — акылсыз (умный — глупый), тәрбияле — тәрбиясез (воспитанный — невоспитанный), игътибарлы — игътибарсыз (внимательный — невнимательный).

Составные прилагательные **(тезмә сыйфатлар)** образуются путём сочетания двух слов: сүзендә торучан — сүзендә тормаучан (держит своё слово — не держащий своего слова), Артур исемле (по имени Артур), арткы партадагы (на задней парте), кара чәчле (с тёмными волосами), шат күңелле (жизнерадостный).

**6.** Хаттан «сыйфат + исем» конструкцияләрен аерып языгыз.

Ү р н ә к: сөйкемле затлар.

**7.** Тексттан Разилнең үз фикерен белдерергә ярдәм итә торган сүзләрне табыгыз. Алар нинди сүзләр дип атала? Ул сүзләр белән җөмләләр төзегез.

**8.** Бу сыйфатларның кайсыларын — уңай, кайсыларын тискәре дип билгеләр идегез? Ясалма, тезмә сыйфатларны билгеләгез. Характер сыйфатлары белән җөмләләр төзегез, аергычларның астына сызыгыз.

Тырыш, чибәр, тупас, тәрбияле, тәрбиясез, сөйкемле, игътибарсыз, эшчән, үз-үзеннән артык канәгать, горур, әдәпле, ялкау, тәмле телле, тыйнак, куркак, ягымлы, акылсыз, акыллы, батыр, җитди.

**9.** Сезгә яшьтәшләрегез (ровесники) белән аралашу бик кыен булган вакытлар булдымы? Ни өчен шулай булды? Кечкенә инша (сочинение) язып карагыз. Үзегез язган иншаның эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

**10.** Диалогларга кирәкле репликаларны өстәгез, үзара сөйләшегез.



1. — Дима, синең апаң бармы?
— Әйе, апама 18 яшь.
— Ул нинди?
— Тышкы кыяфәтен әйтәсеңме?
— Юк, ул нәрсәләр эшли белә?
— ... .



2. — Коля, синең дус кызың бармы?
— ... .
— Аның исеме ничек? Ни өчен ул сиңа ошый?
— ... .

3. — Надя, ничек уйлыйсың, бәйли белү модадамы?
— Әлбәттә, бәйли белү — бик кирәкле эш.
— Надя, ни өчен алай уйлыйсың?
— ... .





4. — Алик, әйдә безнең белән кинога барабыз.
— Кемнәр бара?
— ... .
— Дима безнең белән дус түгел бит. Ул да барамы?
— Дима да бара. Ул Настяны чакыра. Настя — бик яхшы кыз.

— Мин Настяны беләм. Ул бик әдәпле, тыйнак, акыллы.
— Алик, ә син үзең генә барасыңмы?
— Юк, мин Надя белән барам.
— Надя нинди кыз ул?
— … .

**11.** Ашарга пешерү тәртибен истә калдырыгыз.

чистарта



кыргычтан уа



кисә



турый



камыр баса



болгата



кайната



кыздыра



**12.** Яраткан ризыгыгызның рецептын языгыз, сөйләргә өйрәнегез.

## 48–50 нче дәресләр

Ярдәмгә — плакатлар!

**1. Исегезгә төшерегез!**

В татарском языке различаются следующие разряды (**төркемчәләр**) местоимений

| **Зат** (личные) **алмашлыклары** | **Күрсәтү** (указательные) **алмашлыклары** | **Сорау** (вопросительные) **алмашлыклары** | **Юклык** (отрицательные) **алмашлыклары** | **Билгесезлек** (неопределённые) **алмашлыклары** | **Тартым** (притяжательные) **алмашлыклары** | **Билгеләү** (определительные) **алмашлыклары** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| мин<br>син<br>ул<br>без | бу<br>теге<br>әнә<br>шул | кем?<br>нәрсә?<br>нинди? | беркем<br>һичкем<br>берничек | кемдер<br>әллә кем<br>никтер | минеке<br>синеке<br>аныкы | һәр<br>бөтен<br>барлык |

**2.** Җөмләләрдән алмашлыкларны табыгыз, тәрҗемә итегез, төркемчәләрен күрсәтегез.

1. Һәрбер илнең үз флагы, гербы, гимны була. 2. Бәйрәмгә барысы да килделәр. 3. Һәркемгә дә бүләк булды. 4. Бөтен мәктәп белән экскурсиягә бардык. 5. Бу сөлге — минеке, ә зәңгәр төстәгесе синеке булсын. 6. Ниндидер тавыш ишетелә. 7. Теге якта музыка уйный. 8. Кызлар булмаса, кемнәр безгә гөлләр үстерер иде. 9. Алар нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

**!** **3. Исегездә калдырыгыз!**

**Билгеләү алмашлыклары**
Определительные местоимения

К определительным местоимениям относятся: **бөтен, барлык, барча, һәммә** (весь, целый), **үз** (свой).

Местоимения **бөтен, барча, барлык, һәммә** перед существительными выполняют функцию прилагательного и не изменяются по лицам и числам.

**Бөтен** җир ап-ак. (Вся земля белым-бела.)

**Барлык** укучылар да бүләк алды. (Все ученики получили подарки.)

С местоимением **барлык** существительные употребляются только во множественном числе: **барлык** кешеләр — все люди; **барлык** китаплар — все книги.

Местоимение **барысы** в речи употребляется без существительного в значении «все»: **барысы** да килделәр — все пришли.

С местоимением **бөтен** существительные употребляются в единственном числе: **бөтен** мәктәп — вся школа; **бөтен** сыйныф белән — всем классом.

Местоимение **бөтенесе** в речи употребляется без существительного в значении «всё»: **бөтенесе** матур — всё красиво; **бөтенесе** тәмле — всё вкусно.

**4.** Нокталар урынына **бөтен, бөтенесе, барлык, барысы** билгеләү алмашлыкларын өстәп языгыз.

1. Кыш көне ... җир ап-ак. 2. Өстәлдә ... тәмле иде. 3. Бу бәйрәмгә ... мәктәп әзерләнә. 4. Бәйрәмдә ... матур иде. 5. Мәктәптә ... бәйрәмнәр күңелле үтә. 6. Бәйрәмдә ... да рәхәтләнеп җырладылар, биеделәр. 7. Татарстанда ... милләт кешеләре дә дус яши. 8. Казанга экскурсиягә барырга ... дусларым да теләк белдерде.

**5.** Как скажете о том, что:

— все улицы вашего города красивые и широкие;
— вечером все пойдут на праздник;
— вы показали друзьям весь город;
— на этом празднике всё было хорошо;
— все ваши ответы правильны?

**6.** Төсләрне искә төшерегез. Сүзлекләрдән карап, төс атамаларын дәфтәрегезгә языгыз.

**7.** Тәрҗемә итегез. Башка төсләрне дә кулланып, түбәндәге тәртиптә җөмләләр төзеп карагыз.

Ак төс.
Ак төстәге күлмәк.
Бу күлмәк ак төстә.
Мин ак төстәге күлмәк яратам.
Яшел төс.
Яшел төстәге итәк.
Бу итәк яшел төстә.
Мин яшел төстәге итәк яратам.

**8.** Сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез.

Һәркем [һә́ркэм], халыкның [ха$^{o}$лы̆кны̆́ң], төсне [төснө́], чалбарыңа [ча$^{o}$лбары̆ңа́], башлаячак [ба$^{o}$шлайача́к̧], игътибар [ихтиба́р], һәрчак [һә́рчак̧], ышанычы [ы̆шаны̆чы̆́].

**9.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме?

### Минем төс — яшел. Ә синеке?

Һәркемнең яраткан төсе була. Аерым бер кешенең генә түгел, һәр халыкның яраткан төсе бар. Мәсәлән, татар халкы яшел төсне үз итә, ә кытайлар — сарыны.

Сары төс — үзе бер бизәк. Инде киеп туйган чалбарыңа сары каеш тагып куйсаңмы? Өр-яңа булып күренә башлаячак!

Кызыл төс — я аны бик яраталар, я бөтенләй яратмыйлар. Әлбәттә, кызыл төстәге киемне мәктәпкә кимисең. Ә менә дискотекага, дусларыңа, кичәгә кызыл кием белән барсаң, син игътибар үзәгендә буласың.

Зәңгәр — универсаль төс. Ягъни һәрчак модада, һәрчак күңелне күтәрә ул. Малайларга — куе зәңгәр, ә кызларга сыек зәңгәр килешә.

Аксыл-көрән (бежевый) — дизайнерларның яраткан төсе. Күңелсез төс димә. Ул үз-үзеңә ышанычны арттыра.

Ал ул — бизәк төсе. Җәй өчен әйбәт.

Ниһаять, яшел төс. Ул бик тиз аралашып китәргә ярдәм итә. Тынычлык төсе. Табигать төсе.

«Ялкын» журналыннан



**бөтенләй** — здесь: совсем
**киеп туйган чалбар** — брюки, которые уже надоело носить

**10.** Тексттан бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне табып укыгыз.

1. Үз-үзеңә ышанычны арттыручы төс.
2. Универсаль төс.
3. Бәйрәмчә төс.
4. Киемне яңарта торган төс.

**11.** Ничек уйлыйсыз, кием төсенә карап, кәеф үзгәрәме? Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Ак кием кисәң, кәеф ... .
   Ак киемне ... кияргә була.

2. Кызыл кием кисәң, кәеф ... .
   Кызыл киемне ... кияргә була.

3. Кара кием кисәң, кәеф ... .
   Кара киемне ... кияргә була.

**12.** Тексттан үзегезгә ошаган төс турындагы урынны табып укыгыз. Бу төс турында сез тагын нәрсәләр әйтә аласыз?

**13.** Бирелгән тезмә фигыльләрне ничек аңлыйсыз? Алар белән җөмләләр төзеп карагыз.

Үз итү, игътибар үзәгендә булу, хис итү.

**14.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез. Үзара сөйләшергә өйрәнегез.

1. — ... ?
— ... . Миңа зәңгәр төс ошый.
— ... ?
— Әйе, минем зәңгәр төстәге курткам бар.

2. — Миңа кызыл төстәге кием килешә.
— ... .
— Әйе шул, сиңа да кызыл төстәге кием килешә. Ә син соры төсне яратасыңмы?
— ... .
— Мин дә яратмыйм.

**15.** Төсләр кәефкә ничек тәэсир итәләр? Интернеттан материаллар табып, фикерләрегезне языгыз.

**16.** Җөмләләрне укыгыз, тәрҗемә итегез.

1) Менә бит ничек матур киенгәнсең!
2) Матур күлмәгеңне безгә дә күрсәт инде!
3) Нинди кием алдың инде тагын!
4) Әнә ничек киенәләр икән!

**17.** Төркемнәрдә фикерләшегез.

а) Бу кием модада дип, үзеңә килешмәгән (неподходящая) киемне кияргә ярыймы?

ә) Кием алганда, иң беренче чиратта, нәрсә турында уйларга кирәк: сәламәтлек турындамы, матурлык турындамы?

б) «Киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар» дигән мәкальне син ничек аңлыйсың? Үз фикерләреңне тормыштан мисаллар белән расла.

**18.** Ә сез беләсезме?

— Чәчәкләр бүләк итү — матур традиция.
— Бүләк итү өчен чәчәкләр саны 3, 5, 7 булырга мөмкин.
— Ир-егетләргә бер генә төстәге чәчәкләр бүләк итәләр. Әйтик, кызыл розалар, кызыл гвоздикалар.
— Хатын-кызларга ачык төстәге букет бирү килешә. Букетта чәчәкләр күптөрле булырга мөмкин.

— Кыз туганда, әни кешегә ал яки кызыл букет бирәләр, ә малай туганда, зәңгәр, күк, шәмәхә төстәге чәчәкләр бүләк итәләр.

**19.** Интернет аша бүләк кабул итү тәртибе турында табып укыгыз, сөйләргә өйрәнегез.

## 51–52 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

Җөмлә (предложение) тәмамланган фикерне белдерә. **Ия** (подлежащее) белән **хәбәр** (сказуемое) җөмләнең **баш кисәкләре** (главные члены) дип атала. Ия белән хәбәрдән башка кисәкләр **иярчен кисәкләр** (второстепенные члены) дип йөртелә. Иярчен кисәкләргә **аергыч** (определение), **хәл** (обстоятельство), **тәмамлык** (дополнение) керә.

**2.** Җөмләләр уйлап, үрнәктәгечә киңәйтеп языгыз. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләгез, сорауларын әйтегез.

Үрнәк: Ял иттем.
Мин ял иттем.
Мин кичә ял иттем.
Мин кичә бик яхшы ял иттем.
Мин кичә циркта бик яхшы ял иттем.

**3.** Дөрес тәрҗемәне икенче төркемдәге җөмләләрдән табыгыз.

1. Бу фикерең бик яхшы, мин синең белән килешәм.
Юк, мин риза түгел, без яхшы ял итә беләбез.
Мин шулай уйлыйм: китап уку — файдалы шөгыль.

2. Нет, я не согласен, мы умеем хорошо отдыхать.
Я так думаю: чтение книг — полезное занятие.
Твоё мнение очень хорошее, я согласен с тобой.

**4.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме? Төркемнәрдә үзара сөйләшегез.

— Буш вакыт — дәресләрдән тыш вакыт.
— Буш вакыт барлык эшләр беткәннән соң була.
— Буш вакытны файдасыз үткәрергә дә ярый, чөнки ул — буш вакыт.
— Буш вакыт ул урамда йөрер өчен, бары тик ял итү өчен генә.

— Буш вакытта спорт белән шөгыльләнергә кирәк.
— Буш вакытны файдалы үткәрсәң, үзеңә яхшы була.
— Буш вакыт ул дискотекаларга йөрер өчен.
— Буш вакыт ул төрле кызыклы тапшырулар карар өчен.

**5.** Сезнең буш вакытыгыз бармы? Сезнеңчә, буш вакыт нәрсә ул? Сез аны ничек үткәрәсез? Төркемнәрдә фикер алышыгыз. Дәфтәрегезгә языгыз.

**6.** Диалогны укыгыз, үзара сөйләшегез. Алмаз дөрес эшләгәнме?

— Алмаз, кичә өйдә нишләдең?
— Дәресләремне әзерләдем дә чаңгы шуарга чыктым.
— Кем белән шудың?
— Дусларым белән шудым.
— Урамда суык иде, туңмадыгызмы соң?
— Юк, мин кышкы табигатьне яратам, тиз хәрәкәтләнгәч туңмадык.

**7.** Как скажете о том, что в свободное время любите:

— слушать музыку;
— читать книги;
— гулять с друзьями;
— смотреть телевизор;
— кататься на велосипеде?

**8.** Спроси у друга, любит ли он в свободное время:

— слушать музыку;
— читать книги;
— гулять с друзьями;
— кататься на велосипеде.

**9.** Как скажет друг, если он в свободное время:

— не слушает музыку, а читает книги;
— не смотрит телевизор, а катается на велосипеде;
— не гуляет с друзьями, а играет в шахматы?

**10.** Поговори с другом.

— Синең буш вакытың бармы?
— Әйе, буш вакытым бар.
— Миңа реферат язарга булыш әле.
— Ярый, мин сиңа реферат язарга булышам.

# СПОРТ – СӘЛАМӘТЛЕК ЧЫГАНАГЫ



## 53–54 нче дәресләр

**1.** Спорт төрләрен тәрҗемә итегез, исегездә калдырыгыз.

Атыш
Көрәш
Нәфис гимнастика
Суга сикерү
Тимераякта шуу спорты
Чана спорты
Йөгерү
Фигуралы шуу
Җәядән ату
Өстәл теннисы
Ат спорты
Ишү спорты

**2.** Тәрҗемәне истә калдырыгыз!

Здоровье — сәламәтлек, беречь — сакларга, заниматься спортом — спорт белән шөгыльләнергә, закаляться — чыныгырга, бегать по утрам — иртән йөгерергә, умываться холодной водой — салкын су белән юынырга, делать зарядку — зарядка ясарга, ходить в спортивный кружок — спорт түгәрәгенә йөрергә, гулять на свежем воздухе — саф һавада йөрергә, отдыхать на природе — табигатьтә ял итәргә.

**3.** Фигыльнең инфинитив формасын искә төшерегез. 2 нче күнегүдәге фигыльләрдә кушымчаларның ялгану тәртибен аңлатыгыз.

**4.** Сәламәт булу өчен, дустыгызга нинди киңәшләр бирәсез? Сез бу киңәшләр белән килешәсезме?

1. Иртән йөгерергә кирәк. 2. Тәмәке тартмаска кирәк. 3. Иртән зарядка ясарга кирәк. 4. Салкын су белән юынырга кирәк. 5. Кич соң ятарга ярамый. 6. Телевизорны күп карарга ярамый. 7. Телефонда озак утырырга ярамый. 8. Витаминлы ризыклар ашарга кирәк. 9. Көндәлек режимны үтәргә кирәк.

5. Посоветуйте другу:

— бегать по утрам;
— умываться холодной водой;
— делать зарядку;
— заниматься спортом;
— ходить в спортивный кружок;
— гулять на свежем воздухе;
— кататься на велосипеде;
— плавать в бассейне.

6. **Исегездә калдырыгыз!**

**Күләм-чама рәвешләре** (Наречия меры и степени)

**бик** — очень
**аз** — мало
**сирәк** — редко
**шактый** — довольно
**бераз** — немного
**еш** — часто
**бөтенләй** — совсем

7. Җөмләләрне укыгыз. Рәвешләрне билгеләгез.

1) Минем абыем чаңгы спорты белән бик озак шөгыльләнә. 2) Кара әле, тимераякта йөрергә тиз өйрәнгәнсең син! 3) Аз сөйлә, күп эшлә. 4) Бик арыдым, әйдә бераз туктап ял итик әле. 5) Соңгы вакытта урамда бик сирәк күренәсең. Саф һавада йөрергә бөтенләй вакытың юкмы әллә? 6) Бассейнга еш йөрим, чөнки йөзү организмны ныгыта.

8. Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп языгыз.

1. Мин спорт түгәрәге... барам. 2. Мин спорт түгәрәген... кайтам. 3. Мин спорт түгәрәге... булдым. 4. Без түгәрәк... яхшы шөгыльлән... . 5. Түгәрәк... соң өй... кайтып кит... . 6. Иртәгә түгәрәк... Оля да бар... .

9. Җөмләләрдән исем фигыльләрне табыгыз. Ия белән хәбәрне билгеләгез. Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

1. Сәламәт булу — үзе бер бәхет. 2. Озак йоклау зарарлы. 3. Китап уку файдалы. 4. Йокы алдыннан телевизор карау зыянлы. 5. Ютәлләү — авыру билгесе.

**10.** Текстны укыгыз. Сәламәт булу өчен, нишләргә кирәк? Текст эчтәлеген сөйләү өчен план төзегез.

## Сәламәтлек — зур байлык



Халык: «Дөньяда иң зур байлык — сәламәтлек», — ди. Чыннан да шулай. Сәламәт кеше эшли дә, тормышын да яхшырта, ял да итә.

Һәр кеше үзенең сәламәтлеге өчен үзе җаваплы. Сәламәт булу өчен, кеше нәрсәләр эшләргә тиеш?

Сәламәт булу өчен, беренче чиратта, спорт белән шөгыльләнергә кирәк. Укучылар төрле спорт түгәрәкләренә йөри алалар. Мәсәлән, айкидо, гимнастика, волейбол, карате, җиңел атлетика, бию түгәрәкләре эшли. Иртән зарядка ясарга яки йөгерергә мөмкин.



Кышын тимераякта яки чаңгыда шуарга кирәк. Кышкы саф һава да сәламәтлеккә файдалы. Җәен елгада су коеныргa, кояшта кызынырга була. Теләсәң, велосипедта йөрергә мөмкин. Икенчедән, көндәлек режимны сакларга, акыл хезмәтен физик хезмәт белән аралаштырырга, авыр эштән соң ял итәргә кирәк.

Дөрес туклану да организм өчен бик файдалы. Күбрәк яшелчә һәм җиләк-җимеш ашарга кирәк. Йокы алдыннан кыздырылган, майлы, артык баллы ризыклар ашарга ярамый.

Әлбәттә, ел вакытына карап, дөрес киенә белү дә бик мөһим. Җәен — җиңел, кышын җылы кием кияргә кирәк. Кыш көне яланбаш йөрү, кыска җиңел курткалар кию төрле авырулар китереп чыгара.

Әлбәттә, сәламәтлекне саклау өчен, исерткеч эчемлекләр эчмәү, тәмәке тартмау — иң беренче шартлар. Димәк, һәр кеше үзенең сәламәтлеген үзе саклый ала.

Вакытлы матбугаттан





**җаваплы** — ответственный
**су коеныргa** — купаться
**кызынырга** — загорать
**аралаштырырга** — чередовать
**кыздырылган** — жареный
**исерткеч эчемлекләр** — алкогольные напитки

**11.** Тексттан төрле түгәрәкләргә йөрү турындагы урынны табып укыгыз. Бу түгәрәкләрдә ничек шөгыльләнәләр? Сезгә аларның кайсысы ошый? Ни өчен? Дәфтәрегезгә языгыз.

**12.** «Акыл хезмәтен физик хезмәт белән аралаштырырга кирәк» дигән киңәшне ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә фикерләшегез.

**13.** Текстка нигезләнеп, нокталар урынына үз фикерләрегезне языгыз. Җөмләләрдә инфинитивның барлык, юклык формаларын кулланыгыз.

Сәламәт булу өчен, ... / ... / ... кирәк.

**14.** Представьте, что ваш друг участвовал в лыжных соревнованиях. Похвалите его.

**15.** Как скажете:

— о времени работы спортзала;
— какими видами спорта занимается ваш друг;
— любит ли он кататься на лыжах?

**16.** Посоветуйте другу:

1. Записаться в кружки айкидо, карате. Убедите его в необходимости заниматься этими видами спорта.

2. Правильно питаться, соблюдать гигиену питания. Убедите его в том, что переедание вредно для организма.

**17.** Сәламәт яшәү кагыйдәләрен сөйләргә өйрәнегез. «Сәламәтлек — зур байлык» темасына төркемнәрдә сөйләшегез.

## 55 нче дәрес

**1.** Текстны укыгыз.

### Файдалы җиде ризык

Салкын кыштан соң безнең организмда витаминнар кими. Язын ризыкның витаминлы булуына игътибар бирергә кирәк. Даруханәләрдәге кыйммәтле витаминнарны эчмичә дә, үзебездә үскән җиләк-җимеш, яшелчә белән организмны ныгытырга мөмкин.



Чөгендердә кеше организмы өчен мөһим булган калий, магний, цинк, тимер кебек минераллар күп.

Кәбестә — марганец, йод һәм омега-3 май кислоталарына бай. Кәбестә белән чөгендердәге матдәләр баш мие эшчәнлеген зарарлый торган ферментларны тарката.



Кабак, кишер — бета-каротинга иң бай яшелчәләр. Алар язга кадәр үзләрендәге витаминнарны югалтмый саклый алалар.



Каражиләк антиоксидантларга бай. Ул күрүне яхшырт Бүгенге компьютерлар заманында әлеге җиләкне табиблар һәрдаим ашарга киңәш итә.



Мүк җиләге С витаминын ел әйләнәсендә үзендә саклый. Димәк, кешенең иммунитетын күтәрә, авыруларга каршы көрәшә.



Тикшеренүләр күрсәткәнчә, акыл эшчәнлеген арттыру өчен, мүк җиләге ашарга кирәк. Ул хәтерне яхшыртып кына калмый, ә терәк-хәрәкәт аппаратын да ныгыта.

Кара миләш кеше организмы өчен иң мөһим булган С, Р, А, В, Е, К витаминнарын үзендә туплаган.

**каражиләк** — черника　　**мүк җиләге** — клюква
**кара миләш** — черноплодная рябина

**2.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Чөгендердә кеше организмы өчен мөһим булган ... . 2. Кабак, кишер — ... . 3. Каражиләк күрүне ... . 4. Мүк җиләге С витаминын ... .

**3.** Текст эчтәлегенә план төзегез. План тәртибендә сөйләргә өйрәнегез.

! **4.** **Исегездә калдырыгыз!**

**Исемнәрнең ясалыш ягыннан төрләре**

1. **Тамыр** (корневые): тәрәзә (окно), бал (мёд), хезмәт (труд).
2. **Ясалма** (производные): ташчы (каменщик), эшче (рабочий), күзлек (очки).
3. **Парлы сүзләр**: (парные слова): ата-ана (родители); кайгы-хәсрәт (печаль).
4. **Кушма сүзләр** (сложные слова): аккош (лебедь), көнчыгыш (восток).
5. **Тезмә сүзләр** (составные слова): бал корты (пчела), тимер юл (железная дорога), кура җиләге (малина).
6. **Кыскартылма сүзләр** (сложносокращённые слова): ТР, музфак, вуз, КФУ, КДАТУ.

Ярдәмгә — плакатлар!

**5.** Түбәндәге сүзләрнең төзелешен билгеләгез.

Каражиләк, мүк җиләге, кара миләш, үги ана яфрагы, бию түгәрәге, башкала, алъяпкыч, күрше-күлән, көнбатыш, өчпочмак, карабодай, вәгъдә бирү, ярдәм итү.

# 56–58 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Гади җөмләләр җыйнак һәм җәенке булалар.**

| **Җыйнак** (нераспространённые) **җөмләләр** | **Җәенке** (распространённые) **җөмләләр** |
|---|---|
| Баш кисәкләрдән, ягъни ия белән хәбәрдән генә торган җөмлә **җыйнак җөмлә** дип атала.<br>Әти укый.<br>Мин барам. | Баш кисәкләре һәм иярчен кисәкләре булган җөмлә **җәенке җөмлә** дип атала.<br>Әти китап укый.<br>Мин бүген Казанга барам. |

**2.** Бирелгән җыйнак җөмләләрне җәенке җөмләләргә үзгәртеп языгыз.

1. Без барабыз.
2. Мин шөгыльләнәм.
3. Ул уйный.

**3.** Саннарның дөрес язылышын искә төшерегез. Үрнәк буенча саннарны сүзләр белән языгыз.

Үрнәк: 3 — өч, 15 — унбиш, 246 — ике йөз кырык алты, 2018 — ике мең унсигез.

9, 28, 82, 350, 673, 1995, 2005, 2017.

**4.** Текстны укыгыз. Ни өчен Казанны спорт шәһәре дип атыйбыз?








Казан — спорт шәһәре. Ул 2009 нчы елда «Спорт башкаласы» номинациясендә «Россиянең алтын командасы» милли премиясен алды.

Казанда 2013 нче елда — Универсиада, 2014 нче елда фехтование буенча дөнья чемпионаты узды. 2015 нче елда — су спорты төрләре буенча дөнья чемпионаты, 2017 нче елда футбол буенча Конфедерацияләр кубогы һәм 2018 нче елда дөнья чемпионаты булды. Башкалабызда зур спорт корылмалары бик күп: Үзәк стадион, Баскет-холл, Татнефть-Арена, Теннис академиясе, Чирәм хоккее үзәге, Волейбол үзәге, «Ак Барс» көрәш сарае, Су спорты төрләре сарае, Ишкәкле спорт төрләре үзәге һәм башкалар. Гомумән алганда (в общем), Казанда 2000 нән артык спорт корылмасы бар.

Казанның яңа стадионы 45 000 тамашачыны кабул итә ала. Анда балалар шәһәрчеге, сәүдә павильоннары, тренажёр заллары, теннис корты, ачык бассейннар урнашкан.

**бердәнбер** — единственный
**корылма** — сооружение
**сәүдә (нокталары)** — торговые (точки)

**5.** Текстка план төзегез, план эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

**6.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Казанда нинди дөньякүләм спорт ярышлары узды?
2. Казанда нинди спорт корылмалары төзелде?
3. Казандагы яңа стадион кайсы ягы белән үзенчәлекле?
4. Казанда нинди ял итү урыннары бар?

**7.** Дустыгыз белән сөйләшегез.

— Син спорт белән шөгыльләнәсеңме?
— Әйе, спорт белән шөгыльләнәм.
— Сиңа нинди спорт төре ошый?
— Миңа баскетбол ошый.

**8.** Как скажете, что вы:

— по вторникам и субботам ходите в спортивный кружок;
— танцами занимаетесь 5 лет;
— в свободное время ходите в бассейн?

**9.** Порекомендуйте другу:

— записаться на плавание;
— по утрам делать зарядку;
— часто бывать на свежем воздухе.

**10.** Узнайте у друга:

— есть ли у них в школе спортивный зал;
— каков режим работы спортивного зала;
— какие виды спорта ему больше нравятся;
— делает ли он утром зарядку, умывается ли холодной водой;
— ходит ли на спортивные секции.

**11.** Как скажете о том, что вы:

— хотите стать футболистом (хоккеистом, борцом, теннисистом);
— утром делаете зарядку, умываетесь холодной водой;
— ходите на спортивные секции;
— занимаетесь в спортивном зале?

**12.** Текстны укыгыз. Казандагы ял итү урыннары турында бер-берегезгә сөйләгез.







Казанда ял итү өчен дә барлык шартлар тудырылган. Казан — бик кунакчыл шәһәр. Шәһәрдә туристлар өчен ике йөздән артык агентлык, кырыктан артык кунакханә булуы шул турыда сөйли. Алар арасында халыкара дәрәҗәдәгеләре дә бар: «Мираж», «Корстон», «Шаляпин Палас Отель». Кунакханәләрдә уңайлы номерлар, аерым кунак бүлмәләре, зур телевизор, Wi-Fi бар. Биредә ябык бассейн, спа-салон, сауна һәм мунча да эшли.

Казанда күңел ачу парклары күбрәк җәйге ял белән бәйле. Аларда төрле аттракционнар, кафелар, сәүдә нокталары эшли.

Аквапарклар — балаларның һәм олыларның яраткан ял итү урыны. Аларның берсе — «Ривьера» аквапаркы. Монда 50 дән артык аттракцион, төрле тирәнлектәге бассейннар, кечкенәләр өчен шуу таулары бар. Аквапаркта идәннәр аяк таймаслык итеп эшләнгән.

**манзара** — вид, пейзаж, панорама
**кунакчыл** — гостеприимный
**шартлар тудыру** — создать условия
**халыкара дәрәҗәдәге** — международного уровня




**13.** Текст эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

# ТУГАН ИЛЕМ ШӘҺӘРЛӘРЕ ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ УРЫННАР

## 59–61 нче дәресләр

**1.** Текстларны укыгыз. Сез нинди шәһәрләр турында нинди яңа мәгълүмат белдегез, бер-берегезгә сөйләгез.

### Россия шәһәрләре



Истәлекле урыннар, яңа җирләр күрер өчен, күп кеше чит илләргә барырга хыяллана. Туган илебез Россиядә дә матур урыннар бик күп. Илебезнең иң матур шәһәрләре арасында — Санкт-Петербург, Мәскәү, Казан, Екатеринбург, Түбән Новгород, Калининград, Волгоград, Архангельск, Сочи, Ростов-на-Дону, Красноярск, Владивосток шәһәрләре. Аларның кайберләрен яратып, үзенчәлеген күрсәтеп, башкача да атап йөртәләр. Мәсәлән, Санкт-Петербург — Төньяк Венеция, Төньяк башкала, Мәскәү — Ак ташлы шәһәр; Казан — мәдәниятләр кисешкән урын; Түбән Новгород — Идел буе башкаласы; Архангельск — Төньяк традицияләр сакчысы; Сочи — Кояшлы шәһәр; Ростов-на-Дону — Россиянең көньяк башкаласы, Владивосток — Көнчыгыш диңгез капкасы.

Россиядә барлыгы 1100 дән артык шәһәр исәпләнә. 16 шәһәрдә миллионнан артык кеше яши. Әлбәттә, иң зур, иң матур шәһәрләр — Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Казан.

**2.** Шәһәрләрнең башкача да атап йөртелүе турында кабат укыгыз. Ни өчен шәһәрләргә шундый исемнәр бирергә мөмкин? Исемнәрне һәрбер шәһәрнең үзенчәлеге белән бәйләп аңлатып карагыз.

**3.** Башкалабыз Мәскәүнең тарихи истәлекләре белән танышыгыз.



Мәскәү — Европаның иң борынгы шәһәрләренең берсе. Мәскәүгә 1147 нче елны кенәз Юрий Долгорукий тарафыннан нигез салына. Мәскәү агач һәм таш биналар заманын әле дә хәтерли. Мәскәү елгасы шәһәр өчен яшәү чыганагы була. Елганың озынлыгы — 473 километр.

Кызыл мәйдан — Мәскәү шәһәренең символы. Чит илдән килгән туристлар Кремль комплексын карамыйча китми.

Данлыклы Мәскәү курантлары Спас манарасына куелган. Ул 1491 нче елда төзелә. Тантаналы чаралар үткәрү вакытында Кызыл мәйданга Спас манарасы капкалары аша керәләр.



Тарихи истәлек — Минин һәм Пожарскийга куелган монумент-һәйкәл

Кызыл мәйданны бик матур Василий Блаженный соборы бизи. Ул Явыз Иван әмере белән төзелгән. Собор 11 чиркәүдән тора. Аларның һәрберсе — сәнгать әсәре.

Кузьма Минин һәм Дмитрий Пожарский — халык геройлары. Алар халыкны интервентларга каршы көрәшкә берләштерәләр һәм 1612 нче елның 4 нче ноябрендә Мәскәүне азат итәләр.

4 нче ноябрь — Россиядә Халыклар бердәмлеге көне (День народного единства) буларак бәйрәм ителә.



**4.** Кызыл мәйдандагы тарихи истәлекләр турында диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

**5.** Бу даталарда нинди вакыйгалар була?

Даталар: 1147 ел; 1491 ел; 1612 ел.

**6.** Мәскәү метросы турындагы текстны укыгыз, җөмләләргә сораулар языгыз.

Мәскәү метросы дөньядагы иң матур метроларның берсе санала. Скульптура, пыяла тәрәзәләр, мозаика — чын җир асты сарае! Станцияләр декоратив композицияләр, уникаль сыннар, атаклы художникларның рәсемнәре белән бизәлгән. Бигрәк тә Маяковский, Революция мәйданы, Арбат, Комсомол, Җиңү паркы, Киев станцияләре матурлыгы белән туристларны җәлеп итә.

Метрополитен бүген 270 тән артык станциядән тора. Юллар озынлыгы — 470 километрдан артык. Бүген яңа станцияләр төзү эше дәвам итә.

**7.** Санкт-Петербург шәһәренең истәлекле урыннары турында укыгыз. Интернет аша өстәмә материаллар туплап, алар турында сөйләргә әзерләнегез.

Санкт-Петербург — Европада Лондон һәм Мәскәүдән кала өченче зур шәһәр. Санкт-Петербург шәһәрен Төньяк Венеция дип тә атыйлар.



Аңа 1703 нче елда Пётр I тарафыннан нигез салына. 1712 нче елда ул Россиянең башкаласына әйләнә һәм 1918 нче елга кадәр Россиянең башкаласы була.



Шәһәрнең һәр урамы — тарихи истәлек. Шуңа күрә шәһәрне «ачык һавадагы музей» дип атыйлар. Шәһәрнең үзәк бинасы — Кышкы сарай. Ул барокко стилендә Елизавета патшабикә вакытында император гаиләсе өчен төзелә. Аның янына 1764 нче елда Бөек Екатерина үзенең җыелган сәнгать әсәрләре коллекциясен урнаштыру өчен Эрмитаж төзетә. Эрмитаж — бүген дөньяда сәнгать әсәрләре саклана торган иң зур музей.

Туристлар Пётр I һәм башка патшалар җирләнгән Пётр һәм Павел соборына да зур кызыксыну белән киләләр.



Санкт-Петербург ачылмалы күперләре белән данлыклы. Алар шәһәрдә 20 гә якын. Күперләрне төнге берләрдән иртәнге бишләргә кадәр күтәреп аералар.

**8.** Сорауларга җавап бирегез.

1) Санкт-Петербургка кайчан нигез салына?
2) Санкт-Петербургка кайда нигез салына?
3) Санкт-Петербургка кем нигез сала?
4) Санкт-Петербург кайсы елларда Россиянең башкаласы була?

**9.** Санкт-Петербургта сезне нинди тарихи истәлекләр кызыксындыра? Шуларның берсе турында сөйләргә әзерләнегез.

**10.** Интернет аша Ленинград блокадасы турында материал туплап, кыскача сөйләргә әзерләнегез.

## 62–65 нче дәресләр

**1.** Текстларны укыгыз. Россия шәһәрләре турындагы мәгълүматны дәфтәрегезгә кыскача конспектлагыз, сөйләргә өйрәнегез.

Россиянең мәдәни үзәге булган Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан тыш, борынгы биналары күп булган бай тарихлы башка шәһәрләр дә байтак.

### Бөек Новгород



Бөек Новгород — Россиядәге иң борынгы шәһәрләрнең берсе. Ул елъязмаларда беренче тапкыр 859 нчы елда телгә алына. Киевтан кала иң бай, иң көчле кенәзлекләрнең берсе була. Шунысы кызыклы: Бөек Новгородта борынгы корылмалар, биналар җимерелми сакланган. Әгәр сезнең борынгы Киев Русе шәһәрен күрәсегез килсә, нәкъ менә шушы шәһәргә барырга кирәк. Шәһәрдәге 37 архитектура истәлеге ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегенә кертелгән.

### Түбән Новгород



Түбән Новгород — Бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегенә кертелгән 100 шәһәрнең берсе. Борынгы таш кирмән, иске агач биналар, җәяү йөри торган сукмаклар, гаҗәп матур чиркәүләр, Спас соборы — күпләр яратып карый торган тарихи истәлекләр.

Түбән Новгород дәүләт сәнгать музеенда дөньядагы иң зур картиналарның берсе саклана. 6x7 метр зурлыктагы бу әсәр «Минин мөрәҗәгате» дип атала.

### Архангельск



Архангельск Санкт-Петербург төзелгәнчегә кадәр Россия державасының төньяк порты була. Аннан Ак диңгезгә — бер сәгатьлек юл. Монда Пётр I үзенең беренче диңгез кораблен төзи. Архангельск — М. В. Ломоносовның туган ягы. Россиядә галимнәр хөрмәтенә куелган беренче һәйкәл — Ломоносовка.

**Сочи**



Сочи Россиянең иң эре курорт шәһәре булып санала. Диңгез яры, җылы климат, уңайлы пляжлар, парклар, сирәк очрый торган үсемлекләр — ял итү өчен тагын нәрсә яхшырак булырга мөмкин? Монда табигать гаҗәп матур: урамда эвкалипт, магнолия, пальма агачлары үсә, газоннар төрледән-төрле роза чәчәкләреннән генә тора. Шул ук вакытта Красная Полянада җәй көне карлы тауларда ял итеп була.

Адлердагы океанариум — Россиянең көньягында иң зурысы. Ул 2009 нчы елда ачылган. Аның мәйданы 6 мең квадрат метр. Океанариум — тулысынча пыяладан ясалган озын тоннель. Анда 4 меңнән артык диңгез хайваны һәм үсемлекләре яши. Экскурсиягә килүчеләр акулаларны, муреналарны, пираньяларны, скатларны һәм башка бик күп экзотик балыкларны күрәчәкләр.

**Волгоград**



Волгоград — миллионнан артык кеше яши торган шәһәр. Ул Россиянең көньягында, Идел елгасы ярында урнашкан. Шәһәр корылмалары яр буйлап берничә дистә километрга сузыла.

Шәһәргә якынча 1585 нче елда нигез салынган. Ләкин ул вакытта шәһәрнең исеме Царицын булган. 1925 нче елда шәһәр исеме Сталинград дип үзгәртелә. Сталинград сугышы Бөек Ватан сугышы тарихында әһәмиятле роль уйный. Нәкъ менә шуннан немец гаскәрләре кача башлый. Аны сугыш барышында кискен борылыш чоры дип саныйлар.

1961 нче елда Сталинград Волгоград дип үзгәртелә. Ә тагын 4 елдан соң шәһәр герой-шәһәр дип атала. Сугышта һәлак булганнар истәлегенә 1967 нче елда шәһәрнең иң югары ноктасында Мамай кургана мемориаль комплексына нигез салына. Биеклектә Туган Илана скульптурасы урнаштырылган. Аның биеклеге 80 метрдан артык. Ватан-ана скульптурасыннан тыш, комплекста Геройлар мәйданы, Кайгы мәйданы, Мәңгелек ут янган Хәрби дан залы һәм башка истәлекләр бар.

**2.** Әйтик, сез «Данлы Россия шәһәрләре» дигән кичәдә катнашасыз. Үзегез теләгән бер шәһәр турында чыгыш әзерләгез.

# 66–67 нче дәресләр

**1.** Татарстан турында текстны укыгыз. Текстка план төзегез.

Татарстан Идел буенда урнашкан һәм аның мәйданы 67 836 квадрат км дип исәпләнә. Бу Ирландия, Литва, Шри-Ланка кебек дәүләтләрнең мәйданына тиң.

Республикабызның иң зур байлыгы, горурлыгы — аның халкы. Ул инде дүрт миллионга якынлашып килә. Татарстанда 170 кә якын милләт кешесе яши. Татар халкы гасырлар дәвамында рус, чуваш, мари, башкорт, мордва, удмурт һәм башка халыклар белән дус, тату яши.

Республикабызның иң зур шәһәре — аның башкаласы Казан. Ул — бик борынгы кала. Аңа 1000 ел элек нигез салынган. Казан шәһәре Татарстанның төньяк-көнбатышында урнашкан. Ул Казансу елгасының Иделгә кушылган җирендә, ике як яр буйлап сузылган. Шәһәрнең халык саны 1,2 млн кешедән артык.

Татарстан Республикасы составына 43 муниципаль район һәм 2 шәһәр округы (Казан һәм Яр Чаллы) керә. Аларда 24 шәһәр, 17 шәһәр тибындагы бистә һәм 3000 гә якын авыл исәпләнә.

**2.** Татарстан картасыннан районнарны табыгыз, аларның географик урынын әйтегез.




Татарстан Республикасы турында укы

**3.** Татарстан шәһәрләренең татарча исемнәрен хәтердә калдырыгыз.

**Агрыз** — Әгерҗе
**Азнакаево** — Азнакай
**Альметьевск** — Әлмәт
**Арск** — Арча
**Бавлы** — Баулы
**Болгар** — Болгар
**Бугульма** — Бөгелмә
**Буинск** — Буа
**Елабуга** — Алабуга
**Заинск** — Зәй
**Зеленодольск** — Яшел Үзән
**Казань** — Казан
**Лаишево** — Лаеш
**Лениногорск** — Лениногорск
**Мамадыш** — Мамадыш
**Менделеевск** — Менделеевск
**Мензелинск** — Минзәлә
**Набережные Челны** — Яр Чаллы
**Нижнекамск** — Түбән Кама
**Нурлат** — Нурлат
**Тетюши** — Тәтеш
**Чистополь** — Чистай

**4.** Сез бу раслаулар белән килешәсезме?

— Татарстан Республикасының мәйданы бик зур түгел.
— Татарстан Республикасының мәйданы Ирландия, Литва кебек илләрнең мәйданына тиң.
— Татарстан халкы саны өч миллионга якынлашып килә.
— Казан шәһәре Татарстанның көньяк-көнбатышында урнашкан.
— Алабуга — Татарстанның иң зур шәһәре.

**5.** 1 нче күнегү эчтәлеге буенча диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

**6.** Үзегез яшәгән төбәкнең географик урыны, халкы турында сөйләргә әзерләнегез.

## 68–71 нче дәресләр

**1.** Татарстан шәһәрләре турында кызыклы мәгълүматларны укыгыз. Текстлар эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.



### Яр Чаллы шәһәре

1969 нчы елда бөтен ил өчен мөһим вакыйга була. Яр Чаллы шәһәрендә Кама автомобильләр заводы — «КАМАЗ» төзү турында карар кабул ителә. Йөк машиналары заводы белән бер үк вакытта яңа шәһәр дә төзелә башлый. Яр Чаллы шәһәрендәге Бөтенсоюз төзелешенә Советлар Союзының

төрле почмакларыннан эшчеләр һәм белгечләр җыела. Алар арасында 70 тән артык милләт вәкиле була. Төзелеш мәйданында 100 меңгә якын кеше эшли.

### Әлмәт шәһәре



Әлмәт шәһәре — Татарстан Республикасының зур нефть сәнәгате үзәге, Татарстанның «нефть башкаласы». Районның барлык территориясендә нефть чыга. Әлмәт «Дуслык» магистраль нефть үткәргече, Түбән Новгород, Пермь, Самара һәм башка нефть үткәргечләренең башлангыч пункты булып тора.

Ромашкино чыганагыннан елга 15 миллион тонна нефть алалар. Ул үзе генә дә 2 миллиард тоннадан артык нефть бирде.



Әлмәт дәүләт драма театры 1944 нче елдан бирле эшли. Бүген ул Татарстанның иң көчле театр коллективларының берсе булып тора, татар һәм рус телләрендә спектакльләр куя.

### Алабуга шәһәре

Алабуга — тарихи-мәдәни комплекслар, һәйкәлләр һәм истәлекле урыннар күпләп тупланган шәһәр. Алар республика һәм гомумроссия күләмендә генә түгел, ә бәлки дөньякүләм кыйммәткә ия. Бүген дә яңа музейлар ачу, һәйкәлләр төзү юлы белән, тарихта Алабуга шәһәренә бәйләнеше булган шәхесләр исемен мәңгеләштерү эше алып барыла.



Дөньякүләм сәнгать тарихында әһәмиятле эз калдырган бөек рәссам Иван Иванович Шишкин мемориаль музее 1835 нче елда Алабуга сәүдәгәре Иван Васильевич Шишкин төзеткән йортта урнашкан. И.В. Шишкин шәһәрнең иҗтимагый тормышында актив катнашучы буларак билгеле булган. И.В. Шишкин туган якны өйрәнү буенча Алабуга турында күп кенә тарихи материаллар җыя. 1871 нче елда Мәскәүдә «Алабуга шәһәре тарихы» дигән беренче тарихи очерк яза.



И.В. Шишкинның улы бөек рәссам И.И. Шишкин 1832–1898 елларда бу йортта үзенең балачагын һәм үсмер елларын үткәргән.

И.И. Шишкинның иң танылган рәсеме — «Нарат урманында бер иртә». Бүгенге көндә картина Мәскәүдә Третьяков галереясында саклана.

**Надежда Дурова мемориаль музее**



Атаклы кавалерист-кыз, 1812 нче елгы Ватан сугышы герое, беренче офицер-хатын-кыз — Надежда Дурова музей-йорты Алабуга кунаклары арасында аеруча кызыксыну уята.

Дурова Алабугада 30 елга якын яши.

Надежда Дурова 23 яше тулган көндә, кечкенә улын әтисенә калдырып, чәчен кистереп, ирләр күлмәге киеп, атлы казак полкына ияреп, сугышка китә. Ул үзен корнет Александров дип таныштыра.



1807 нче елда каты сугыш барганда, яралы офицерны коткарган өчен, Дурова Георгий тәресе белән бүләкләнә. Тик сер чишелә: тиздән батыр солдатның хатын-кыз икәне ачыклана, һәм аны өенә, әти-әнисе янына кайтарырга тиеш булалар. Әлбәттә, Н. Дурова моның белән килешә алмый, император Александр I гә үтенеч яза. Патша Дуровага армиядә калырга рөхсәт итә. 1812 нче елгы Ватан сугышында Н. Дурова Кутузовның шәхси ординарецы булып тора.

1835 нче елда ул Алабугага яшәргә кайта һәм язучылык эшенә керешә. 1839 нчы елда Дурованың 4 томнан торган «Повестьлар һәм хикәяләре» басылып чыга. Бөек критик В.Г. Белинский Дурованың иҗаты турында сокланып сөйли торган була.

Бүгенге көндә Алабуга шәһәрендә бронза атка атланган кавалерист-хатын-кызга һәйкәл куелган.

**Чистай**



Чистай авылына 18 нче гасыр башында нигез салына. 1781 нче елда Екатерина II указы белән аңа шәһәр статусы бирелә.

Бүген Чистай — бай тарихка һәм уникаль архитектурага ия матур шәһәр. Ул — дөньякүләм танылган композитор София Гобәйдуллинаның туган җире.

Бөек рус химигы Александр Михайлович Бутлеров та Чистай шәһәрендә туа.

Бөек Ватан сугышы елларында Чистай өяз шәһәренә совет язучылары Борис Пастернак, Александр

Твардовский, Александр Фадеев, Марина Цветаева, Анна Ахматова, Арсений Тарковский һәм башка язучылар эвакуацияләнә.

### Бөгелмә




Бөгелмәдә чех язучысы Ярослав Гашек музее бар. 1918 нче елда ул монда комендант булып хезмәт иткән. «Картада Бөгелмә аз урын алса да, минем йөрәгемдә аның урыны зур», — дип язган Гашек. Биредә ул үзенең «Бөгелмә хикәяләре» циклын язган. Бу әсәр төрле телләргә тәрҗемә ителгән. Бу китап музейда саклана.

Бөгелмә шәһәре вокзалында аркасына рюкзак аскан бронза солдат басып тора. Бу Ярослав Гашекның «Бөтендөнья сугышы вакытында солдат Швейкның башыннан үткәннәре» романы героена куелган һәйкәл.

**2.** Татарстан шәһәрләре белән танышуны дәвам итегез. Һәр абзац буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

Татарстанда дөньяга танылган галимнәр эшләгәне билгеле. Республикабызда бөек галим Дмитрий Менделеев эшләгән шәһәр бүген аның исемен йөртә. Ул — **Менделеевск шәһәр**е. Менделеевск бүген үзенең химия заводлары белән билгеле.

**Арча районы** — музейлар төбәге. Районда әдәбият һәм сәнгать музее, Габдулла Тукайның мемориаль комплексы, Тукаевлар гаиләсенең Кушлавыч авылындагы музей-утары, дөньядагы бердәнбер Әлифба музее, язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең туган авылы Гөберчәктәге музее һәм башка музейлар булдырылган. Арча районында сөт комбинаты, икмәк заводы, милли аяк киемнәре тегү, мех эшкәртү белән шөгыльләнә торган һәм башка предприятиеләр бар.

**Түбән Кама** — Кама аръягы зонасының иң тиз үскән шәһәрләренең берсе, республиканың нефть химиясе сәнәгате үзәге. «Түбән Кама Нефтехим» һәм «Түбән Кама Шин» акционерлык җәмгыятьләре — шәһәрнең төп предприятиеләре.

**Яшел Үзән** шәһәре — Иделнең сул ягында, елганы Мәскәү — Екатеринбург тимер юл магистрале кисеп үткән урынында урнашкан. Шәһәр машина төзелеше һәм металл эшкәртү, агач эшкәртү, җиңел һәм азык-төлек сәнәгате тармаклары үсеше белән данлыклы.

**Лениногорск** — Татарстанның иң матур һәм иң яшел шәһәрләренең берсе. Шәһәр урамнарын биек биналар, монументаль архитектура ансамбльләре бизи.

Беренче «кара алтын» ятмасы Лениногорскида 1948 нче елда ачыла. Нәкъ менә шул вакыттан шәһәрнең «нефть» тарихы башлана.

1968 нче елда Лениногорскида Советлар Союзында нефтькә багышланган беренче музей ачыла.



**3.** Тәрҗемә итегез.

Памятник нефти. Этот эффектный монумент был установлен в городе в 2007 году, после добычи трёхмиллиардной тонны татарской нефти. Этот памятник символически изображает мощные струи нефти, бьющие из-под земли. На 27-метровую высоту возвышается букет из двенадцати символических нефтяных фонтанов, собранных воедино и изображающих три миллиарда татарской нефти.

**4.** Сорауларга җавап бирегез.

1) Татарстанның Чаллы, Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә шәһәрләрендә нинди сәнәгать тармаклары үскән? Дәфтәрегезгә языгыз.
2) Кайсы шәһәр мәдәни комплекслары, истәлекле урыннары белән дөньякүләм әһәмияткә ия?
3) Татарстан Республикасының кайсы шәһәре халык саны буенча Казаннан кала икенче урынга чыкты?
4) Әлмәт шәһәре кайсы ягы белән үзенчәлекле?
5) Түбән Кама шәһәренең төп сәнәгать предприятиеләре нинди?
6) Татарстан Республикасының кайсы төбәкләрендә нефть чыгарыла?

**5.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1) 1781 нче елда Чистайга ... . 2) Бөгелмәдә чех язучысы ... . 3) Бөек галим Дмитрий Менделеев ... . 4) Арчадагы музейлар: ... . 5) Арча милли ... . 6) Түбән Кама шәһәренең төп сәнәгать предприятиеләре: ... .

**6.** Бүгенге «Кама автомобильләр заводы —«КАМАЗ» дигән темага Интернеттан материаллар туплагыз, чыгышка әзерләнегез.

**7.** Әйтик, сезгә килгән кунаклар Надежда Дурова белән кызыксыналар. Сез аның турында нәрсәләр сөйли алырсыз?

**8.** Үзегез яшәгән төбәк тарихы турында белешмә туплагыз, сөйләргә өйрәнегез.

# 72–74 нче дәресләр

Казан Кремле белән таныш



**1.** Текстны укыгыз. Казан Кремле турында сөйләргә әзерләнегез.

**Кремльгә экскурсия**

Башкалабызның үзәгендә Кремль урнашкан. Ул ак төстәге таш кирмән-койма белән уратып алынган. Элек анда хан сарайлары һәм мәчетләр булган. Хәзер биредә Татарстан Республикасы Рәисе сарае, Сөембикә манарасы, Благовещение соборы, Кол Шәриф мәчете һәм башка биналар бар.



Кремль каршында герой-шагыйрь **Муса Җәлилгә һәйкәл** куелган. Ул әсирлектә дә үлемсез шигырьләр язган, батырларча һәлак булган.



**Сөембикә манарасы** — бик борынгы корылма. Манараның биеклеге 58 метр. Ул кызыл кирпечтән төзелгән. Бу манара җиде катлы. Манараның эчендә тар баскыч ясалган. Тирә-якка нур бөркеп торган бу манара Казанның тарихи символына әйләнде.

Манара тарихи шәхес — Сөембикә ханбикә исеме белән бәйле. Сөембикә искиткеч гүзәл ханбикә була. Аның образы безнең чорга тарихи язмалар, риваятьләр, бәетләр аша килеп җиткән һәм хәзер дә халык күңелендә яши.

1549 нчы елның мартында Сөембикәнең ире Казан ханы Сафагәрәй үлә. Сөембикә ихтыяры белән тиз арада бу манара Сафагәрәй кабере өстендә төзелә. Ул 30х15х8 сантиметрлы кызыл кирпечтән салынган. 1552 нче елда Казан алынганнан соң Сафагәрәй кабере аннан күчерелә. Шуннан соң мавзолей күзәтү манарасы итеп файдаланыла.



**Спас манарасы.** Манара 1556–1562 нче елларда төзелә. Кремльгә кергән юлда ап-ак Спас манарасы урнашкан. Аны сәгать бизи. Спас манарасы Казан Кремле территориясенә керә торган төп кунак капкасы булып тора.

**Кол Шәриф мәчете.** Мәчеткә 1996 нчы елда нигез салына. Сигез почмаклы. Манараларга ярымай куелган. Ул искиткеч матур һәм зур мәчет. Кайсы яктан карасаң да, 4 манарасы балкып тора. Кол Шәриф Казанны саклап 1552 нче елның октябрендә шәкертләре белән бергә һәлак булган. Шуңа күрә ул халык хәтерендә каһарман буларак та урын алган. Кол Шәриф мәчетен ачу тантанасы 2005 нче елның 24 нче июлендә, җомга көнне була.



Бу мәчеткә татар халкы һәм килгән кунаклар бик яратып йөри. Кол Шәриф мәчете — татар халкының горурлыгы.



**Благовещение соборы** Кремль эчендә урнашкан. Ул — Казан Кремле территориясендәге иң борынгы корылма. Собор — Казан җирендә Явыз Иванның шәһәрне алуын билгеләп үтү хөрмәтенә төзелгән төп һәйкәлләрнең берсе.

Шәһәрнең бу төп кафедраль соборы бик күп кунакларны кабул итә. Анда шулай ук танылган әдәбиятчылар А.С. Пушкин, А.Н. Радищев, В.Г. Короленко, җырчы Фёдор Шаляпин һәм башка атаклы кешеләр булганнар.

**2.** Җөмләләрне текст эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

1. Манара тарихи шәхес — Сөембикә ханбикә исеме белән бәйле. 2. Манараның очында алтынсу ярымай балкый. 3. Сөембикә искиткеч гүзәл ханбикә була. 4. Сөембикә манарасы — Казанның иң күренекле архитектура истәлеге.

**3.** Тексттан бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне табып укыгыз.

1. Сөембикәнең матурлыгы.
2. Манараның биеклеге.
3. Манараның үзенчәлекләре.
4. Манараның исеме.

**4.** Җөмләләрне текст эчтәлеге буенча дәвам итегез.

1. Спас манарасы ... .
2. Спас манарасының ... .
3. Благовещение соборы ... .
4. Благовещение соборын Иван ... .
5. Благовещение соборында танылган ... .
6. Кол Шәриф мәчетенә ... .
7. Кол Шәриф мәчете ... .

**5.** Дәреслекнең 85 нче битендәге рәсем эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

**6.** Позовите друга съездить в Казань на экскурсию, убедите его в необходимости поездки.

**7.** Спросите у друга:

— был ли он в Казанском Кремле;
— чем запомнилась Спасская башня;
— посетил ли он мечеть Кул Шариф;
— в каком году была открыта мечеть Кул Шариф;
— видел ли он башню Сююмбике;
— знает ли он о Сююмбике;
— какие знаменитые люди посетили Благовещенский собор.

**8.** Вам хочется побывать в Казанском Кремле. Как вы об этом скажете родителям?

**9.** Бу манаралар кайда урнашкан? Алар турында Интернет аша мәгълүмат туплагыз, сөйләргә өйрәнегез.

| | | |
|---|---|---|
| Сөембикә манарасы | ? | Париж |
| Пиза манарасы | | Мәскәү |
| Эйфель манарасы | | Казан |
| Спас манарасы | | Италия |

**10.** Какие вопросы вы зададите, чтобы узнать:

— люди каких национальностей проживают в Татарстане;
— как они живут;
— какие языки являются государственными в Татарстане;
— что нарисовано на Государственном гербе Татарстана;
— какого цвета Государственный флаг Татарстана;
— кто является автором музыки и слов Государственного гимна Татарстана;
— какие молодые татарские певцы популярны сегодня;
— какие исторические места есть в Казанском Кремле;
— где находится новый театр Галиасгара Камала?

**11.** Как спросите у друга:

— каких татарских поэтов, писателей он знает;
— какие реки есть в Татарстане;
— какие исторические места есть в Татарстане?

**12.** Как скажете, что:

— вы были в музее Мусы Джалиля;
— вы ходили в Национальный музей Республики Татарстан;
— вам в музее понравились все экспонаты?

**13.** Сообщите о том, что:

— башня Сююмбике — украшение Казанского Кремля;
— Татарстан — республика в составе Российской Федерации.

**14.** Әйтик, сез Башкортстанга кунакка бардыгыз. Казан шәһәре турында нәрсәләр сөйләр идегез?

# 75–77 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Текст эчтәлеге буенча план төзеп, сөйләргә әзерләнегез.

Күптән түгел Казанга экскурсиягә бардык. Казан — искиткеч матур шәһәр. Бигрәк тә безгә Казан Кремле ошады. Анда Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы, Благовещение соборы урнашкан. Кремль янындагы мәйданда герой-шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл куелган.

Казанда озак еллар Татар дәүләт академия театры эшли. Театрда драмалар, комедияләр куела. Иң атаклы спектакльләрнең берсе — «Беренче театр». Пьесаның авторы — атаклы драматург Галиәсгар Камал. Һәм театр аның исемен йөртә.

Театр Кабан күле буендагы бик матур бинада урнашкан. 2021 нче елда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов яңа театр бинасы төзү турында карар кабул итә. Гаҗәеп матур яңа театр бинасын ачу тантанасы 2025 нче елда узды. Бинаның мәйданы 59 609 квадрат метр. 1500 тамашачы сыйдырышлы 4 залы бар. Татарстанда гына түгел, илебездә тиңе булмаган бу затлы бина ерактан ук балкып, нур бөркеп тора.



**2.** Предложите другу:

— поехать в Казань;
— пойти в театр имени Галиасгара Камала;
— посмотреть все залы театра.

**3.** Узнайте на сайте театра:

— какой спектакль идёт в театре;
— во сколько часов начинается спектакль;
— есть ли билеты;
— сколько стоит билет.

**4.** Ә сез беләсезме? Казанны музейлар шәһәре дип атыйлар. Рәсемнәргә карагыз, Казандагы музейларны исегездә калдырыгыз.



Бакый Урманче музее



Габдулла Тукай әдәби музее



Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее



Максим Горький әдәби-мемориаль музее




Нәҗип Җиһанов музей-фатиры



Каюм Насыйри музее



Татарстан Республикасы Милли музее

**5.** Интернет аша үзегез теләгән бер музей турында мәгълүмат туплап, сөйләргә әзерләнеп килегез.

**6.** Текстны укыгыз, бер-берегезгә сөйләгез.

**Казан — бөек шәхесләр шәһәре. Анда татар галимнәре Каюм Насыйри һәм Шиһабетдин Мәрҗани, атаклы математик Николай Лобачевский, бөек шагыйрьләр Габдулла Тукай һәм Һади Такташ, күренекле рус язучылары Лев Толстой һәм Максим Горький, герой-шагыйрь Муса Җәлил, данлыклы җырчы Фёдор Шаляпин һәм башкалар яшәгән.**

**7.** Рәсемнәргә карагыз, Казанда яшәгән атаклы кешеләрнең исемнәрен исегездә калдырыгыз.



Шиһабетдин Мәрҗани



Сергей Аксаков



Василий Качалов



Максим Горький



Фёдор Шаляпин



Каюм Насыйри



Александр Суворов



Лев Толстой

**8.** Дәвам итегез.

Н.И. Лобачевский — атаклы математик.
Г.Р. Державин — ... .
С.Т. Аксаков — ... .
Ф.И. Шаляпин — ... .
Л.Н. Толстой — ... .
А.М. Горький — ... .
В.И. Качалов — ... .
А.А. Фадеев — ... .

**9.** Текстны укыгыз. Эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

Татарстан белән күп кенә күренекле мәдәният эшлеклеләренең язмышлары бәйле. Җырчы Фёдор Шаляпин, язучылар Лев Толстой, Сергей Аксаков һәм Максим Горький, Василий Аксёнов, шагыйрьләр Евгений Боратынский, Гавриил Державин, Марина Цветаева һәм Никита Заболоцкий, рәссамнар Иван Шишкин һәм Николай Фешин, музыкантлар Олег Лундстрем һәм Михаил Плетнёв.







**10.** 9 нчы күнегүдәге шәхесләр турында сез нәрсәләр сөйли аласыз? Төркемнәрдә фикерләшеп, туплаган мәгълүматны дәфтәрегезгә языгыз.

**11.** Текстны укыгыз, тәрҗемә итегез, эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

Казанда бик зур халыкара һәм бөтенроссия чаралары уза. Монда ел саен Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивале, Нуриев исемендәге Халыкара классик балет фестивале, «Европа — Азия» хәзерге заман музыкасы фестивале, Казан Халыкара мөселман киносы фестивале үткәрелә. Казан шулай ук берничә тапкыр төрки халыкларның «Нәүрүз» театр фестивален кабул итте.

# МУЗЫКА ДӨНЬЯСЫНДА

## 78–80 нче дәресләр

**1.** Күренекле шәхесләрнең музыка турында әйткән сүзләрен укыгыз, тәрҗемә итегез, үз фикерегезне белдерегез.



Мне всегда лучше работается после того, как я послушаю музыку.
И.В. Гёте

Я всегда любил музыку. Если мне подолгу не приходилось слушать её, я тосковал.
И.Е. Репин



**2. Исегездә калдырыгыз!**

**1 нче октябрь** — Халыкара музыка көне.
**27 нче март** — Халыкара театр көне.
**18 нче май** — Халыкара музейлар көне.

**3.** Рәсемнәргә карагыз. Татар музыка сәнгатенә нигез салучы күренекле композиторларның исемнәрен истә калдырыгыз.



*Салих Сәйдәшев*

Композитор, татар профессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе.



*Нәҗип Җиһанов*

Композитор, педагог, җәмәгать эшлеклесе. 43 ел Казан консерваториясе ректоры булып эшли.



*Александр Ключарёв*

Композитор, фольклорчы, ТАССР Җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе.



*Мансур Мозаффаров*



*Рөстәм Яхин*



*Фәрит Яруллин*

Композитор, педагог, хәзерге заман татар профессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе.

Композитор, пианист, педагог. Татарстан Республикасы Дәүләт гимны авторы.

Беренче татар балеты «Шүрәле»гә музыка язган автор.

**4.** Текстны укыгыз. Зәһидулла Яруллин, Мирсәет һәм Фәрит Яруллиннарның татар музыка сәнгатенә керткән өлешләрен билгеләгез.

### Аталы-уллы Яруллиннар



Аталы-уллы Яруллиннар татар музыка сәнгатендә якты эз калдырдылар.

Заһидулла Яруллин атаклы композитор Салих Сәйдәшевның беренче укытучысы була. Татар музыка сәнгате тарихында беренче кыллы оркестр төзи.

1913 нче елда Г. Тукай вафатыннан соң атаклы «Тукай маршы»н яза. З. Яруллин татар музыка сәнгатендә зур урын алган ике композиторны: Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннарны үстерә. Ул үзенең ике улында да музыкага мәхәббәт тәрбияли, музыкаль белем бирә.



Мирсәет Яруллин — композитор, педагог, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, Муса Җәлил премиясе лауреаты. Халык яратып җырлый торган бик күп татар җырлары авторы. Озак еллар Казан консерваториясендә студентларга музыка белеме бирә, Татарстан Композиторлар берлеген җитәкли.

Фәрит Яруллин кечкенәдән музыка сәнгатенә гашыйк булып үсә. 1930 нчы елда ул музыка техникумына укырга керә, виолончельдә һәм фортепианода уйнарга өйрәнә.



1933 нче елда Ф. Яруллин Мәскәү консерваториясенә укырга җибәрелә. Уку елларында ул аеруча күп яза, фортепиано, скрипка һәм виолончель өчен сонаталар иҗат итә.

1939 нчы елда Фәрит Яруллин Габдулла Тукай әкияте мотивы буенча «Шүрәле» балетын иҗат итә. Аңа либреттоны Әхмәт Фәйзи яза. Спектакльне сәхнәгә чыгарырга әзерләнгән чорда Бөек Ватан сугышы башланып китә. Кызганычка каршы, композиторга Бөек Җиңү көнен күрергә насыйп булмый. 1943 нче елның 17 нче октябрендә Австрия башкаласы Вена шәһәрен фашистлардан азат иткәндә, ул батырларча һәлак була.

Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты беренче тапкыр Казанда 1945 нче елның мартында Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында куела һәм чын-чынлап халык күңелен яулый. Биш елдан соң балетны С.М. Киров исемендәге Ленинград опера һәм балет театры сәхнәсендә дә бииләр. Казанда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты сәхнәдән төшми. Музыка сәнгате тарихына Фәрит Яруллин исеме беренче татар балеты авторы буларак кереп калды.

**5.** Рәсемнәргә карагыз. Алар бер-берсе белән ничек бәйләнгән?









**6.** Интернет аша татар опера сәнгате турында материал туплап, кечкенә чыгыш әзерләгез.

**7.** Как скажете о том, что:

— автором первого татарского балета «Шурале» является Фарид Яруллин;

— автором балета «Су анасы» является Анвар Бакиров?

## 81–83 нче дәресләр

**1.** Композитор Салих Сәйдәшев турында укыгыз.

### Композитор Салих Сәйдәшев



Салих Сәйдәшев — композитор, дирижёр, Татарстанның халык артисты, 35 ел гомерен татар музыка сәнгатенә багышлаган атаклы шәхес. Ул халыкка 400дән артык җыр, романс, увертюралар, маршлар бүләк итә. Татар халкының беренче профессиональ композиторы Салих Сәйдәшев 1900 нче елда Казан шәһәрендә туа. Салих кечкенә вакытта ук музыкага сәләтле була, гармунда, пианинода уйнарга өйрәнә. Аның беренче музыка укытучысы танылган музыкант, пианист Заһидулла Яруллин була. Салих Сәйдәшев Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Гадел Кутуйлар белән аралаша, әдәбият-сәнгать дөньясында кайный. Ул Казанда кыллы музыка оркестры оештыра, беренче музыкаль әсәр — татар вальсын яза. Салих Сәйдәшев 1929 нчы елда данлыклы «Совет Армиясе маршы»н иҗат итә. Оборона халык комиссары Климент Ворошилов аңа исемле сәгать бүләк итә. Салих Сәйдәшев татар музыка сәнгатенә яңа жанр — музыкаль драма жанрын алып керә. Татар драма театры өчен Салих Сәйдәшев 60тан артык сәхнә әсәренә музыка яза. Сәйдәшев татар музыкасының үсешен яңа баскычка күтәрде.



Казандагы Зур концерт залы Салих Сәйдәшев исемен йөртә.

С. Сәйдәшев турында күбрәк бел



Татар халкы үзенең сөекле улын сагына, аның истәлеген барлый. Башкалабыз Казанда 1993 нче елның 25 нче июлендә Горький урамында Салих Сәйдәшев музее ачыла. 2000 нче елның 15 нче декабрендә Татарстанның Зур концертлар залына С. Сәйдәшев исеме бирелә.

2005 нче елның 12 нче августында Татарстан урамында С. Сәйдәшевкә һәйкәл куелды.

**2.** Текст буенча план төзегез, абзацларга бүлегез.

**3.** Җөмләләрне текст эчтәлеге эзлеклелегендә урнаштырыгыз.

1. Татар драма театры өчен Салих Сәйдәшев 60 тан артык сәхнә әсәренә музыка яза.
2. Салих Сәйдәшев — композитор, дирижёр, Татарстанның халык артисты.
3. Татар халкының беренче профессиональ композиторы Салих Сәйдәшев 1900 нче елда Казан шәһәрендә туа.
4. Татар халкы үзенең сөекле улын сагына, аның истәлеген барлый.
5. Аның беренче музыка укытучысы танылган музыкант, пианист Заһидулла Яруллин була.
6. Салих Сәйдәшев 1929 нчы елда данлыклы «Совет Армиясе маршы»н иҗат итә.

**4.** Текст эчтәлеге буенча диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

**5.** Тәрҗемә итегез.

В Государственном Большом концертном зале имени С. Сайдашева работают Государственный оркестр народных инструментов Республики Татарстан, Государственный камерный хор Республики Татарстан, Государственный струнный квартет Республики Татарстан.

**6.** Аудиоязмада «Совет Армиясе маршы»н тыңлагыз. Марш сездә нинди хисләр уята?

**7.** Текстны укыгыз. Текстка план төзегез.

### Совет Армиясе маршы

Салих Сәйдәшевнең «Совет Армиясе маршы» беренче тапкыр 1929 нчы елның 23 нче февралендә, Казан гарнизонының Кызыл

Армия туган көнгә багышланган тантаналы җыелышында хәрбиләр алдында башкарыла. Маршны 1 нче татар полкы оркестры башкара. Хәрбиләргә музыка шулкадәр ошый, аларның соравы буенча оркестр маршны өч мәртәбә кабатлый. Авторга «почётлы кызылармеец» исеме бирәләр, гаскәриләрнең хәрби киемен бүләк итәләр.

Марш беренче мәртәбә 1934 нче елда Мәскәүдә Кызыл мәйданда уза торган хәрби парадта яңгырый. Оборона халык комиссары Клемент Ворошилов композиторга алтын сәгать бүләк итә.

Бөек Ватан сугышы фронтларына Казан тимер юл вокзалыннан китүче гаскәрләрне «Совет Армиясе маршы»н уйнап озаталар. Салих Сәйдәшев дирижёрлык иткән симфоник концертлардан кергән акча Совет Армиясе фондына җибәрелә. Марш 1945 нче елның маенда — Берлин урамында, ә Җиңү көнендә Мәскәүдә яңгырый.

Шагыйрь Равил Фәйзуллин «Совет Армиясе маршы»ның героик язмышын «Сәйдәш» поэмасының түбәндәге юлларында бик ачык чагылдыра:

Сәйдәш рухы йөрде фронтларда,
Окопларда, алгы сызыкта.
Туплар булып яңгырады «Марш»
Фашизмга каршы, коллыкка!

«Совет Армиясе маршы»н тыңла

**8.** 7 нче күнегүдәге текст эчтәлеге буенча диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

**9.** Нокталар урынына ил исемнәрен языгыз. Тагын нинди атаклы композиторларны беләсез, Интернеттан материаллар туплап сөйләгез.

Бетховен дисәк без ... , Шопен дисәк, ... , Моцарт дисәк, ... уйлыйбыз. Салих Сәйдәшев дисәк, без Татарстаныбызны искә төшерәбез.

**10.** Әйтик, мәктәбегездә Салих Сәйдәшевка багышланган кичә булса, сез аның турында нәрсәләр сөйләр идегез? Кечкенә текст языгыз, сөйләргә әзерләнегез.

## 84–86 нчы дәресләр

**1.** Татар халкының күренекле композиторы Нәҗип Җиһанов турындагы текстны укыгыз.

### Күренекле композитор Нәҗип Җиһанов

Нәҗип Җиһанов 1911 нче елның 15 нче гыйнварында Уральск шәһәрендә туа. Бик яшьли ата-ана назыннан мәхрүм кала: аңа бер яшь тулганда — әтисе, ә биш яшь тулганда, әнисе вафат була. Шуңа күрә



балалык һәм үсмерлек еллары Уральск балалар йортында уза. Нәҗип кечкенә чагында ук үзлегеннән пианинода уйнарга өйрәнә.

1927 нче елда ул Казанга килә, биредә аның апасы яшәгән. Казанда ул Татар сәнгать техникумына укырга керә. Техникумда укыганда, Нәҗипнең уңышларына композитор Александр Ключарёв игътибар итә һәм аңа Мәскәүгә укырга барырга киңәш бирә.

1931 нче елда Нәҗип Җиһанов Мәскәү консерваториясендә композиторлар әзерләү бүлегенә укырга керә. Мәскәүдә ул Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров, Фәрит Яруллиннар белән бергә эшли.

Укуны тәмамлагач, Нәҗип Җиһанов кире Казанга кайта.

Казанда композитор татар шагыйре Муса Җәлил белән якыннан аралаша башлый. Иҗади дуслык нәтиҗәсендә «Алтынчәч» операсы туа. Операның премьерасы Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә — 1941 нче елның июлендә була. Соңрак композиторга аның өчен Сталин премиясе бирелә.

1953 нче елда Н. Җиһанов герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормышына багышланган «Җәлил» операсын яза. Ул Мәскәүнең Зур театрында, ә 1960 нчы елда Праганың Милли театрында уйнала.

Нәҗип Җиһанов Казанда консерватория ачу өчен күп көч куя. Ул озак еллар консерваториядә ректор булып эшли. Хәзер Казан дәүләт консерваториясе аның исемен йөртә.

Нәҗип Җиһанов — СССРның халык артисты, Социалистик Хезмәт Герое, СССР Дәүләт премиясе лауреаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

**2.** **Мәхрүм кала, укырга керә, аралаша башлый** — нинди фигыльләр? Аларны текстган табыгыз, җөмләләр төзегез.

**3.** Бирелгән сүзләрдән үрнәктәгечә «исем+исем» сүзтезмәләре төзеп языгыз.

Ү р н ә к: Алтынчәч, опера — «Алтынчәч» операсы.

Халык, артист; Уральск, шәһәр; балалар, йорт; сәнгать, техникум; Казан, консерватория.

**4.** Җөмләләрне үрнәктәгечә языгыз,

Ү р н ә к: Нәҗип Җиһанов туа.
Нәҗип Җиһанов (кайчан?) 1911 нче елда туа.
Нәҗип Җиһанов 1911 нче елда (кайда?) Уральск шәһәрендә туа.

Ул укырга керә.
Ул (кайда?) Казанда укырга керә.
Ул Казанда (кая?) Татар сәнгать техникумына укырга керә.

Җ ө м л ә л ә р:

1. Александр Ключарёв киңәш бирә. 2. Нәҗип Җиһанов укырга керә. 3. Нәҗип Җиһанов кайта. 4. Нәҗип Җиһанов аралаша башлый. 5. «Алтынчәч» операсы туа. 6. Премьерасы була. 7. Ул «Җәлил» операсын яза. 8. Нәҗип Җиһанов көч куя.

**5.** Текст буенча план төзегез. План пунктлары буенча сораулар әзерләгез.

**6.** Текст эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

**7.** Опера һәм балет театры турындагы текстны укыгыз. Музыка турында мәгълүматны истә калдырыгыз, бер-берегезгә сөйләгез.

**Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт - опера һәм балет театры**

Театр 1939 нчы елның 17 нче июнендә Н. Җиһанов әсәре буенча «Качкын» операсы премьерасы белән ачыла.




Милли опера һәм балет сәнгате үз эшчәнлегенең беренче унъеллыгында Н. Җиһановның — «Ирек», «Алтынчәч», М. Мозаффаровның — «Галиябану» опералары, Ф. Яруллинның — «Шүрәле» балеты; Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясе белән халык күңелен яулап ала. Бер үк вакытта театр сәхнәсендә Европа, рус опера һәм балет репертуарларыннан «Риголетто», «Травиата», «Фауст», «Евгений Онегин», «Аккош күле» кебек югары сәнгать әсәрләре дә куела.



Бүген театр коллективының сәнгати мөмкинлекләре бик киң: «зур опера» һәм «зур балет» стилендә эшләнгән академик пландагы спектакльләрдән алып, автор җитәкчелегендәге яки чорның мәшһүр дирижёрлары, режиссёрлары, сценографлары, хореографлары иҗат иткән тәҗрибә характерындагы спектакльләр куела, Татарстан композиторларының әсәрләре сәхнәләштерелә.

1991 нче елдан барлык спектакльләр дә оригинал телдә башкарыла. Төрле илләрдән (Италия, Нидерланд, Бөекбритания, Һиндстан, Канада, Көньяк Африка Республикасы һ.б.) килгән сәхнәгә куючы төркемнәр белән уртак иҗат проектлары гамәлгә ашырыла.

Спектакльләр арасында В.А. Моцартның «Фигароның өйләнүе» («Свадьба Фигаро»), «Тылсымлы флейта» («Волшебная флейта»), М. Мусоргскийның «Дон Жуан», «Борис Годунов» әсәрләре бик еш куела.

Театр чит илләргә һәрдаим гастрольләргә чыга: Бельгия, Бөекбритания, Германия, Австрия, Дания, Швеция, Швейцария, Нидерланд, Португалия, Франция һәм башка илләрдә ел саен 100 дән артык спектакль күрсәтә.

## 87–88 нче дәресләр

**1.** Татар халкының яраткан җырчысы Әлфия Авзалова турында текстны укыгыз. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев аңа нинди бәя бирә?

### Моң патшабикәсе



«...Әлфия Авзалова — җыр сәнгатендә иң тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе. Кешенең үзеннән тора: Әлфиянең җорлыгы, тырышлыгы, тормышта югалып калмавы шушы казанышларга ирешүгә нык ярдәм итте. Бөтен илне гизеп, күпме җырлар җырлап, халкыбызның моңын башкаларга җиткерү — моннан да зур эшләр кайда булыр? Бу зур казаныш. Әлфиянең гомере — җырлап узган гомер. «Моң патшабикәсе» дип, аңа зур бәһа бирер идем», — дип яза Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев җырчы Әлфия Авзалова турында.

Әлфия Авзалова 1933 нче елның 15 нче гыйнварында Татарстанның Актаныш районы Актаныш авылында туа. Аңа биш яшь вакытта, әнисе үлә. Әтисе Бөек Ватан сугышыннан кайта алмый. Ул әнисенең сеңлесе тәрбиясендә үсә. Кечкенәдән үк җырларга ярата, төрле концертларда катнаша.

Солистка буларак, 1952 нче елда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә эшкә чакырыла. Кабатланмас матур тавышка ия җырчы тиз арада ансамбльнең алдынгы башкаручыларыннан берсе булып таныла. 1957 нче елда Мәскәүдә Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында ясаган чыгышы Әлфия Авзаловага беренче зур уңыш китерә.

Ул эстрада сәхнәсендә Солтан Габәши, Александр Ключарёв, Мансур Мозаффаров, Заһит Хәбибуллин һәм башка композиторларның катлаулы әсәрләрен, халык көйләрен һәм заманча җырлар башкара. Легендар җырчы Урта Азия, Балтыйк буе республикаларында күп тапкырлар концертлар куя, Россия шәһәрләрендә чыгыш ясый.

Әлфия Авзалова — Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

**2.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Әлфия Авзалова кайда туа?
2. Аның балачагы ничек үтә?
3. Аны кая эшкә чакыралар?
4. Әлфия Авзалова беренче зур уңышка кайчан ирешә?
5. Минтимер Шәймиев җырчы Әлфия Авзаловага нинди бәһа бирә?
6. Әлфия Авзалова хезмәте ничек бәяләнә?

**3.** Тәрҗемә итегез.

За популяризацию песен народов мира в 1960 году певица была награждена почётной грамотой «За вклад в укрепление дружбы между народами мира». Она также дважды была награждена орденом Трудового Красного Знамени. В 2010 году в Казани, в кинотеатре «Мир», состоялась премьера документального фильма «Королева музыки», посвящённого Альфие Авзаловой. Автор сценария и режиссёр — Рабит Батулла.

**4.** Текст эчтәлеге һәм сораулар эзлеклелеге (последовательность) ярдәмендә план төзегез, эчтәлекне сөйләргә өйрәнегез.

**5.** Әлфия Авзалова җырлавын тыңлагыз, бергәләп җыр өйрәнегез.

Әлфия Авзалова, «Җидегән чишмә»

## 89–90 нчы дәресләр

**1.** Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров турында укыгыз.

Илһам Шакиров 1935 нче елда Сарман районының Яңа Бүләк (хәзер Тукай районына карый) авылында дөньяга килә. Ул гаиләдә алтынчы — төпчек бала була. Кече яшьтән үк Илһам зур авырлыклар күрә. Гаиләдә бала күп, ашарга юк. Иртәдән кичкә кадәр һәркем эштә. Кичләрен бергәләп чабата үрәләр, ә Илһам энисе белән җыр суза.

Аның тавышы моңлы, ягымлы, күңелгә үтеп керә торган, көчле, яңгыравыклы.

Мәктәптә дә Илһам тырышып укый, математиканы яхшы белә, укытучы булу турында хыяллана. Ләкин Илһам җырсыз, музыкасыз яши алмый. Армиядән соң ул Казан музыка училищесын тәмамлый, консерваториядә укый.

Илһам Шакиров — Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Аның үзенчәлекле моңлы җырлары бик күп төбәкләрдә яңгырый. Илһам Шакиров — бәхетле җырчы булды. Ул үз халкының күңелендә мәңгелеккә калды.



Вакытлы матбугаттан

**чабата үрәләр** — лапти плетут
**моңлы** — мелодичный
**төпчек** — последний ребёнок в семье
**хыяллана** — мечтает
**төбәк** — регион

И. Шакиров турында күбрәк бел

**2.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Ул гаиләдә … .
2. Илһам кечкенә чакта … .
3. Илһам әнисе белән … .
4. Ул Казан музыка … .
5. Илһам Шакиров илебезнең төрле төбәкләрендә … .

**3.** Тексттан бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне табып укыгыз.

1. Илһам Шакировның бала чагы.
2. Җырчының таланты, моңы турында.
3. Илһам Шакировның мактаулы исемнәре.

**4.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Илһам Шакиров кайда туган?
2. Ул гаиләдә ничәнче бала булган?
3. Кечкенә Илһам кем белән җырларга яраткан?
4. Ул ни өчен укытучы булмаган?
5. Илһам Шакиров кайларда укыган?
6. Халык ни өчен Илһам Шакировны ярата?
7. Илһам Шакиров нинди исемнәргә лаек булган?

5. Казахстаннан кунакка иптәшегез кайтты, ди. Ул җырчылар белән кызыксына. Сез аңа Илһам Шакиров турында нәрсәләр сөйләр идегез?

6. Текст эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

7. Илһам Шакиров турында шагыйрь Разил Вәлиевнең хатирәсе белән танышыгыз. Истәлек аша Илһам Шакировның нинди кешелек сыйфатларын күрә алдыгыз?

«Илһам агай белән танышлыгыбызга узган ел 50 ел булды. Иҗатта булсынмы, тормышта булсынмы, без аның белән һәрдаим аралашып, йөрешеп яшәдек. Тормышымда Илһам агайның урыны бик зур. Аралашу вакытында мин аның гыйлемлелегенә шакката идем. Ул татар халкының тарихын, динен, җыр-моң тарихын бик яхшы белә иде. Заманында радиода да тапшырулар алып барды».

8. Җөмләләрне дәвам итегез.

Татар җырчылары: Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, ...

Татар композиторлары: Рөстәм Яхин, ... .

9. Спросите у друга:

— какую музыку он любит слушать;
— какая у него любимая группа;
— поёт ли он в свободное время;
— играет ли он на каком-нибудь музыкальном инструменте;
— каких татарских певцов он знает.

10. Предложите другу:

— встретиться возле театра имени Г. Камала;
— послушать музыку;
— сходить на концерт, в театр, в кино;
— послушать музыку (вместе танцевать, петь, играть на гитаре).

11. Как скажете о том, что:

— Салих Сайдашев — знаменитый композитор;
— Салих Сайдашев — автор «Марша Советской Армии»;
— Фарид Яруллин — автор первого татарского балета;
— Сара Садыкова — автор лирических песен?

# ТАБИГАТЬ ҺӘМ КЕШЕ



## 91–92 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес әйтергә өйрәнегез, язылышын истә калдырыгыз, дөрес тәрҗемәсен табыгыз.

| | ? | |
|---|---|---|
| терлек | | долг |
| казылма байлыклар | | поколения |
| буыннар | | заботиться |
| кайгыртырга | | век |
| гасыр | | полезные ископаемые |
| кими | | скот |
| бурыч | | уменьшается |

**2.** Рәсемнәргә карагыз һәм әйтегез: нәрсә ул табигать?



**3.** Уйлагыз һәм җөмләләрне язып бетерегез. Кеше табигатьтән нәрсәләр ала?

Кеше кояштан ... .
Кеше елгадан ... .
Кеше урманнан ... .
Кеше таулардан ... .
Кеше җирдән ... .

**4. Исегездә калдырыгыз!**

**Сложноподчинённое предложение**
Иярченле кушма җөмлә

Сложноподчинённое предложение **(иярченле кушма җөмлә)** — это вид сложного **(кушма)** предложения, в составе которого одно простое предложение **(гади җөмлә)** по смыслу и интонации подчинено другому. Зависимое предложение называют придаточным **(иярчен җөмлә)**, независимое — главным **(баш җөмлә)**.

Части сложноподчинённого предложения связываются союзами **(чөнки, әгәр, ягъни, гүя)**; относительными словами **(шул, шуңа күрә, алайса, шуңа карамастан)**; аффиксами в составе сказуемого **(-гач/-гәч, -кач/-кәч, -ганчы/-гәнче)**. М ә с ә л ә н :

Барысы да тынып калдылар, **чөнки** кыз җырлый башлады.
Кыз җырлый башла**гач**, барысы да тынып калдылар.

**5.** Текстны укыгыз, эчтәлеккә карата диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

Кешеләр, табигатьне яратыгыз, табигать бездән ярдәм сорый. Без кояшсыз, айсыз, һавасыз, суларсыз, агачларсыз яши алмыйбыз. Агачлар безгә кислород бирә, ә без аларны утыртканга караганда өч тапкыр артыграк кисәбез. Сусыз без өч көн дә яши алмыйбыз, әмма без сулыкларны һаман пычратабыз. Елга, күл буйларында заводлар һәм комбинатлар төзибез. Димәк, без эчә торган суларыбызны агуга әйләндерәбез. Җир-су, һава пычранса, авырулар арта, зәгыйфь балалар дөньяга килә.

**6.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1) Без кояшсыз, ... . 2) Агачлар безгә ... . 3) Без сусыз ... . 4) Елга буйларында ... . 5) Авырулар арта ... .

**7.** 5 нче күнегүдәге текстан кушма җөмләләрне табыгыз, баш кисәкләрен билгеләгез.

**8.** Җөмләләрне дәвам итегез.

Үрнәк: Урманнарны сакларга кирәк, чөнки алар кешегә бик файдалы.

1. Суларны пычратмаска кирәк, чөнки ... .
2. Кошларны сакларга кирәк, чөнки ... .
3. Җәнлекләрне сакларга кирәк, чөнки ... .

**9. Исегезгә төшерегез!**

Если подлежащее и сказуемое в татарском языке выражены именами существительными или частями речи, близкими к существительным в именительном падеже (местоимением, именем действия), то между ними ставится тире. Например: Мәскәү — Россиянең башкаласы. Минем яраткан шөгылем — теннис уйнау.

**10.** Бирелгән җөмләләрдә тиешле тыныш билгеләрен куегыз.

1. Без табигать балалары.
2. Табигать ул әйләнә-тирә.
3. Табигатьне пычрату бик начар эш.

**11.** Тәрҗемә итегез.

Природа — это наше богатство, наше наследие, наша жизненная среда. От её состояния зависит здоровье и благополучие не только настоящих, но и будущих поколений. Если мы хотим, чтобы нашим детям и внукам было где жить, чем дышать и что есть, то мы должны активно принимать участие в охране и восстановлении природы.

**12.** 1 нче күнегүдәге сүзләр белән 5–6 җөмлә төзегез. Баш һәм иярчен кисәкләрне табыгыз.

## 93–94 нче дәресләр

**1.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы? Транскрипция билгеләре белән языгыз.

Гасыр, агулы, зарарлы, кайгырта, бурыч, казылма байлыклар, табигать, пычрана, куркыныч, гаепле.



**2.** Текстны укыгыз. «Табигать» төшенчәсен (понятие) сез ничек аңлыйсыз?

Син — табигать баласы. Табигать — синең әйләнә-тирәң ул. Кояш, болыт, су, ком, таш, хайваннар һәм үсемлекләр — барысы бергә табигать дип атала. Кеше үзенә кирәк әйберләрне табигатьтән ала. Иген, яшелчә һәм җиләк-җимешләр үстерә, терлек үрчетә.

Җир астыннан казылма байлыклар чыгаралар. Елга һәм күлләрдән балык тоталар. Урман-кырлардан гөмбә һәм җиләк җыялар.

Табигать бай, ләкин аны сакларга кирәк. Кешеләр киләчәк турында, алдагы буыннар хакында кайгыртырга тиешләр. Җир шарында барлык кешеләр дә гасырлар буе уртак бер максат белән яшиләр: ул — табигатьне саклау!

Кызганычка каршы, бүген кешелек зур куркыныч алдында тора. Табигать төрле зарарлы радиоактив матдәләр белән агулана, суларыбыз пычрана, үсемлекләр, җәнлекләр кимегәннән-кими. Табигатьне пычрату — гасыр чире ул. Табигатьне пычратучыларга каршы көрәшү — һәркемнең изге бурычы.

**терлек** — скот
**үрчетә** — разводит
**кешелек** — человечество

**3.** Тексттан бәйлек, бәйлек сүзләр кергән җөмләләрне табыгыз, алар белән җөмләләр төзегез.

**4.** Тексттан хәзерге заман хикәя фигыльләрне табыгыз, зат-санын билгеләгез, алардан исем фигыль формасын ясагыз.

**5.** Сыйфатларның ясалышын исегезгә төшерегез. Тексттагы сыйфатларны тамыр һәм ясалма сыйфатларга аерыгыз.

**6.** Җөмләләрне текст эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз. Ия белән хәбәр арасында сызык ни өчен куелганын аңлатыгыз.

1. Синең әйләнә-тирәң — табигать. 2. Табигать бай, ләкин аны сакларга кирәк. 3. Син — табигать баласы. 4. Кызганычка каршы, табигать торган саен күбрәк зарарлана бара. 5. Табигатьне пычрату — гасыр чире. 6. Кешеләр алдагы буыннар хакында кайгыртырга тиеш.

**7.** Сүзләр һәм сүзтезмәләр белән җөмләләр төзегез, сораулар уйлагыз.

| | |
|---|---|
| Кеше | балык тоталар. |
| Җир астыннан | үзенә кирәк әйберне табигатьтән ала. |
| Елгалардан | казылма байлыклар чыгаралар. |
| Кешелек | изге бурыч. |
| Табигатьне саклау | зарарлы матдәләр белән агулана. |
| Табигать | зур куркыныч алдында тора. |

**8.** Җөмләләргә сүзләр өстәгез, тәрҗемә итегез.

1. Басуда иген ... . 2. Татарстанның ... бай. 3. Табигатьне саклау — ... . 4. Табигать ... белән агулана. 5. Суларны, урманнарны ... сакларга кирәк, чөнки алар ... иң зур байлыгы.

**9.** Сорауларга җавап табып, диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

1. Нәрсә ул табигать?
2. Кеше табигатьтән нәрсәләр ала?
3. Җир шарында кешеләр нинди максат белән яшиләр?
4. Кешелек нинди куркыныч алдында тора?
5. Ни өчен табигатьне сакларга кирәк?

**10.** Табышмакларның җавабын әйтегез.



1. Яз килсә — киенә,
   Көз килсә — чишенә.

2. Олысы да, кечесе дә
   Эшләпә кигән.



**11.** 9 нчы күнегүне язмача эшләгез.

## 95–96 нчы дәресләр

1. **Исегездә калдырыгыз!**

**Теләкне ничек белдерергә?**
(Как выразить желание?)

Для выражения желания, намерения употребляется желательное наклонение **(теләк фигыль)**.

Желательное наклонение употребляется лишь в 1 лице единственного и множественного числа.

Утвердительная форма

бар-ый-м — давайте я пойду
кил-и-м — давайте я приду
бар-ый-к — давайте мы пойдём
кил-и-к — давайте мы придём

Отрицательная форма

бар-м-ый-м — давайте я не пойду
кил-м-и-м — давайте я не приду
бар-м-ый-к — давайте мы не пойдём
кил-м-и-к — давайте мы не придём

Для выражения желания употребляются и такие конструкции:

а) бар-асы килә — хочется идти
бар-асы килми — не хочется идти
кит-әсе килә — хочется уйти
кит-әсе килми — не хочется уйти

б) бар-ырга тели — хочет идти
бар-ырга теләми — не хочет идти
кил-ергә тели — хочет прийти
кил-ергә теләми — не хочет прийти

2. Нокталар урынына теләк фигыль аффиксларын өстәп языгыз.

1. Әйдә, Алсу, иртәгә урманга бар..., анда гөмбәләр җый... . 2. Без кошлар турында кайгырт... . 3. Татар телен яхшы бел... . 4. Татарстан гимнын өйрән... . 5. Туган илебезне ярат... . 6. Шәһәр урамнары чисталыгы өчен көрәш..., пычрат... .

**3.** Тәрҗемә итегез.

1. Давайте сегодня пойдём в лес. 2. Давай я тебе помогу. 3. Давайте всегда вежливо разговаривать. 4. Давайте не будем встречаться сегодня вечером, у меня времени нет. 5. Давайте я буду переводчиком.

**4.** Җөмләләрне укыгыз, фигыльләрнең зат-санын күрсәтегез.

1. Минем урманда уйныйсым килә. 2. Синең дусларың белән елга буена барасың киләме? 3. Аларның бакчага барасы килми. 4. Безнең су коенасыбыз килә.

**5.** Диалогтан теләкне белдергән формаларны табыгыз.

— Лена, синең безнең белән урманга барасың киләме?
— Әйе, бик барасым килә. Минем умырзая чәчәген күрәсем килә.
— Әйдә ял көне урманга барыйк, анда бергә ял итик.
— Мин риза. Сәгать ничәдә очрашабыз?
— Иртә белән сәгать унда.
— Сөйләштек.

**6.** Теләк белдерү формаларын кулланып, диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

**7.** Нокталар урынына кирәкле кушымчаларны өстәп, җөмләләр төзегез.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин<br>Син<br>Коля<br>Без<br>Сез<br>Алар | табигать... | сакларга<br>булышырга<br>файдаланырга | тели... . |

**8.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Минем урманга барасым килә, чөнки ... . 2. Табигатьне саклыйк, чөнки ... . 3. Киләчәк буын турында кайгыртырга телибез, чөнки ... . 4. Табигатьне һәр кеше сакларга тиеш, ләкин ... .

**9.** Тәрҗемә итегез.

Природа обладает огромным богатством, которое нужно бережно хранить и использовать с умом. Охрана природы включает в себя принятие мер по сохранению и восстановлению природных ресурсов, бережное отношение к окружающей среде.

# 97–98 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Тезүче** (сочинительные) һәм **ияртүче** (подчинительные) **теркәгечләр** (союзы) була.

Тезүче теркәгечләр:

1) җыючы (собирательные): һәм, да, дә, та, та, тагын;
2) каршы куючы (противительные): ләкин, ә, тик, әмма;
3) бүлүче (разделительные): я, яки, яисә.

Ияртүче теркәгечләр: чөнки, әгәр, аеруча, ягъни, шуңа күрә.

2. Җөмләләрне укыгыз, теркәгечләрне табыгыз, төркемчәләрен атагыз. Җөмләләрнең эчтәлеге буенча үзара сөйләшегез.

1. Табигать бай, ләкин аны сакларга кирәк.
2. Табигать төрле зарарлы радиоактив матдәләр белән агулана, суларыбыз пычрана, ә үсемлекләр, җәнлекләр кимегәннән-кими.
3. Елга һәм күлләрдә күптөрле балыклар бар.
4. Минем урманга барасым килә, чөнки анда саф һава, кошлар сайрый.

3. Нокталар урынына теркәгечләр куегыз, җөмләләрне языгыз.

1. Табигать матур, ... аны сакларга кирәк. 2. Безнең гаилә урман ярата, ... без анда еш булабыз. 3. Без бу гөмбәләрне җыймадык, ... алар агулы. 4. Урманны саклыйк, ... киләчәк буын безгә рәхмәт әйтер.

Теркәгечләр: һәм, чөнки, шуңа күрә, әмма.

4. 1 нче күнегүдәге теркәгечләр белән җөмләләр төзегез.

5. Җөмләләрне киңәйтеп языгыз.

1. Без барабыз. 2. Без җыймадык. 3. Без көрәшик.

6. Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Без — табигать балалары, шуңа күрә ... . 2. Табигать бай, ләкин ... . 3. Кеше кирәк әйберләрне табигатьтән ала, шуңа күрә ... . 4. Табигатьне сакларга кирәк, чөнки ... . 5. Әгәр табигатьне сакламасак, ... . 6. Табигатьне пычратучылар белән көрәшик, чөнки ... .

**7.** Как вы скажете о том, что:

— нельзя разводить костёр в лесу в ветреную погоду;
— после отдыха в лесу нельзя оставлять мусор;
— нельзя ломать деревья;
— нельзя разрушать гнёзда птиц в лесу;
— нельзя загрязнять воду разными ядовитыми веществами?

**8.** Рәсемнәрне чагыштырыгыз. Табигатькә төрле караш рәсемнәрдә ничек бирелгән?





**9.** Тәрҗемә итегез.

Охрана природы начинается с малого. Мы хотим участвовать в акциях по уборке мусора в парках и на улицах, разделять отходы и сдавать их на переработку, экономить воду и энергию, выращивать растения и ухаживать за животными. Мы хотим внедрить экологические привычки в нашу повседневную жизнь и поощрять других к их принятию.

**10.** Табигатькә сак караучыларны мактагыз, начарлык эшләүчеләргә киңәш бирегез.

## 99–100 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез, язылышларын истә калдырыгыз, тәрҗемәләрен табыгыз.

Матурлык [ма°турлы́ķ], табигать [та°биғә́т], һава [һа°wá], чишмә [чишмә́], ягулык [йа°ғулы́ķ], җәнлекләр [җәнлә̆клә́р], азык [а°зы́ķ], күке [күкә̆́].

**2.** Текстны укыгыз. Сез бу фикерләр белән килешәсезме?

Урман — кешенең якын дусты. Урманны кем генә яратмый икән?! Ул үзенең матурлыгы, гүзәллеге белән табигатькә ямь бирә. Урманда һава чип-чиста, шуңа күрә аны планетабызның үпкәсе дип атыйлар да инде. Урман ул — кислород чишмәсе, ягулык, төзү материалы, дарулар дөньясы да. Тормыш өчен кирәкле сумала, камфара, скипидар, буяулар да урманнан алына. Урман кошларга, җәнлекләргә азык, яшәү урыны бирә, кырларыбыз өчен дым саклый, климатны яхшырта.

Урмандагы һәр үсемлек, җәнлек, кош табигатькә ямь бирә. Зифа каеннар, күке тавышы, сандугач сайравы — барысы да урман белән бәйле.

Әйе, урман матур да, файдалы да. Ләкин урманга булышырга, аны сакларга кирәк! Урманнарны чиста тотыйк, киләчәк буын өчен саклап калыйк.

**дым** — влага
**сумала** — смола

**3.** Тексттан түбәндәге план пунктларына туры килгән өлешләрне табып укыгыз. Эчтәлек буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

1. Урман сәламәтлек өчен файдалы.
2. Урманның тормыш өчен файдасы.
3. Урманда кошлар, җәнлекләр яши.
4. Урманның кырлар, басулар өчен файдасы.

**4.** Тексттан теркәгечләрне табыгыз, төркемчәләрен билгеләгез.

**5.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Урманда һава чиста, шуңа күрә ... .
2. Урман матур, шуңа күрә ... .
3. Урманда йөрү рәхәт, чөнки ... .
4. Урманда кислород күп, чөнки ... .
5. Урманны саклыйк, чөнки ... .

**6.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп, җөмләләрне укыгыз.

1. Урман үзенең ..., ... белән табигатькә ямь бирә. 2. Урманны планетаның ... дип атыйлар. 3. Урман — ... чишмәсе. 4. Урман — ... да, ... да. 5. Урманга булышырга, аны ... кирәк. 6. Урманны ... тотыйк.

**7.** Бу мәкальне ничек аңлыйсыз? Тексттан аның эчтәлегенә туры килгән җөмләне табып укыгыз.

Саф һава — тәнгә дәва.

**8.** Урман ни өчен файдалы? Аны ничек саклап була? Таблицаны дәвам итегез.

| Нәрсә белән файдалы? | Ничек саклап була? |
|---|---|
| Кислородка бай, чөнки ул — кислород чишмәсе. | Агачларны сындырмаска кирәк. |
| … | … |

**9.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Урман кешегә ни өчен кирәк?
2. Урманны ни өчен һәм ничек сакларга кирәк?
3. Урман табигать, кешелек өчен нәрсәләр эшли?
4. Урманны саклауда безнең өлеш нинди?
5. Урманда ни өчен шешә ватарга (разбивать) ярамый?
6. Учак урынында ничә елдан соң үлән үсә?
7. Җилле вакытта ни өчен учак ягарга ярамый?
8. Ял иткән урынны нинди хәлдә калдырырга кирәк?

**10.** Диалогларны дәвам итегез, үзара сөйләшегез.

1. — Наилә, әйдә урманга барабыз.
— Урманда хәзер җиләк тә, гөмбә дә юк. Нигә барабыз соң?
— … .

2. — Андрей, сиңа кышкы урман ошыймы, җәйгеме?
— Җәйге.
— Ни өчен?
— … .

3. — Альберт, сиңа кышкы урман ошыймы?
— Әйе.
— Ни өчен?
— … .

**11.** Текстны укыгыз. Агач атамаларын истә калдырыгыз.

**Ә сез беләсезме?**



АКШның Невада штатында нарат агачын (сосна остистая межгорная) 1964 нче елны кисеп, боҗраларын санап, аның яшен билгеләгәннәр. Аңа — 4862 яшь.

АКШның Калифорния штатында секвойядендрон дигән агач 3266 ел үсә.

Иранда 4000 ел яшәгән кипарис бар.

Туган илебездә, Якутиядә, 750–885 яшьлек карагайлар (лиственницы) бар.

# 101–102 нче дәресләр

**1.** Тәрҗемә итегез.

нужно охранять — ...
ядовитое вещество — ...
для будущего поколения — ...
отравляет природу — ...
болезнь века — ...

об охране природы — ...
давайте заботиться — ...
борется за чистоту — ...
человечество остановит — ...
давайте охранять — ...

**2.** Башваткычны чишегез.


1 Я
2 Ш
3 Е
4 Л
5 Ч
6 Ә
7 Л
8 Ә
9 Р


1) Тәрәзәсе юк, ишеге юк, эче тулы халык.

2) Җир астында алтын казык.

3) Йөз кат кием, барысы да төймәсез.

4) Алма, дисәң дә алалар, нәрсә соң ул, балалар?

5) Озын-озын агачлар, агачларда оялар, ояларда кошчыклар.

6) Җир астында җиз бүкән, ул ни икән?

7) Ите симез — мае юк, тиресе калын — йоны юк.

8) Олысы да, кечесе дә ап-ак эшләпә кия.

9) Эче кып-кызыл, тышы ямь-яшел.









**3.** Һәр ел фасылы үзенчә матур. Сез ел фасыллары турында нәрсәләр сөйли аласыз?

4. Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзегез.

1. Табигатьне, кирәк, сакларга.
2. Һәр, изге, табигатьне, кешенең, саклау, бурычы.
3. Чишмәсе, урманны, кислород, планетабызның, атыйлар, дип.
4. Булыйк, да, табигатьнең, әйдәгез, барыбыз, дуслары.
5. Көрәшик, урманның, әйдәгез, чисталыгы, өчен.

5. Бу мәкальләрне ничек аңлыйсыз?

Бүген белән көн бетми.
Агачны үстерергә — илле ел, кисәргә биш минут кирәк.
Алмалары булмаса, алмагач гаепле түгел.

6. Сез бу очракларда нинди киңәшләр бирер идегез?







7. Напишите плакаты, призывающие охранять природу.

**8.** Схема буенча диалог төзегез.

1) — сорау
— җавап
— киңәш
— килешү

2) — сорау
— раслаучы җавап
— сорау
— җавап һәм киңәш

Т е м а л а р: агач утырту; чәчәкләр үстерү.

**9.** Табигатьне саклау турында кешеләргә нинди киңәшләр бирер идегез?

**10.** Ребусны чишегез.



# Сүзлек

## А

**авылдаш** — односельчанин
**агуланырга** — отравиться, травиться
**агулы** — ядовитый
**агыз** — пролей
**аергыч** — определение
**аеруча** — особенно
**аерылып тора** — выделяется
**аерым** — отдельно; отдельный
**аккош** — лебедь
**аксыл** — беловатый, белёсый
**аксыл көрән** — бежевый
**алайса** — если так, тогда
**алан** — поляна
**алдакчы** — обманщик, врун
**алдаша** — обманывает, врёт
**алмашлык** — местоимение
**аннан соң** — после этого
**аныклагыч** — поясняющее, уточняющее слово
**аныклык** — ясность, конкретность
**аптыраш** — растерянность
**аралашу** — общение
**аркылы** — через, поперёк
**арт** — зад
**артка** — назад
**артык** — слишком, более
**аръяк** — та сторона, заречье
**ары** — дальше, больше
**арый** — устаёт
**арыш** — рожь
**ас** — низ
**ат** — бросай, стреляй
**атау җөмлә** — назывное предложение
**атказанган** — заслуженный
**атла** — шагай
**ауна** — валяйся
**ачулы** — злой
**ачы** — горько, горький; кисло, кислый
**ачыш** — открытие
**ашык** — торопись

## Ә

**әгәр** — если
**әдәбият** — литература
**әдәпле** — вежливо; вежливый
**әдип** — писатель, литератор
**әзер** — готовый
**әйтем** — поговорка
**әллә** — или, либо
**әңгәмәдәш** — собеседник
**әсәр** — произведение
**әшәке** — плохой; грязный

## Б

**балан** — калина
**барыбер** — всё равно
**барысы** — все, всего
**басым** — ударение
**башваткыч** — головоломка
**башка** — другой
**башкача** — по-другому
**башлангыч** — начальный
**башта** — сначала, сперва
**бәйлек** — послелог
**бәйлек сүз** — послеложное слово
**бәла** — беда, несчастье
**бәлки** — возможно, вероятно
**бәргәләнә** — мечется
**бәс** — иней, изморозь
**бәялә** — оцени
**бераз** — немного
**бервакыт** — однажды

**бергә, бергәләп** — вместе
**бердәнбер** — единственный
**беркем** — никто
**бернинди** — никакой
**берничә** — несколько
**берьюлы** — сразу, одновременно
**билгелә** — отметь
**болга** — маши
**боргалана-сыргалана** — крутится-вертится, извивается
**борыл** — повернись
**ботак** — ветка, сук
**борчыла** — беспокоится, тревожится
**бөек** — великий
**Бөек Ватан сугышы** — Великая Отечественная война
**бөҗәк** — насекомое
**бөртек** — крупинка, зерно; капля
**бөтен** — целый, весь
**бөтенләй** — полностью
**бугай** — кажется, как будто
**буенча** — вдоль, по
**буйлап, буенча** — по
**бурыч** — долг
**бута** — путай, мешай
**буталчык** — запутанный
**буш** — пусто; пустой
**буын** — поколение
**бүлдермә** — не перебивай
**бүлек** — глава
**бүрәнә** — бревно
**бүтән** — другой

# В

**вакыйга** — событие, происшествие
**ват** — разбей, сломай, расколи
**ватык** — разбитый, сломанный
**вәгъдә** — обещание, обет
**вөҗдан** — совесть

# Г

**гадәт** — привычка, навык
**гадел** — честно, честный; справедливо, справедливый
**гаеп** — вина
**гаепле** — виновный
**гаҗәпләнә** — удивляйся
**газап** — мучение
**галим** — учёный
**гасыр** — век
**гафу ит** — извини, прости
**гашыйк** — влюблённый, любящий
**гәүдә** — туловище, тело
**гомер** — жизнь
**гореф-гадәт** — обычай, традиция
**горурлан** — гордись
**гөлҗимеш** — шиповник
**гөрләвек** — ручей

# Д

**данлыклы** — знаменитый, прославленный
**дәва** — лекарство
**дәлилләә** — докажи; аргументируй
**дәрәҗә** — степень, звание
**дәрт** — страсть
**дәһшәтле** — страшный, зловещий
**дерелди** — дрожит
**димәк** — следовательно, таким образом, значит
**дусларча** — по-дружески
**дым** — влага

# Е

**егет** — парень
**елан** — змея
**елмай** — улыбайся
**ерта** — рвёт
**еш** — часто

# Ж

**җай** — удобный момент, возможность
**җәза** — наказание
**җәмгыять** — общество
**җәяүле** — пеший, пешеход
**җимерелә** — разваливается
**җиңелчә** — слегка, налегке
**җитәкче** — руководитель
**җитәрлек** — достаточный
**җитди** — серьёзно; серьёзный
**җитез** — ловко, ловкий; шустро, шустрый
**җитеш** — успевай
**җуйма** — не теряй
**җыентык** — сборник

# З

**зарарлый** — вредит
**зарлан** — жалуйся
**затлы** — знатный, благородный
**зыянлы** — вредно; вредный

# И

**игълан** — объявление
**игътибарлы** — внимательный
**иҗат** — творчество
**иҗек** — слог
**икътисади** — экономический
**илт** — отнеси
**имеш** — будто бы, мол, дескать
**инеш** — речка; родник
**иптәш** — товарищ
**ирекле** — свободный
**ireш** — добейся, достигни
**иркәлә** — ласкай
**иркен** — просторно; просторный
**исән** — живой, здоровый
**исәнлек** — здоровье
**исемлек** — список
**иске** — старый
**искиткеч** — изумительно; изумительный
**исни** — нюхает
**истә калдыр** — запомни
**ичмаса** — хотя бы
**ишек төбе** — место перед дверью
**ишет** — услышь
**ия** — подлежащее

# Й

**йодрык** — кулак
**йомшак** — мягко; мягкий
**йонлач** — мохнатый, волосатый
**йөз** — плыви
**йөткер** — кашляй

# К

**кабан** — кабан
**кабер** — могила
**кабырга** — ребро
**казылма** — ископаемое
**кайбер** — некоторый
**кайвакыт** — иногда
**кайгырт** — заботься
**кайнаган** — кипячёный
**кайсы** — который
**кайчак** — иногда
**кал** — останься
**калтыра** — трясись
**калын** — густой
**камыр** — тесто
**кан** — кровь
**канәгать** — довольный
**карчыга** — ястреб
**каршы** — противоположный, напротив
**каурый** — перо
**кәеф** — настроение

**кемдер** — кто-то
**кереш сүз** — вводное слово
**кешелек** — человечество
**кигез** — одень
**киләсе, киләчәк** — будущий
**килен** — невестка, сноха
**килеш** — падеж
**килешү** — договор, сговор
**кимерә** — грызёт
**кими** — уменьшается, убавляется
**кимчелек** — недостаток
**кинәт** — внезапно, вдруг
**киңәш ит** — посоветуй
**киресенчә** — наоборот
**кис** — режь
**кисәкчә** — частица
**кит аннан** — уходи оттуда; не может быть
**кичереш** — переживание
**коелып төште** — рассыпался; растерялся
**кондыз** — бобр
**корсак** — живот
**коточкыч** — страшный
**кочаклый** — обнимает
**көй** — мелодия, мотив
**көймә** — лодка
**көл** — зола
**көнбатыш** — запад
**көндезге** — дневной
**көнкүреш** — быт
**көнчыгыш** — восток
**көньяк** — юг
**көрәш** — борьба
**көрәшче** — борец
**көчәй** — усиливайся
**куак** — куст
**куан** — радуйся
**куе** — густо; густой
**куллан** — используй
**кулъязма** — рукопись
**куркусыз** — бесстрашный
**куркыныч** — страшно; страшный
**куркыта** — пугает
**кушамат** — кличка, прозвище
**күнекмәгән** — непривычный
**күңел ач** — развлекайся
**күптән** — давно
**күпчелек** — большинство
**күргәзмә** — выставка
**күрешергә** — здороваться, встречаться
**күч** — пересядь, перейди
**күчер** — спиши
**кызган** — пожалей
**кызганычка каршы** — к сожалению
**кызыксын** — интересуйся
**кыйммәтле** — дорогой, дорогостоящий
**кыйна** — бей
**кылана** — кокетничает, изображает
**кыланыш** — поступок, выходка
**кырыс** — суровый, строгий, резкий
**кыстыр** — прищеми, вложи
**кычыткан** — крапива
**кыю** — смело, смелый; отважно, отважный
**кыяфәт** — внешний вид

## Л

**лаек була** — удостоен
**ләлә** — тюльпан
**лачын** — сокол

## М

**маҗаралы** — приключенческий
**максат** — цель
**мактанчык** — хвастун
**мактаулы** — похвальный
**матдә** — вещество, материя
**мәгълүмат** — информация

**мәгънә** — смысл
**мәдәни** — культурный
**мәдәният** — культура
**мәҗбүри** — обязательный
**мәкалә** — статья
**мәкаль** — пословица
**мәңге** — вечно; вечный
**мәртәбә** — раз
**мәрхәмәтле** — милосердный
**мендәр** — подушка
**мескен** — несчастный, жалкий
**микән** — ли, то ли
**мирас** — наследие
**могҗиза** — чудо
**моны** — это
**моңлы** — мелодично; мелодичный
**мөгаен** — наверное
**мөмкин** — можно
**мөнәсәбәт** — отношение
**мөстәкыйль** — самостоятельно; самостоятельный
**мөһим** — важно; важный
**муенса** — бусы, ожерелье
**мул** — щедро, щедрый; изобильный
**мүк** — мох

# Н

**надан** — необразованный; неуч, невежа
**намус** — честь
**начар** — плохо; плохой
**нәкъ** — именно, точь-в-точь
**нәшрият** — издательство
**нигез** — основа
**ниһаять** — наконец
**Нократ** — Вятка
**нур сип** — излучай
**ныгыт** — крепи, укрепи

# О

**озат** — проводи
**озын** — длинно; длинный
**оныт** — забудь
**онытылмаслык** — незабываемый
**орлык** — семя
**остаз** — наставник
**охшаш** — похожий
**оч** — конец, кончик
**очраш** — встреться
**очсыз** — дёшево; дешёвый
**ошый** — нравится
**оял** — стыдись
**оялчан** — застенчиво, застенчивый; робко, робкий; совестливо, совестливый
**оят** — стыд

# Ө

**өз** — рви
**өзгәлән** — разрывайся
**өзек** — отрывок
**өй** — складывай
**өлешчә** — частично
**өлкә** — область
**өлкән** — взрослый, старший
**өмет** — надежда
**өр-яңа** — совершенно новый
**өстәмә** — дополнительный

# П

**пәрәмәч** — перемяч
**песнәк** — синица
**пешер** — вари, пеки
**почмак** — угол
**пошы** — лось
**пөхтә** — опрятно; опрятный

# Р

**расла** — подтверди, докажи
**рәнҗет** — обижай
**рәсем** — рисунок
**рәссам** — художник
**рәхәт** — приятно, хорошо
**рәхим ит** — добро пожаловать
**риза** — согласен
**ризык** — пища
**рөхсәт** — разрешение
**рух** — дух, душа
**рухи** — духовно; духовный

# С

**сабыр** — терпеливо; терпеливый
**сагын** — скучай
**сагыш** — тоска
**саен** — каждый
**сайла** — выбирай
**сайланма** — избранный
**сакла** — береги
**сына** — ломается
**саңгырау** — глухой
**саран** — скупо; скупой
**саулык** — здоровье
**саф күңелле** — чистосердечный, искренний
**сәбәп** — причина
**сәлам** — привет
**сәламәт** — здоровый
**сәләт** — способность
**сәдәп** — пуговица
**сәхнә** — сцена
**сәяхәт** — путешествие
**себерке** — метла, веник
**сердәш** — закадычный друг
**сиз** — чувствуй
**сизгер** — чуткий
**симез** — тучный, полный, жирный
**сирәк** — редко; редкий
**соклан** — восхищайся
**соклангыч** — восхитительно, восхитительный; изумительно, изумительный
**соңга кал** — опоздай
**сөекле** — любимый
**сөен** — радуйся
**сөенеч** — радость
**сөйкемле** — симпатичный, обаятельный
**сөйлә** — рассказывай
**сөю** — любовь
**сөяк** — кость
**сугышчан** — боевой
**сугышчы** — воин, боец
**суела** — сдирается
**суз** — тяни
**сукыр** — слепой
**сул** — левый
**сурәтлә** — изображай
**сусыл** — сочный, водянистый
**сүзеңдә тор** — держи слово
**сүндер** — туши, выключи
**сыек** — жидко; жидкий
**сызгыр** — свисти
**сыйфат** — прилагательное
**сыйфат фигыль** — причастие

# Т

**таба** — сковорода
**табиб** — врач
**табигать** — природа
**табигый** — природный, естественный
**табыш** — находка
**табышмак** — загадка
**тагын** — ещё
**тал** — ива
**тамаша** — представление
**тамашачы** — зритель
**тамчы** — капля

**тамыр** — корень
**тантаналы** — торжественно; торжественный
**танылган** — известный
**таныш** — знакомый
**таң калдыр** — удиви
**тапкыр** — раз
**тапшыр** — передай
**тапшыру** — передача
**тар** — узкий
**таратучы** — распространитель
**тарих** — история
**тартык** — согласный
**тартыл** — потянись
**тасма** — лента
**татлы** — сладко; сладкий
**тату** — дружно; дружный
**ташлан** — бросайся
**таяк** — палка
**тәбәнәк** — низко; низкий
**тәвәккәл** — решительный
**тәҗрибә** — опыт
**тәкъдим ит** — предложи
**тәмамлык** — дополнение
**тәмәке тарту** — курение
**тән** — тело
**тәэсир** — влияние
**тезүче** — сочинительный
**тегермән** — мельница
**теләгәнчә** — вволю, сколько угодно
**теләк** — желание
**телем** — кусок
**текә** — крутой
**теркәгеч** — союз
**терлек** — скот
**тешлә** — кусай
**тигез** — ровно; ровный
**тиздән** — скоро
**тик яту** — бездельничать
**тимәскә** — не трогать
**тимер юл** — железная дорога
**тиңдәш кисәкләр** — однородные члены
**тип** — пинай
**тирлә** — потей
**токым** — порода
**торна** — журавль
**төбәк** — регион
**төгәл** — точно; точный
**төзә** — целься
**төзүче** — строитель
**төлке** — лиса
**төн** — ночь
**төнбоек** — кувшинка, водяная лилия
**төп** — основа
**төпчек** — младший ребёнок
**төрен** — кутайся
**төркем** — группа
**төтен** — дым
**төчкер** — чихай
**тугрылыклы** — верный
**тузганак** — одуванчик
**тукта** — остановись
**тукталыш** — остановка
**туктат** — останови
**тупас** — грубо, грубый; невежливо, невежливый
**туры килә** — подходит
**туфрак** — почва
**түбәтәй** — тюбетейка
**түгәрәк** — круглый
**түлә** — плати
**түрдән уз** — проходи
**тыйнак** — скромный
**тынычлык** — мир, спокойствие

# У

**уз** — проходи
**уң** — правый
**уңган** — умелый; трудолюбивый
**уңдырышлы** — плодородный
**урнаш** — устройся, устраивайся
**уртак** — общий, совместный
**уртаклык** — общность, взаимность

**усак** — осина
**уч** — ладонь
**учак** — костёр
**уян** — проснись
**уят** — разбуди

## Ү

**үз** — свой
**үзара** — взаимный
**үзгәрт** — измени
**үзе** — сам, само, сама
**үзенеке** — свой
**үзенчәлекле** — своеобразный
**үзләренчә** — по-своему, как сами желают
**үзлегеннән** — произвольно; самостоятельно
**үкен** — раскаивайся
**үкенеч** — раскаивание
**үкенечле** — жалко; досадно
**үлем** — смерть
**үпкәлә** — обижайся
**үрмәлә** — ползай
**үрчет** — разводи
**үсемлек** — растение
**үтерә торган** — смертельный
**үткәр** — пропусти
**үткен** — остро, острый; остроумный

## Ф

**файда** — польза, выгода
**файдалан** — пользуйся, используй
**файдалы казылмалар** — полезные ископаемые
**фәрман** — приказ, повеление, указ
**фикер** — мысль

## Х

**хаклы** — прав; законный, справедливый
**хәбәр I** — весть, известие
**хәбәр II** — сказуемое
**хәл** — сила, мощь, бодрость
**хәл ит** — реши, улади
**хәл фигыль** — деепричастие
**хәтле** — до, по
**хәтта** — даже, вплоть

## Һ

**һаман** — постоянно
**һәйкәл** — памятник
**һәлак бул** — погибни
**һәлакәт** — крушение, гибель, бедствие
**һәрбер** — каждый
**һәрвакыт** — всегда, постоянно
**һәркайсы** — каждый, любой
**һәркем** — каждый (человек)
**һәр көн** — каждый день
**һичшиксез** — без сомнения; обязательно
**һөнәр** — профессия, ремесло

## Ч

**чаклы** — до
**чакыр** — зови
**чат** — перекрёсток
**чәч** — волос
**чебен** — муха
**чирлә** — болей
**чит ил** — чужая, зарубежная страна
**читләш** — отдаляйся
**чишмә** — родник
**чүлмәк** — горшок
**чыгыш** — выступление

**чыда** — терпи
**чынлап** — в самом деле
**чын күңелдән** — от всей души
**чынык** — закаляйся

# Ш

**шаккат** — удивляйся, поражайся
**шарт** — условие
**шартлавык** — смолёвка
**шартнамә** — договор
**шәп** — здорово, хорошо
**шәфкатьле** — милосердный
**шоп-шома** — гладкий-прегладкий
**шу** — катайся
**шул** — тот
**шулаймыни** — неужели
**шулкадәр** — так, до такой степени
**шулпа** — бульон
**шунда** — там
**шуыш** — ползай

# Ы

**ылыс** — хвоя
**ыңгыраш** — стони
**ыргыт** — бросай
**ышан** — верь, поверь
**ышанычлы** — верно, верный; надёжный

# Э

**эз** — след
**эзлә** — ищи
**эл** — повесь
**эләк** — ловись, попадись
**элгеч** — вешалка
**элек** — раньше
**элемтәче** — связной, связист
**энә** — иголка
**эндәш** — обращайся, зови
**эссе** — жарко; жаркий
**эч** — живот
**эчке** — внутренний
**эшлекле** — деловой
**эшмәкәр** — бизнесмен, предприниматель

# Ю

**юан** — толстый, полный
**юаш** — смирный, тихий, кроткий
**югал** — исчезни
**югалт** — теряй
**юеш** — мокро, мокрый; сыро, сырой
**юка** — тонко; тонкий
**юкә** — липа
**юкка** — напрасно, понапрасну, зря
**юклык** — отсутствие, неимение
**юлдаш** — спутник, попутчик
**юлчы** — путник, проезжий, странник
**юмарт** — щедрый
**юньле** — толковый, умный
**юрган** — одеяло (стёганое)
**юри** — умышленно, нарочно
**ютәл** — кашель
**юын** — умывайся

# Я

**ябык** — худой; закрытый
**ябыш** — цепляйся, приклеивайся
**ябыштыр** — заклей

**ягулык** — горючее
**ягымлы** — ласково; ласковый
**язмыш** — судьба
**якла** — защищай
**якташ** — земляк
**якынлаш** — приближайся
**яланаяк** — босиком
**ялангач** — голый
**ялганла** — лги, ври
**ялгыз** — одинокий
**ялгыш** — ошибка; ошибочный
**ялкын** — пламя
**ялтыра** — блести
**ямьле** — красиво, красивый;
уютно, уютный
**ян** — гори
**яңгыра** — греми, звучи
**яра** — рана
**ярат** — люби
**ярты** — половина
**ярыйсы** — удовлетворительный,
средний
**яса** — делай
**ятим** — сирота
**ятла** — выучи
**яшен** — молния
**яшер** — прячь
**яшерен** — тайный
**яшьтән** — смолоду

# Эчтәлек

**КҮП УКЫГАН КҮП БЕЛЕР**

1–30 нчы дәресләр .......... 4

**ЯШЬТӘШЛӘР БЕЛӘН АРАЛАШУ**

31–52 нче дәресләр .......... 39

**СПОРТ – СӘЛАМӘТЛЕК ЧЫГАНАГЫ**

53–58 нче дәресләр .......... 55

**ТУГАН ИЛЕМ ШӘҺӘРЛӘРЕ ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ УРЫННАР**

59–77 нче дәресләр .......... 70

**МУЗЫКА ДӨНЬЯСЫНДА**

78–90 нчы дәресләр .......... 89

**ТАБИГАТЬ ҺӘМ КЕШЕ**

91–102 нче дәресләр .......... 101

**Сүзлек** .......... 115

Учебное издание

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Малафеева** Рамиля Лябибовна
**Ахметзянова** Гульназ Магсумзяновна

# ТАТАР ТЕЛЕ

**8 класс**

Учебник для образовательных организаций
основного общего образования

**Группа разработчиков учебно-методического комплекта**
Авторы *Р. З. Хайдарова,*
*Р. Л. Малафеева, Г. М. Ахметзянова*
Художественный редактор *С. В. Киатров*
Руководитель группы художников и верстальщиков *Д. И. Бариев*
Вёрстка *Е. Б. Шараповой*
Координатор проекта *А. М. Ганиев*
Технический руководитель *И. М. Низаметдинов*
Редакторы *Ф. Ш. Ахметзянова, Г. М. Ахметзянова, И. А. Закиев*
Художники *А. Е. Гаранина, П. К. Михайлова, А. Я. Смольская,*
*Н. К. Авдеева, Г. И. Гилазетдинова, А. Р. Ромашова*

Соответствует требованиям СанПиН 2.4.7.1166-02 «Гигиенические требования к изданиям учебников для общего и начального профессионального образования».

Подписано в печать 10.08.2025. Формат 84x108$^{1}/_{16}$ . Бумага офсетная. Гарнитура «Школьная».
Печать офсетная. Уч.-изд. л. 6. Тираж экз. Заказ

Издательство «Татармультфильм».
420124, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
**www.tatarmultfilm.ru**

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных издательством «Татармультфильм» материалов в типографии филиала ОАО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идель-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

**Издательство «Татармультфильм»**
разрабатывает и выпускает:

— учебники,
— электронные учебники,
— мультимедийные пособия,
— методические пособия,
— рабочие тетради,
— художественно-анимационные издания,
— интерактивные приложения.

**www.tatarmultfilm.ru**

Дополнительные материалы по изучению татарского языка и литературы для классных и внеурочных занятий на сайте **www.balarf.ru (www.бала.рф).**

# Гади җөмләләр җыйнак

## Җыйнак (нераспространённые) җөмләләр

Баш кисәклəрдән, ягъни ия белән хәбәрдән генә торган җөмлә **җыйнак җөмлә** дип атала.

*Әти укый.*
*Мин барам.*

**һәм җәенке булалар**

## **Җәенке** (распространённые) **җөмләләр**

Баш кисәкләре һәм иярчен кисәкләре булган җөмлә **җәенке җөмлә** дип атала.

*Әти китап укый.*
*Мин бүген Казанга барам.*

ФГОС



ISBN 978-5-906508-06-5

Татармультфильм

издательство
«Татармультфильм»